PRESSA

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН 2020 АПРЕЛЬ № 4

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

Илнар МИРАНОВ
беренче тәэсирләр алдавыч

гаиләдә – сынау
ИР ЭШ
тапмый

иң популяр
ДЕСЕРТ
камырсыз чизкейк

Динара МӘҖИТОВА:
«Халыкларны дуслаштырыр өчен бер сүз җитә!»

PRESSA

75 ПОБЕДА! 1945–2020

Хәтер – мәңгелек...

Бөек Җиңүгә миллионлаган гап-гади кешеләрнең каһарманлыгы бәрабәренә ирешә алдык. Алар арасында безнең татар егетләре, татар кызлары да байтак. Минем бабам, синеке, аныкы... Сугыш афәте кагылмаган, сугыш ишек шакымаган капка, гаилә калды микән? Җиңү таңы безгә шуңа да кадерле... Инде бу хакта бүгенге яшьләребезгә дә аңлатасы, төшендерәсе, күңелләрендә горурлык хисләре уятасы килә. Бу проект – шул хакта. Мондый ядкарьләр, бәлки, сезнең гаиләләрдә дә сакланадыр. Юк икән, аларны шушы сайттан табып алырга мөмкин: https://pamyat-naroda.ru. Бабаларыгызга орден-медальләр ни өчен бирелде икән? Балалар, оныклар белән бергә утырып эзләп карагыз әле. Әлеге тарихи документларны үз күзләре белән күргәч, Җиңү сүзенә алар инде берничек тә битараф калалмас...

Табышларыгызны безнең белән дә уртаклашыгыз. Хатларыгызны көтәбез.



Надыйров Шәриф Галим улы – Биектау (ул вакытта Дөбъяз) районы Чуваш Иле авылының беренче колхоз рәисе. 1933 елларда аны безнең якларга Әлмәт районы Кәшер авылыннан җибәрәләр. Чуваш Иле кызы Нәгыймәгә өйләнә, дүрт балалары туа. 1937 елда Надыйровны Дөбъяз авылына редактор итеп күчерәләр, аннан Арча районына райком секретаре итеп алалар. 1943 елның июлендә сугышка китә. 1945 елда, үлгән хәбәре килгәч, хатыны, балаларын алып, туган авылы Чуваш Иленә әтисе йортына кайта. Оныгы Гөлүсә бабасының бүләкләнү кәгазьләрен эзләтеп тапкан, җирләнгән урыны да билгеле. Шунда – Латвиягә барып кайту планы белән яши. (Кабер ташында инициалларында хата бар, икенче исемлектә инде төзәткәннәр.)

Наградной лист:
(танылып бетмәгән җирләре бар)
26–28.12.44 при отражении многочисленных ожесточенных контратак противника в районе Мастландэники (?) т. Надыров со своим взводом смело и решительно отражал наседавшего озверелого врага, расстреливая его в упор, не раз переходил в рукопашную схватку, с успехом каждый раз отбрасывая противника назад.
В бою 28.12.44. т. Надыров был ранен. В боях в районе Цельмали 23–30.01.45. при наступлении, он стремительной атакой выбил противника из занимаемых им рубежей. Противник предпринял яростные контратаки силами пехоты и танков. Т. Надыров проявил исключительную стойкость и мужество. Дружными действиями взвода он с успехом отражал попытки врага, прочно удерживая свой рубеж, своим личным примером мужества и бесстрашия воодушевлял своих бойцов.
В бою 31.01.45. т. Надыров был тяжело ранен. Достоин награждения орденом Отечественной войны II степени.

Сәвия ГАЛИЕВА,
Биектау районы Чуваш Иле авылы китапханәчесе.

НАГРАДНОЙ ЛИСТ

1. Фамилия, имя и отчество Надыров Шариф Галимович
2. Звание Гвард. лейтенант 3. Должность, часть Командир стрелкового взвода 268 гв. стр. орд. Суворова 3 ст. полка, 90 гв. стр. Витебск. кр. зн. дивизии
Представляется к ордену Отечественной войны II степ.
4. Год рождения 1904 5. Национальность татарин 6. Партийность чл. ВКП(б) с 1929
7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР и Отечественной войне (где, когда) Отечественная война с сентября 1944
8. Имеет ли ранения и контузии в Отечественной войне ран. 28.12.44 (легко). 31.01.45 тяж.
9. С какого времени в Красной Армии с июля 1943 10. Каким РВК призван Казанским ГВК
11. Чем ранее награжден (за какие отличия) Не награждался
12. Постоянный домашний адрес представляемого к награждению и адрес его семьи
Где находится представленный к награждению в настоящее время Выбыл в 596 ОМСБ по ранению.

I. Краткое, конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг

ПРОСМОТРЕНО Военной цензурой 21407

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2019



Фото: Анна Арахамия

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Тышлыкта:
Динара Мәҗитова
Фото: Альберт Дунбоянов

Верстка:
Резеда Галиуллина
Бүлек мөхәррирләре:
Чулпан Галиәхмәтова
Раилә Хәялиева
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Олег Сердюк

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.


Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 25.03.2020 ел.
Заказ А-658
Тираж 5000

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+

Гөлнара ҖӘЛИЛОВА

Яз сулышы

Язга атлыйм шигырь белән бергә,
Язга атлыйм сөю артыннан.
Бу галәмдә язын һәрбер йөрәк
Тизрәк эри кышның карыннан.

Тукай моңын көйлим эчтән генә,
Шигырь булып язга йөгерәм.
Апрель горур атлый галәм буйлап,
Итәгенә сөю түгелгән.

Яз – галәмгә, галәм язга чаба,
Кавышырлар алар, күрерсез.
Яз булалмый җирдә мәхәббәтсез,
Яз килалмый җиргә шигырьсез.

Апрель коча сөю иңсәсеннән,
Күзләреннән сөю түгелә.
Яз сулышын тояр өчен җанда
Суламыйча торыйк бүгенгә.




Фото: Газинур Хафизов

Рифат СӘЛАХ

Апрель

Апрель бүген.
Әнә апрель көлә,
Әнә апрель килә дөньяга.
Апрель балкый кара күк йөзендә.
Апрель ялкынында төн яна.

Апрель көлә
Бөреләргә кунып,
Апрель көлә карап кошларга.
Март аенда тынган бураннарны
Апрель җилләренә кушарга.

Апрель килә
Гөрләвеккә кунып,
Апрель килә чумып гөлләргә.
Йолдызларның шавы тынар кебек
Апрель белән тулган көннәрдә.



Безнең тышлыкта



«Бездәге татарларның тормышны кабул итүе дә, темпераменты да үзгә. Елына ун ай кояш кыздырган җирдә яшибез бит! Татарлыклары белән горурлану хас якташларыма, бер-берсе белән очрашсалар, уртак телне бик тиз табалар.»



12 Әстерханнан Казан күренә!
Раилә Хәялиева

Заман һәм без



6 «Һәр ялны туганнарымны җыям»
Чулпан Галиәхмәтова

16 Үзгәрәсем килә!
Гөлнур Сафиуллина

19 ИделиЯ
Мәдинә Авзалова



20 Мин бөтенләй башка!
Чулпан Галиәхмәтова

Татар дөньясы



22 Әнкәй безне Сөннән алып кайткан...
Эльмира Закирова



26 Саба көмешчеләре
Лилия Гәрәева

Мәдәни тормыш



36 Йола
Ландыш Әбүдәрова

Яшәеш



42 Дилбегәне җибәрергә булдым...
Раилә Хәялиева



50 Мәңгелек кояш иле
Алинә Гобәйдуллина

Хуҗабикә



60 Камырсыз чизкейк

»

PRESSA

«ҺӘР ЯЛНЫ ТУГАННАРЫМНЫ ҖЫЯМ»



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Гаиләдәге мөнәсәбәтләр, мөгаен, иң четерекле, нәзберек, бик тиз уалучан мөнәсәбәттер ул. Йокыдан торгач башкача карау, ашап туйгач рәхмәт әйтмәү, хәтта сөйләшкәндә тавыш тембры үзгәрү дә гаилә дигән учакның дөрләгән утын мизгел эчендә сүндерергә мөмкин. Караш кына түгел, хәтта әнә коронавирус та сәбәпче була ала. Атналар буе өйдән чыкмый гаилә белән бергәләп утырып кара әле?! Икең бер җан дисәләр дә, холык төрле. «Ныклы гаилә кору һәм аны яшәтү зур хезмәт ул, – ди Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе башлыгы Гөлшат НИГЪМӘТУЛЛИНА. – Ир белән хатын бер-берсенә ярашып, икесе бергә төзегән кечкенә дәүләтне сакласа, якласа гына уртак тормыш мәгънәле булачак. Ә моның өчен икең бер якка карап яшәргә кирәк».

Гөлшат Рәдифовна, ил буйлап алып карасак, демография күрсәткечләре берничә ел инде әллә ни мактанырлык түгел. Тик Татарстан бу яктан да күпләрнең борынына чиертте. Узган ел республикада үлүчеләргә караганда, яңа туган сабыйлар саны күбрәк булды. Идел буе федераль төбәкләре арасында бездә генә мондый тенденция саклана. Тик шулай да статистика буенча яшьләр гаилә корып бала табарга ашыкмый. Дөньяга килгән барлык сабыйларның 60 проценты гаиләдә туган оченче, дүртенче балалар өлешенә туры килә.

– Гаилә турында күзаллаулар үзгәрә. Бүгенге көндә яшьләр төпле итеп уйлап, һәрнәрсәне бизмәнгә салып бара ул адымга. Статистикага күз салсак, узган ел Татарстанда 24182 яңа гаилә теркәлде. Аларның 70 проценты 30 яшькә кадәрге парлар. Өйләнешүчеләрнең уртача яшьләре 28-29 яшь. Әйе, яшьләр гаилә корырга ашыкмый. Иң элек югары белем алырга, эшкә урнашырга, лаеклы хезмәт хакы алырга телиләр. Кызлар әни булырга да озаклап уйлап «өлгерә». Бу сөендерә, ләкин, кызганыч, медальнең башка ягы да бар. Яшь бару белән организмдагы репродуктив система да үзгәрә. Гади итеп әйтсәк, әни була алу чиге кими. 20 яшь белән 30 яшь арасында 10 ел аерма бар. Соң кияүгә чыгучылар өчен ул еллар югала: бер йә ике бала табарлык кына вакыт кала. Хатын-кыз үзе үк вакытны чикли! Яшьләр бу хакта уйлап бетерми. Шуңа күрә Мәгариф министрлыгы белән бергә югары сыйныф укучылары өчен гаилә нигезләре дәресләре әзерләдек. Яшьләр үз әти-әнисенең гаилә моделен генә күреп үсә. Бу хакта башкача гыйлем бирелми.

Гаилә – дәүләт нигезе ул. Россия Президенты Владимир Путин үзенең еллык юлламасында бу фикерне илнең милли идеясе дәрәҗәсенә күтәрде дип саныйм. 2007 елда «Ана капиталы» кертелгәннән соң, бу мәсьәләгә янә туктaлдык. Ни өченме? 90 нчы еллар буыны үсеп җитте. Аларның саны бик аз. Россиядә генә түгел. Сәламәтлекне саклау буенча бөтендөнья оешмасы күрсәткечләрен карасак, XX гасырның 60 нчы елларында Җир шарындагы барлык халыкның яртысы балалар булса, 2050 нче елларга ул инде 20 процентка гына калачак. Бу – уйландыра торган саннар! Шуңа күрә дә гаиләне, ананы, баланы саклау буенча бик күп чаралар үткәрелә. Әйтик, бала табучылар өчен төрле түләүләр булдырылды, төрле программалар гамәлгә ашырыла.

Республикада ай саен ничә бала туа? Аларның ничәсе тулы булмаган гаиләдә?

– Өч мең ярым бала дөньяга килә. Ел буена һәр җиденче сабый тулы булмаган гаиләдә туа. Әлбәттә, малайлар саны күбрәк. Бу инде традиция!

Никахларын рәсми рәвештә теркәми генә яшәүчеләр бик күп. Хәтта балалары тугач та гаилә мөнәсәбәтләрен рәсмиләштерергә ашыкмыйлар...

– Бу вакыт мәсьәләсе генәдер дип уйлыйм. Әйе, бергәләп шактый яшәгәннән соң язылышкан парлар күп безнең. Миңа калса, алар никахларын рәсмиләштергәннән соң, ышанычлырак мөнәсәбәтләргә керәләр. Бу уртак тормышның башка, яңа этабы. Парлар язылышмый икән, димәк, мөнәсәбәтләрдә ихласлык юк. Мин шулай уйлыйм. Димәк, алар бер-берсенә ышанмыйлар, алдыйлар. Әле бит шулай яшәп балалар табалар да, әтиләре сабые-

ның атасы булуын раслатып йөри. Миңа калса, бу – баланы кимсетү. Үскәч, ул бу хакта сорамый калмас. Нәрсә дип җавап бирерләр? Җитмәсә, балада ватык гаилә моделе күзаллавы туачак. Гаиләне рәсми рәвештә теркәп, балага әтиле булу хокукы бирү кирәк дип саныйм.

Гөлшат Рәдифовна, гаилә корып, бала табып үстерү – сөенечле күренеш. Тик көнкүрештә табаксавыт та шалтырамый калмый, һәм ул хәзерге заманда бик еш кына зурга китә. Кызганыч, ничәнче ел рәттән инде аерылышучылар саны кимеми. Узган ел Татарстанда 13316 аерылган парның 65 проценты бергә ун ел да яшәмәгән! Тормыш авырлыклары каршында калган парларга ЗАГСның ярдәм итү мөмкинлеге бармы?

– Аерылышуларның 80 проценттан артыгы суд карары буенча рәсмиләштерелде. Бу килештерү процедурасы үткәрү мөмкинлегебез чикләнә дигән сүз. Әйе, безгә ярдәм сорап килүчеләр дә бар. Һәр гаилә уртак тормышының биш, җиде-сигез һәм ун еллыгында авырлыклар кичерә. Еллар узган саен, үзебез үзгәргән кебек, гаилә мөнәсәбәтләре дә үзгәрә. Моңа карап мөгамәләне көйләргә кирәклеген кайчак белеп бетермибез, йә бөтенләй игътибар итмибез. Узган ел, мин Идарәгә килгәч, һәр ай саен психологларны алып районнарга бара башладык. Район халкы җирле психологка барып чишелергә кыенсына. Ә килгән белгечкә ачылып, проблемаларын сөйләп бирә ала. Безнең психологларның ярдәме тиде, бик күп рәхмәтләр ишеттек. Күпчелек вакытта хатын-кыз аерылышу инициаторы була, чөнки табигатебез буенча бик таләпчән без. Гаиләдә атаның да нинди роль уйнавы мөһим. Яшьләр белән очрашу вакытында гел әйтәм: бала үскәндә әнисенең гаилә өчен нәрсә эшләвен күрә, әтисенең нәрсә белән шөгыльләнгәнен күпчелек вакытта белми ул. Ә моны аңлатырга кирәк. Бала өчен гаилә моделе кечкенәдән үк формалаша. Әти-әни гаилә өчен нишли, бер-берсенә ничек эндәшә, сөйләшә, ярдәм итә – ул барысын да күреп, үзенә «җыя». Үскәч, шәхси мөнәсәбәтләрен әнә шул модель буенча кора. Баланың киләчәктәге гаилә бәхете – ата-ана кулында. Очрашу вакытларында мин һәрвакыт сорыйм: «Гаиләдә иң төп элемент нәрсә?» Йә, сез ничек уйлыйсыз?

Аш өстәле дип уйлыйм...

– Дөреслеккә якын. Ис ул! Син өйгә кайтасың, ә анда ризык исе. Таба ашымы ул, боткамы – мөһим түгел. Гаилә табын янына җыела. Ризык исе гаиләне берләштерә, аралаштыра, якынайта. Ә без ул хакта уйланмыйбыз. Тагын бер мисал. Балык Бистәсендә бер яшь пар белән сөйләшәм. Иреннән киләчәккә планнарын сорыйм. Ул: «Хатын ничек әйтә, шулай булыр», – ди. Хатыныннан сорыйм. «Өйне төзекләндерәсе иде», – ди. Кабат иренә борылам: «Моның өчен син нишләргә уйлыйсың?» – дим. Башын кашый. «Күбрәк хезмәт хакы алыр өчен квалификацияңне күтәрергә, бәлки, өстәмә эшкә урнашырга, үз вакытыңны гаиләңә тулаем багышларга әзерме? Ун елдан сиңа 30 яшь була. Ун ел эчендәниләр эшләргә планлаштырасың?» – дип сорыйм. Ул: «Бу хакта уйланмадым», – ди. Ә кем уйларга тиеш? Тормышта алга таба


Фото: Анна Араханя

барыр өчен шартлар тумый калмый. Шуны вакытында күреп, кабул итеп куллана белергә генә кирәк. Тормыш шул ул! Ә хатын-кыз ир-атны рухландырып торырга тиеш. Менә әйтегез әле, ир-ат иң элек нәрсәгә мохтаҗ?

Назга, аны аңлауга, тыңлауга...

– Юк, иң элек мактау кирәк аңа. Ир-атны мактасаң, аңа канатлар үсеп чыга. Хатыны ни теләсә, шуны эшләячәк. Бу да – бәхетле, ныклы тормышның бер сере. Ә аны күбебез белә, тик кулланмыйбыз гына.

Гөлшат Рәдифовна, быел кәбисә елы. Аның гаилә коручылар өчен берәр тәэсире бармы?

– Яшьләр хорафатларга ышанмый. Киресенчә, быел гаилә коручылар саны 13 процентка артты да әле. Беренче парны 1 гыйнвар көнне үк теркәдек. Чаллыдан алар. «Безнең беренче буласы килә», – диделәр. Мондый тенденция барса, ел ахырына бик матур нәтиҗәләр булыр дип уйлыйбыз.

Гаилә шәхсән сезнең өчен нәрсә ул?

– Минем өчен гаилә – бар нәрсәнең нигезе. Барыбыз да гаиләләрдә үскән. Ата-аналарыбыз, традицияләребез белән горурланабыз. Алар бездә тормыш кыйммәтләрен формалаштырган. Яшәр өчен зирәклек, аң биргән. Кая гына барсак та, гаиләбезгә ашыгабыз. Анда җаныбызга тынычлык, күңелебезгә ямь табабыз. «Битлек»ләребезне салып атабыз, үзебез булып калабыз. Гаиләбезгә кайтып: «Аллага шөкер, без өйдә», – дибез. Моннан да рәхәт нәрсә юк! Ни чәчсәң, шуны урырсың, диләр бит. Очрашулар вакытында яшьләргә әйтәм: гаилә традицияләрегезне булдырыгыз, дим. Без, мәсәлән, һәрвакыт кичке ашны гаилә белән ашыйбыз. Бөтенебез җыелып бетмичә, өстәл янына утырмыйбыз. Безнең әти-әниләр гаиләсендә дә шулай булган. Кичке аш – изге. Мин шулай ук ял көнне туганнарны төшке ашка җыярга тырышам. Мондый күрешүләр бик мөһим дип саныйм. Аралашу, бер-береңнән киңәшләр сорау бик шәп бит инде ул. Дөрес, моның өчен бер тартылу үзәге булырга тиеш. Ул күп ресурс та сорамый, бары тик теләк кенә кирәк.

ЗАГС Идарәсе җырчылар оештырган «Әниләр һәм бәбиләр» социаль проектын гамәлгә ашыруда катнаша. Бу проектның асылы нәрсәдә?

– Анда бөтен гаилә катнаша. Шунысы иң мөһимедер. Әтиләр дә сәхнәгә чыга. Балалар да чыгыш ясый. Гаиләнең мөһимлеген, аның кечкенә бер дәүләт булуын, аны саклау өчен бөтен көчне куярга кирәклеген күрсәтәләр. Районнарда узган концертлар вакытында җирлектә яшәүче күп балалы гаиләләрне сәхнәгә алып менәләр. Гап-гади гаиләләргә иҗади мөмкинлекләрен күрсәтергә менә дигән мәйдан. Балалар тәрбияләү дә бу. Чөнки бергәләп кайда да булса бару, катнашу зур вакыйга, күңелле хатирәләр булып кала ул бала күңелендә.

Килешәсездер, соңгы елларда әдәбият-сәнгатьтә дә, танылган кешеләр арасында да гаиләгә игътибар көчәю күзәтелә...

– Гомумән, уңай гаилә образы һәркайда пропагандаланырга тиеш. Гаиләле булу, яшьләр теле белән әйтсәк, трендта булу дип исәпләнсен иде. Илне генә түгел, кешелекне дә алга алып бару өчен башка юл юк.



Сәхнәдә –

Республиканың бер төркем җырчылары әнә шулай «Әниләр һәм бәбиләр» социаль проектын оештырып җибәрде. Ул «Демография», «Крепкая семья – Ныклы гаилә» федераль проекты кысаларында Мәдәният министрлыгы, Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе ярдәмендә гамәлгә ашырыла. Җырчы Лилия Муллагалиева, Гүзәл Идрисова, Айгөл Шәйхетдинова, Гөлназ Шәрипҗанова һәм алып баручы Замирә Рәҗәпова халык арасында иң популяр, мәгънәләре буенча гаилә кыйммәтләре абруен арттыруга, мәхәббәткә, әти-әни кадеренә, бала бәхетенә багышланган җырлары белән шоу-программа төзиләр. Проектның үзенчәлеге шунда: җырчылар гаиләләре белән тотынган бу эшкә. Әти-әниле, балалы проект ул! Сәхнәдә әтиләр дә җырлый, балалар да үз һөнәрләрен күрсәтә. Шоу-программа шуңа да «0+» тамгасы белән оештырыла. Аны карарга балалар белән киләләр. Антракт вакытында алар өчен аниматорлар, аквагрим һәм фотозоналар каралган. Әлеге проектның тагын бер үзенчәлеге – гап-гади кешеләргә, сәхнәгә менеп, эстрада җырчылары белән чыгыш ясау мөмкинлеге тудырылган. Менә шулай, игелекле башлангыч белән гаиләнең никадәр мөһим булуын тагын бер кат раслый җырчылар.



Лилия МУЛЛАГАЛИЕВА, Татарстанның атказанган артисты, проект идеясенең авторы:

– 2016 елда «Бәби көтәбез әле» җырына клип төшергәндә шушы проектны төзү идеясе туды. Ул ва-



ГАИЛӘ

Татарстан талантлы гаиләләргә бай. Алар безнең проектта катнашып, үзләренең иҗади потенциалын тормышка ашыра, гаилә бәхетенең серләре белән уртаклаша. Әлеге проект яшь парларга фестивальгә әзерләнгәндә көнкүрештән аерылып торып, иҗади сәләтләрен күрсәтергә, бер-берсенә якынаерга, уртак эш өчен берләшергә ярдәм итәр дип ышанабыз.

кытта бишебез дә авырлы идек. Клипта төшкәнче дә концертларда күрешеп, сөйләшеп йөрдек. Авырлы хатын өчен иң якын дус авырлы хатын бит инде ул. Кызыксынулар уртак, сүзләр дә бер тема тирәсендә бөтерелә. Якынаеп киттек. Концертлар оештырырга уйлаштык. Безнең гаилә мәнфәгатьләрен кайгыртуыбызны, ир белән хатын мөнәсәбәтләре һәм аны ныгытуны җырларыбыз аша күрсәтергә булдык. Артист кешегә гаиләне алып бару аеруча авыр ул. Кызганыч, элек тә бик күп танылган җырчылар матур гаиләләр кора алмаган. Артистлар белән танышырга, җитди мөнәсәбәтләр корырга куркып торалар. Без бу стереотипны җимерергә булдык. Җырчы хатын-кызлар да уңган, тырыш хуҗабикәләр, сәхнә кешеләре дә үрнәк гаилә кора ала, һәм алар өчен дә өйдәге якыннар дөньядагы иң мөһим институт ул. Идея авторы буларак, бу концертларны тамашачыга социаль проект итеп бушка күрсәтәсе килә. Без бит җырлап-биеп кенә калмыйбыз: тамашачыны уйландырабыз да, елатабыз да, күпмедер күләмдә өйрәтәбез дә. Һәр районда күп балалы гаиләләрне сәхнәгә алып чыгабыз. Киләсе елдан ул бәйге итеп игълан ителер дип уйлыйм. Шул рәвешле талантлы гаиләләрне барларбыз. Талант бит әле ул җыр-бию белән генә чикләнми. Кемдер бик оста пешерә, кемдер алтын куллы тегүче, кемнәрдер башка төрле һөнәрләре белән үрнәк. Хезмәт яраткан ныклы гаиләләрне халыкка танытасы иде. «Әниләр һәм бәбиләр» брендка әйләнде. Проектны зур фестиваль рәвешендә үткәрү турында да хыялланабыз. Җәй көне, печән өсте башланганчы һәр районда табигать кочагында Сабантуйны хәтерләткән фестиваль рәвешендә уздырасы иде. Үзебезнең үрнәктә күрсәтәсе килә: гаилә корыгыз, балалар табыгыз, рәхәтләнеп күңел ачып яшәгез. Тормышның бар мәгънәсе шунда бит!



Гөлнара ХАФИЗОВА,
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, проектның директоры:

– «Әниләр һәм бәбиләр» социаль проектының максаты – иҗат ярдәмендә гаиләне берләштерү, гаилә кыйммәтләрен, гореф-гадәтләрне, сәламәт яшәү рәвешен раслау, мөнәсәбәтләрне саклап калу һәм үстерү, минемчә. Хәзер чит илләрдә беренче номерлы ата-ана, икенче номерлы ата-ана дигән төшенчәләрне куллана башладылар, без әти-әни абруен үстерүне максат итеп куябыз. Гаиләдә бала өчен әти бик мөһим кеше. Кагыйдә буларак, ир-атның төп бурычы – гаиләсен матди яктан тәэмин итү. Әмма бүген баланың дөньяга карашын дөрес формалаштыру өчен әти кешенең гаиләдәге роле актуаль. Шуңа да проектыбыз максатының берсе: әтиләрнең бала тәрбияләүдә катнашуын күрсәтү. Ата белән бала арасында рухи якынлык булганда гына бала чын шәхес булып үсә.



Замирә РӘҖӘПОВА,
алып баручы,
проектның режиссеры:


– Сәхнәдә берьюлы биш иҗади гаилә! Бу концертта һәр гаилә әгъзасы нинди дә булса һөнәрен күрсәтә. Балаларның сәхнәдә булуы үзе бер куаныч, чөнки киләчәктә көндәшлеккә сәләтле шәхес үстерер өчен аларны һәрьяклап ачарга кирәк. Сәхнә оялу-кыенсынуларны бетерә, сәләтеңне күрсәтергә өйрәтә. Музыка – иң яхшы тәрбия чарасы да ул: матурлыкка өйрәтә. Андый кешенең күңеле чиста була.

Гаиләдә бала туу-тумауны концерт кына хәл итми, билгеле. Ул ир белән хатынның шәхси эше. Безнең проект гаилә кыйммәтләренең дәрәҗәсен арттырып, тамашачыларга үрнәк булыр дип уйлыйм. Сәхнәдәге эреле-ваклы сабыйларга, күп балалы җырчыларга карап, «нигә безгә дә бала тапмаска әле!» дигән уй тамашачыларга килми калмас, мөгаен. «Сезнең концертны карагач, өченчене алып кайтырга кызыктым әле», – дип язалар әнә. Димәк, без дөрес юлда.

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүенең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

Ярты миллионлы тираж белән бөтен СССРга таралучы журнал тышында сурәтләре басылып чыкканнан соң тормышларында нинди үзгәрешләр булды икән аларның? Бу проект шул хакта да... Татарстан тарихында аларның – ул чорда «Азат хатын», бүген инде «Сөембикә» булып басылучы журналыбыз геройларының да салган эзләре бар. Еллар сарысы сеңгән фотолардан елмаючы ул сөйкемле хатын-кызлар – республикабыз кичкән юлларның тере шаһитлары.

ПЕДАГОГЛАР ДИНАСТИЯСЕ




























Фото: Анна Арахамия

Люция ЗАКИРОВА:
«Нәрсә ул бәхет?» дип сорасалар, яраткан эшем, хезмәтем дип җавап бирәм. Җавапны һәркем үз тормыш тәҗрибәсеннән чыгып таба. Гомер үтсә дә, югалмый торган кыйммәтләр була. Иң кыйммәтле хәзинә – кешенең хезмәте».

«Гаиләбезнең иң кадерле ядкарьләре арасында «Азат хатын» журналының да ике саны бар», – дип башланган иде редакциябезгә килгән бер хат. Лениногорск районыннан Люция ханым Закирова яза булып чыкты. Үзе белән күрешкәч тә, сүзебез бүгенге очрашуга җирлек булган шул вакыйгалар турында булды. «Бу хакта бөтен район шаккатып сөйләде ул чакта. Күрелгән хәлмени? Бер гаиләдән апалы-сеңелле ике кызны «Азат хатын»ның тышлыгында бирсеннәр әле!» 1978 елның ноябрь саны тышлыгында кулларына чәкчәк тоткан бер төркем кызлар, шат елмаеп, камерага төбәлгән. Уртада – сары камзуллысы – бүгенге героебыз Люция Закирова үзе.

Бар белемен, тырышлыгын балалар укытуга багышлаган бу ханым – атаклы укытучылар династиясенең бер вәкиле. Зиннуровлар гаиләсе – Лениногорск районының горурлыгы. Бер гаиләдән биш кыз – бишесе дә укытучылар! Аптырыйсы юк, әтиләре Шамил абый Зиннуров үзе дә укытучы бит! Әле ул гына да түгел, Шамил абыйның бертуган апалары Фаһирә һәм Зәйтүнә дә гомер буе балаларга аң-белем таратучылар.

Люция ханымны мәктәпкә илтүче сукмак исә бераз гына бормалырак. Балачакта артист булырга хыялланган кыз, мәктәптән соң укуын Алабуганың мәдәни-агарту училищесында дәвам итә. Дипломлы белгечне Чаллы шәһәренең мәдәни бүлегенә юллыйлар. «Азат хатын» тышлыгында дөнья күргән фото да әнә шул чакта – инспектор булып эшләгән вакытында төшерелгән. Район Сабан туенда чыгыш ясарга әзерләнеп торган мәлләре... Эшен яратса да, Люция ханымның күңелендә бер талпыну яши – әтисе һәм туганнары кебек, аның да укытучы буласы килә.

– Кан тарткандыр, күрәсең, өйрәнгән эшемне калдырып, Алабуга педагогика институтына укырга кердем, – дип, шул чакларны искә төшерә Люция Шамилевна. 1985 елны Чаллының 6 нчы урта мәктәбенә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып килә. Яратып, бирелеп эшли. Аның һәр дәресе үзенә күрә бер спектакль була. Менә кайда кирәк икән училищеда алган белеме! Люция апалары мәктәпкә чана-чаңгылар күтәреп килә икән, һич тә тау шуарга түгел, ә – фигыль формаларын үтү өчен. Тегәргә һәвәслеге дә ярап куя – дәресләрне үзең теккән курчаклар белән курчак театры рәвешендә уздырсаң, балалар тизрәк төшенә, исләрендә ныграк калдыра. 45 минутлык дәрестә укытучы да ул, режиссер да, артист та... 1992 елны аны Чаллы коррекцион мәктәбенә эшкә чакыралар. Үзенчәлекле балалар белән теләсә кем эшли алмый. Анда үз укучыларын нәкъ менә Люция Шамилевна кебек ихлас яраткан укытучылар кирәк.

Кайда гына эшләсә дә, үз принципларына тугры кала ул. Балаларны һәм эшне ярату, вакыт узсынга түгел, эшенең нәтиҗәсе булсын дип тырышу – менә аның принциплары.

Люция ханым – барыннан да бигрәк иҗат кешесе. Төрле матбугат битләрендә басылып чыккан язмалары, шигырьләре, очерклары шул хакта сөйли. Күбесе балалар тәрбиясенә, мәрхәмәтлелек, ихтирам тәрбияләүгә багышланган. Соңгы елларда күп вакыты архивларда үтә – шәҗәрәләр төзи, солдат хатлары буенча эзләнү эшләре алып бара. Үз эшенә булган мәхәббәтне кызларына да күчерә алган ул. Люция ханымның ике кызы да педагог. Династия дәвам итә, димәк.

Лилия ГӘРӘЕВА

PRESSA

ӘСТЕРХАННАН КАЗАН КҮРЕНӘ!



Раилә
ХӘЯЛИЕВА

Язмамны мин һәр иртәсен мундир киюдән башлаган эшлекле хатын-кыз – Әстерхан таможнясының матбугат үзәге җитәкчесе турында язуга багышлаган идем. Соңгы ноктаны куярга да өлгермәдем, яңалык килеп иреште: «Астрахань-24» телеканалына талантлы идарәче, журналистикада азу ярган, һәркем белән уртак тел таба белгән яңа җитәкче – Динара МӘҖИТОВА билгеләнде», диелгән иде анда. Ышанам, героемның карьера баскычы никадәр генә текә булса да, ул күңеленнән барлаган изге ниятеннән – милләтенә хезмәт итүдән барыбер туктамас әле! Моңа чаклы да шундый булган ул...

без булдырабыз « Безнең тышлыкта

Урамда таныш булмаган баланың: «Сәлам, Динара апа!» – дип, туган телдә эндәшүенә ияләштем инде.

Көндез башланган әңгәмәбез шактый озак дәвам итте. Төн уртасы якынлашып килә иде инде. Ә ул, эшләрен әле яңа гына тәмамлаган да, өенә юл алган. Иртәгә Мәскәүгә командировка. Әлегә элемтәдә – Казан.

– Күрәсезме, мәшһүр манараны? Безнең Татар бистәсендәге Кызыл (үзәк) мәчет ул. Ерак түгел Ак мәчет урнашкан, Нугай мәчете дә күренеп кенә тора. Урам очында «Татар базар» шаулый, Казан урамыннан җәяүлеләр йөри. Әстерхан миллениумга кадәрге Казанны хәтерләтә шулай. Шәһәребез 12 утрауда урнашкан. Бу яктан Венеция белән охшаш. 27 күпер бар. Безнең шәһәрдән соң Идел мең елгачыкларга тармаклана, һәм алар барысы да Каспий диңгезенә кушыла. Бездә зур агачлар үсми. Шуңа күрә агачтан өй, мунча салу бик кыйммәткә төшә. Безнең стихия – кояш, су, җир...

Динара ханым канатлана-канатлана Әстерхан, анда яшәгән татарлар турында сөйли. Телефон экранынннан әле шәһәр утлары күренеп кала, әле мәчет манаралары яктырып уза. Әкренләп Казан белән Әстерханның тарихи бәйләнешләрен сүтәбез, биредә яшәүче татар яшьләренең киләчәген фаһемләргә тырышабыз...

Тамырларым

– Бүгенге көндә Әстерханда 60 меңнән артык татар яши. Әстерхан өлкәсе – Россиянең көньягындагы җирле халыкның бер өлеше, нигездә, татарлар булган, татар рухы сакланган үзенчәлекле төбәк, – ди Динара ханым. – Бездәге татарларның тормышны кабул итүе дә, темпераменты да үзгә. Елына ун ай кояш кыздырган җирдә яшибез бит! Татарлыклары белән горурлану хас якташларыма, бер-берсе белән очрашсалар, уртак телне бик тиз табалар. Өлкәдә 16 татар авылы бар. Әстерханның электән үк татар мәдәнияте учагы булуы мәгълүм. Шәһәребездә 1907–1941 елларда Әстерхан Татар дәүләт драма театры эшләгән. Ябылып, күпмедер вакыт узгач, татар актерларын туплап яңадан Татар халык театры оештыралар. Театрның ишекләре әле дә ачык, спектакльләр карарга йөрибез. Татар ансамбльләре, җыр-бию студияләре эшли. Тукай исемен йөрткән скверыбыз бар, Муса Җәлил урамы, шагыйрьләргә куелган һәйкәлләр, Тукай исемендәге мәктәп... Сулышыбыз киң, татарлар иркен яши, Аллага шөкер. Тукай исемендәге мәктәптә башлангыч сыйныф укучылары татар телендә укыйлар. Җирлек үзенчәлекләренә хас булганча, авылда яшәүче күпчелек татар гаиләләре бакчачылык белән шөгыльләнә.

Әнием – Әстерхан татары. Әтием тумышы белән Татарстанның Алексеевский, Чистай якларыннан. Әти ягыннан мин Шәрәфетдиновлар нәселенә барып тоташам. Дәү әтиемнең сугыштан алып кайткан чирләренә дәва булсын дип, заманында Каспий диңгезе буена күченеп килгәннәр. Әни ягыннан – Әстерханда хөрмәтле нәсел, дәүләт эшлеклеләре булган Абдуллаевлар кызы мин. Абдуллаевлар үзләренең укымышлылыгы, хатын-кызларының мәгърифәтле булуы белән аерылып торган. Әнием Фирүзә – зур гаиләнең кече кызы. Аның әби-бабасы Дагстанда яшәгән. Ул яклардагы татарлар җирле халык белән дә дус булган, үзебезнең гореф-гадәтләрне, йолаларыбызны да кадерләп саклый белгән. Ә иң мөһиме – олыларга ихтирам, кадер-хөрмәт күрсәтү монда яшәгән һәркем өчен уртак тәрбия булган. Әби-бабаларымның иң зур казанышы – барыбыз да дус, барыбыз да бербөтен дип, төрле милләтләр кушылып яшәгән Советлар Союзы чорында татар гаиләләрен булдырганнар, нәселне катнаш никахлардан саклап кала алганнар. Туган җирдән читтә яшәсәләр дә, үз мәдәниятен югалтмаганнар. Әти белән әнием дә Дагстан җирләрендә танышып, шунда гаилә корган. Ә инде туксанынчы елларда, илдә зур үзгәрешләр башлангач, Әстерхан шәһәренә күченгәннәр. Ләкин әтиемне һәрвакыт кендек каны тамган Ватаны тарткан. Озак уйланып йөргәннән соң, безне Казанга алып кайтып китә ул. Мин Казан дәүләт университетының юридик факультетын тәмамладым. Кызык бит, язмыш мине янәдән гаилә җепләренә урап, Әстерханга тартып китерде. Тагын да гаҗәбрәге: тамырлары белән кубып кайткан әтием белән әнием дә безнең белән күченделәр. Туган җир дип омтылса да, Казанда чакта әтием көньякның йомшак җилен, юмарт кояшын, йөзем агачларын сагынып яшәгән икән. Кызганыч, күптән түгел генә әтием бакыйлыкка күчте. Ул безнең төп терәгебез, тормышның җаен белгән бик көчле кешебез иде. Әти киткәч, әнине үз яныбызга алдык. Оныклар өчен дәү әни белән аралашып үсү бик мөһим.

Йодрык көче

Безнең якта «духум» дигән сүз бар. «Духум белән яшәү» – нәселең белән бердәм булып яшәү игъни. Минем балачагым туганнар арасында узды. Әнием ишле гаиләдән булгач, аның туганнарының балалары белән гел бергә булдык. Хәзер дә бик якын итеп аралашабыз, иң якын дусларым да – абыйларым. Кечкенә чакта бабам, учын йомарлап, безгә: «Без барыбыз бергә, бер йодрыкта булганда көчле», – дия иде. Ә әти ягыннан туганнар чын мишәрләр: эш, өй, гаилә өчен янып торалар. Безнең нәселнең язылмаган зур кагыйдәсе – син үз динеңдәге кеше белән генә гаилә кора аласың. Балачактан сеңдергән бу зирәк тәрбия мисалларын хәзер үземнең гаиләмә күчерергә тырышам. Әлбәттә, заман башка, аралашулар, мөнәсәбәт корулар да үзгә. Әмма гаиләнең һәрвакыт зур җаваплылык икәнен яшь буын аңлап үссен иде!

Минем дүрт балам бар. Игезәк улларым – 19 яшьләрен тутырып килүче Адель белән Булат Әстерхан дәүләт университетында биомедицина һәм генетика бүлегендә белем алалар. Параллель рәвештә Идел буе физик культура, спорт һәм туризм академиясендә

Фото: Альберт Дунбоянов

Бездә татарлык белән горурлану хисе бигрәк тә көчле кебек.

укыйлар. Академик ишү буенча Көньяк федераль төбәк җыелма командасы өчен чыгыш ясыйлар, төрле чараларда актив катнашалар. Сәламәт тәндә сәламәт акыл гыйбарәсе борынгы булса да, хак ул. 16 яшен тутырып килүче Тимурым абыйларыннан нык аерыла. Характеры бик кискен, ул бер үк вакытта йомшак та, кырыс та, конфликттан курыкмый, гаделлек өчен һәрвакыт көрәшергә әзер егет. Тагын бер улым бар әле минем. Олы апам мәрхүм булгач, аның малае Русланны үзебезнең гаиләгә алган идек. Аңа инде 24 яшь. Минем өчен бик кадерле, якын кеше ул! Кызым Асиягә 8 яшь. Гаиләдә кыз бала тугач, гел нәфислек, наз, йомшаклык кына булыр дип күз алдына китерә идем. Асиягә күбрәк абыйларының холкы күчә: нык ихтыярлы булып үсеп килә әнә. Һәрбер әни кебек, мин дә кызым белән бергә бәлеш, пылау пешерергә яратам. Татар кызларының куллары кечкенәдән эшкә ятып, камырга батып үсәргә тиеш, диләр бездә!

Шөкер, эшкә дә, балаларым белән бер дулкында булырга да өлгерәм. Үзем кебек, балаларымның да гаиләбезнең өлкән буыны белән аралашып, аларның кул җылысын тоеп үсүләренә шатланам. Дәү әтиләре



Фирүзә ханым онышклары Адель, Булат һәм Асия белән.

алар өчен авторитет иде. Әнием гомер буе югары партия хезмәткәре булды. Мин кечкенәдән эшлекле хатын-кыз образын күреп, шуңа омтылып үстем. Без әни белән икебез дә елның бер үк көнендә – 21 апрельдә туганбыз. Әнием мине үзенең 30 яшьлегенә алып кайткан. Ул әле дә эшли, әле дә биек үкчәле туфлиләрдән йөри. Чыннан да заманча әби ул безнең! Әнием Фирүзәнең «Яхшылык эшләргә курыкмагыз!» дигән сүзләре минем тормыш девизына әйләнде. Бик дипломатик хатын-кыз ул. Аның йогынтысы белән безнең өйдә «рәхмәт», «зинһар өчен» кебек матур сүзләр еш яңгырый. Безнекеләр кайвакыт башка шәһәрләргә баргач: «Автобуска кергән олы кешегә сикереп торып урын бирсәк – шаккатып карап торалар. Урамда авыр күтәренеп барган әбигә булышмакчы булып сумкасын алырга теләсәк – тарткалаша ук башлыйлар», – дип гаҗәпләнеп сөйлиләр. Безнең якларда олыларга хөрмәт күрсәтү – беренче урында.

Кияү сые, конфет туе

Киләчәктә балаларыма чын татар туе уздырасым килә! Бу – иң зур теләгем. Әстерханда татар туйларын элеккедән калган гореф-гадәтләрне саклап, бик зурлап үткәрәләр. Сөйлимме? Иң элек «кәнфит туе» була. Егетнең әти-әнисе кәләш гаиләсе белән танышырга барганда күчтәнәчкә күп итеп конфет алып бара. Конфет янына чәй, шоколад, төрле тәм-том да мул итеп куела. Ул конфетларны, яшьләргә бәхет теләп, кунакларга тараталар, бигрәк тә кияүгә чыкмаган, өйләнмәгән яшь егет-кызларны сыйлыйлар, ә яртысын кире кияү ягына биреп җибәрәләр. Кыз ягына никахка килгәндә егет ягы «тугыз» алып килергә тиеш. «Тугыз» – купшы итеп бизәлгән тугыз подноска кыйммәтле бүләкләр салып килү дигән сүз ул. Егет ягы никахка Саратов гармуннарын уйнатып, бал мичкәләре тотып, бөтен туганнары белән бик зурлап килә. Килен ягы матур итеп каршы ала, өстәлгә утырта. Аннары бүләк алмашу була. Әстерханда яшьләр ике тапкыр туй үткәрә. Беренчесе – кыз ягында «Кияү сые», ягъни кияү сыйлау уза. Бездә туйларга 200–300 кешедән дә ким чакырмыйлар. Ике яктан да зурлап, бөтен нәсел җыела. Кыз ягындагы туйдан соң егет ягында туй уза. Язын башланган туйлар, көзгә кадәр дәвам итә.

Әйдә, милләткә хезмәткә!..

1905 елда Петербургта беренче татар газетасы «Нур» нәшер ителсә, Әстерханда 1907 елда «Идел» газетасы чыга башлый. «Идел» газетасы, дөнья, Россия хәбәрләре белән бергә, Хаҗитархан шәһәре, тирә-якта яшәүче төрки халыкларның һәм, әлбәттә, татарларның милли яшәешен яктырта. Сәгыйть Рәмиев, Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури исемнәре белән бәйле әлеге тарихи басма бүген дә нәшер ителә. Бу газетаның баш мөхәррире булырга тәкъдим алгач, башта икеләнеп калган идем. Ерак тарихы булган басманы җитәкләү – горурлык та, шул ук вакытта зур җаваплылык та сорый торган хезмәт. Көн саен яңалык, дөнья бертуктаусыз

үзгәреш юлыннан атлый. Шул темп белән барырга, син дә һәр көнне яңарып торырга, киләчәккә карап фикер йөртергә тиеш буласың. Табигатем белән мин – оештыручы лидер. Хокукый ягын да әйбәт аңлыйм. Тәвәккәлләп, бу эшкә алынырга булдым. Игътибарны җәлеп итәрлек язмалар әзерләү, спонсорлар эзләү, грантлар алу... Эш дәверендә үзем өчен дә яңа белем туплый бардым. Газета чыгару ул – мәкалә язу гына түгел, PR юнәлешендә дә көчле булырга кирәк. Хезмәткәрләремнән дә һәрвакыт заман белән бер тизлектә яшәүләрен, актуаль белем алуларын таләп иттем. Казанда Төбәк һәм милли гаммәви мәгълүмат чаралары форумында булган идем. Шунда Этникара журналистика гильдиясе белән таныштым. Алар туган телендә нәшер ителүче милли басмаларны саклап калырга тырышучы уникаль кешеләр булып чыкты. Милли теманы яктыртучы журналистика бик җаваплы юнәлеш. Мондый темаларга язган журналист бик гыйлемле булырга тиеш: бер сүз белән илләрне, халыкларны дуслаштырып та, сугыштырып та була. Мине бу идея бик мавыктырды. Шулай итеп, бездә Этникара журналистлар гильдиясенең Әстерхандагы бүлекчәсе барлыкка килде. Этникара журналистика дигән юнәлешнең актив эшчәнлеген алып барабыз. Милләтара темаларга язучы татар журналистлары белән эшләү бик зур дәрәҗә ул. «Идел» газетасы миңа менә шушы тәҗрибәне бирде.

Әмма кайда гына эшләсәм дә, беренче чиратта җәмәгать эшләре активисты булып калам. Әнием үрнәге дә, студент чактан калган гадәт тә, ә бәлки, табигатемә салынган төп сыйфаттыр да бу. Мөмкинлекләр барлыкка килүгә үземнең татар мәйданын оештырдым. «Бәйрәм» милли үзәген ачтым. Яшьләр өчен оештырган кичәләр бик уңышлы барды ул чорда. Безнең чараларга икешәр мең кеше килә иде. Татарлар дөньясына багышланган иҗтимагый тормышка шулай кереп киттем. Бу юнәлештә уңышлы эшчәнлек алып барырга булышып торучы остазым, «Дуслык» татар оешмасы җитәкчесе Әнвәр Алмаевка рәхмәтлемен. Ул миңа бик күпне өйрәтте. Әстерханда берничә татар оешмасы эшләп килә. Аларның һәрберсенең максаты бер – телне, милләтнең киләчәген саклау. Без һәммәбез дә милләткә хезмәт итү юлында.

Татарлар килә!

2008 елда беренче тапкыр Әстерхан өлкәсендә «Татар кызы» конкурсы уздырган идек. Елдан-ел уңышлырак, популяррак була барды әлеге бәйге. Катнашучы яшьләр саны артты, тамашачылар көтеп ала торган булды. Төрле еллардагы җиңүчеләрне җыеп, бәйгенең ун еллыгын уздырдык. Ул кызлар инде әни булган, үз тормыш тәҗрибәләре бар. «Татар кызы»ның бу зур тамашасында мин киләчәктә бу бәйгене оештыруны рәсми рәвештә яшьләр оешмасына тапшырдым: эшнең дәвамчылары булырга тиеш. Һәр эштән матур итеп китә дә белү мөһим. Узган ел «Татар гаиләсе» бәйгесен ял базасында, гаиләнең бер бәхетле көне итеп уздырдык. Быел менә офыкларны киңәйтеп, «Татар гаиләсе» конкурсын көньяктагы өлкәләрне һәм Кавказны колачлап оештырырга җыенабыз. Кызыксынып, янып, «Татар гаиләсе» бәйгесен дәрәҗәгә санап катнашсыннар иде! Конкурска катнаш гаиләләр килүенә дә каршы төшмибез. Бәйге атмосферасына чумган гаиләнең татар булмаган әгъзасы да милли мәдәниятебез белән кызыксына, халкыбыз тарихын белә башлый. Гаиләдә мөнәсәбәтләр яхшыра, хатыны яки ире өчен горурлык хисләре уяна. Бергәләп татарча шигырьләр ятлыйлар, җырлар өйрәнәләр. Катнаш никахлар белән күбрәк эш алып барсак, алардагы балалар татарлыкны сеңдереп үсәчәк бит.

Татарстанга рәхмәтле мин. Чит өлкәдә яшәүче татар балаларын төрле проектларга, лагерьларга чакыралар. «Сәләт»кә, «Идел» яшьләр үзәге оештырган «Милләтебез хәзинәләре», «Лидерлар мәктәбе» лагерена барып күпме егет-кызларыбыз милли рух сеңдереп кайта! Балаларның документларын, юл мәшәкатьләрен җайлау, оештыру, каршы алу-озату эшләре белән ун еллап шөгыльләнәм инде. Улларымны җибәрәсе, шул хәрәкәткә катнаштырасы килеп башланган эш иде. Ә нәтиҗәләрне күреп үзем дә шаккатам. Ул лагерьларга татар гаиләләрендә үсеп тә, татар телендә сөйләшмәүче балалар бара бит. Татарча рэп укырга өйрәнәләрме, әллә үртәшергәме – мөһим түгел, ул балалар татарча сөйләшүдән уңайсызланмаска ияләшеп кайта. Кайткач, «Әлифба» алып, татарча өйрәнергә утырмасалар да, тел белән кызыксынулары уяна! Икенче, өченче тапкыр баргач, тагын да күбрәккә өйрәнәләр. Әтиәниләренә, нишләп безне элегрәк татарчага өйрәтмәдегез, минем белән ни өчен татарча сөйләшмисез, дип әйтүчеләр дә булды. Алар Татарстаннан рухланып, ялкынланып кайта! Яхшы вузларга керергә омтылалар, мәгънәле кеше булу турында уйланалар. Соңгы елларда яңа күренеш менә: бу лагерьларга йөрүче яшьләрдән туйга чакырулар килә башлады! Куаныч бит: яңа татар гаиләләре туа! Безнең аркылы Татарстандагы чараларга баручы Ростов, Волгоград, Кырым, Краснодар, Махачкалада актив татар яшьләре формалаша, аларны үзара дуслык җепләре бәйли, татарча аралашу мохите барлыкка килә, кайткач та бергә җыелышалар, элемтәдә торалар. Ватан, туган тел, милләт төшенчәсе барлыкка килә! «Ә сез беләсезме, татарлар гомергомергә укымышлы, мәгърифәтле булган! Чит телне генә түгел, татар телен дә белергә кирәк! Чын татар булу, телне белү өчен Казанда гына яшәргә димәгән! Татарларның киләчәге – ул без!» дигән канатлы сүзләр белән сөйләшә башлый бит алар. Вокзалда саубуллашканда «Татарлар килә!» дип җырлап торган баласына карап һәр әти-әнинең йөрәге кысылып куйдыр кебек тоела миңа. Андый вакытта күңелдә нидер уяна, тамырлар калка сыман...

Тышлыкта һәм язмада кулланылган фотолардагы образларның авторы: Альбина САДЫЙКОВА.
Макияж: Мәдинә ПЕРЕПЕЧКИНА.

ҮЗГӘРӘСЕМ КИЛӘ!



Гөлнур
САФИУЛЛИНА

**– Миңа аның кирәге юк...
Язманы укыгач, мөгаен, шулай уйлап куючылар булмый калмас. Әйе, беренче мөрәҗәгать иткәнчегә кадәр кирәге юк. Ә аннан... Шопер турында әйтәм. Голливудта барлыкка килгән бу һөнәр менә безгә дә килеп җитте. Шопер-шәхси стилист чынлыкта психотерапевт белән бер ул: берсе – күңелеңнең түренә үтә, анда тәртип сала, икенчесе – гардеробыңда. Шопер кием шкафыңның ишеген ачуга, аның синең тормышта шулкадәр җитмәгән булуын шунда ук аңлыйсың...
Лилия ИСМӘГЫЙЛЕВА – Казанда иseme күпләргә билгеле шәхси стилистларның берсе. «Татарстан–Яңа гасыр» каналында баручы «Мин» тапшыруының эксперты. Аның эш урыны – шәһәрнең барлык сәүдә үзәкләре, бутиклар, шоурумнар... Һәм Казанныкы гына да түгел! Айдар Галимов, Гүзәл Уразова кебек сәхнә йолдызлары: «Ничек киенергә?» – дип киңәш сораган белгечтән шопер һөнәренең үзенчәлекләре турында сорашабыз.**

Лилия, синең ничек стилист-шопер булып китү тарихыңны ишетәсе килә.

– Белемем буенча икътисадчы мин. Казан химия-технология институтының икътисад факультетын тәмамладым. Кечкенәдән җырлап үстем – бу юнәлештә дә үсәргә уем бар иде. Ләкин әни ягы җиңде – ул да бухгалтер безнең. IV курста укыганда кияүгә чыктым. Беренче баламны тапканчы, автосалонда эшләргә туры килде. Ул чакта стилист-шопер сүзенең ни икәнен ишеткән юк иде әле, әмма танышбелешләрне, дусларны киендерә идем инде. Әлбәттә, бушка. Бу эш ошый иде миңа! «Син бит кием сайлый беләсең, булышмассыңмы?» – дип сораган берәүне дә кире бормадым. Кемдер ябыккан – 100 килограммнан 60 ка калган: бер киеме дә ярамый, икенчеләре фотосессиягә барырга җыена – нәрсә киярга белми... «Ә нигә син моның өчен аз булса да акча алмыйсың?» – дия башладылар. Бер уйласаң, чыннан да, дөрес: мин бит моңа вакытымны сарыф итәм.

Бала тугач, бу эш белән чынлап торып шөгыльләнә башладым. Казанда андый курслар юк иде әле, мастер-классларга күбрәк Мәскәүгә йөрдем, Беренче канал стилистларына – Марианна Елисеевага, Александр Роговка.

Кемне – нәрсә, ә мине матурлык рухландыра! Бу миңа, мөгаен, гаиләдән киләдер. Бер яктан, безнең һәркайсыбыз икътисадчы, әмма шул ук вакытта иҗат кешеләре дә. Балтач районы Көкшәкбаш авылында туып-үстем. Бик кечкенә генә авыл ул. Мин мәктәпне тәмамлагач, безнең гаилә район үзәгенә күченде. Әти гомер буе диярлек районның сөт-май комбинатында өлкән бухгалтер булып эшләде, әмма ул җырмоңга гашыйк – баянда уйный. Ә әнинең ике югары белеме бар: ул – икътисадчы һәм педагог. Дизайнер курсларын да тәмамлады. Кайда яшәсәк, шунда өебез матур булсын дип тырышты. Матурлыкны күрә дә, таба да, тудыра да белә! Абыйның да (ул инженер-архитектор һөнәрен сайлады), минем дә матурлыкка тартылу – тумыштан.



Һәр көнне иртәдән кичкә кадәр шушы эш белән мәшгульмен хәзер. Ялым да юк. Улым кайчак: «Әни, син нигә бер дә ял итмисең?» – дип сорый. «Улым, мин көн саен ял итәм!» – дим. Бер яктан, әйе, арыйм: иртәнге сәгать уннан кичке унга кадәр – кибетләр ябылганчы эшлим бит. Икенче яктан – бу эшне яратам: ул минем өчен хобби кебек. Көнгә өчәр клиент киендергән чакларым бар. Айга 90 кеше дигән сүз бу. Ул гардеробның нинди зур булуын күз алдына китерәсезме?! Һәм моның өчен күпме кибет ураганымны! Бер сәүдә үзәге генә түгел, Казандагы бөтен кибетләрне дисәң дә ярый. Фотосессияләргә әзерләү буенча да бик күп мөрәҗәгать итәләр. Анысын күбрәк онлайн эшлим: клиент белән күзгә-күз очрашмыйбыз, алар миңа фотоларын гына җибәрә. Кибеттә киемнәр җыеп калдырам – алар шуннан барып кына ала. Бу очракта элегрәк фотосурәтләр белән мавыгуым бик ярдәм итә. Фотограф һөнәренә декрет ялында утырган чакта укыдым. Сүз уңаеннан, инглиз теле курсларына да шул вакытта йөрдем. Бик иҗади эш ул фотосурәткә төшерү, аннан китәрмен, фотоппаратны ташлармын дип уйламаган идем. Ләкин гаилә, балалар белән авыррак шул: бер сәгать төшергәнеңне төннәр буе эшкәртергә дә кирәк. Ике мавыгуымның берсен сайлау алдында калгач, стилист-шоперга тукталдым. Монысы рухыма якынрак, әмма җиңелрәк дип әйтә алмыйм. Сине ишетсеннәр, аңласыннар өчен психолог та булырга туры килә. Тагын – икътисадчы да: мин клиентка аның акчасын һәм вакытын янга калдырырга булышам. Кибетләрдә нәрсә барын, аларның урынын – кайсы кайда эленеп торганын беләм. Вакытны беркайчан бушка уздырып, кибетләр буенча эзләнеп йөрмибез: туп-туры кирәк элгечкә барабыз. Һәм ике сәгать эчендә шактый бай гардероб туплыйбыз. Ни өчен ике сәгать дим, чөнки клиентны шуннан артык йөртмәскә тырышам. Озакка китсә, кием ошыймы-юкмы икәнен аңламый башлый.

Клиентка яңа образ сайлау нәрсәдән башлана?

– Миңа башта аның эчке дөньясын күрергә кирәк. Нәрсә белән шөгыльләнүен, кайда эшләвен, ниләр белән кызыксынуын сорашам. Гардероб базасы кешенең тормыш рәвешенә бик нык бәйләнгән, ул һәркемдә бертөрле була алмый. Кеше белән аралаша башлауга аның образы инде күз алдыма килеп баса: уем белән аны «киендерергә» керешәм. Әйбәт стилист булып җитешү өчен иң беренче чиратта тәҗрибә кирәк. Һәр көнне төрле-төрле фигура белән очрашасың, һәм синең максатың – андагы кимчелекләрне кием ярдәмендә яшерергә ярдәм итү. Кемдер: «Эше бигрәк җайлы. Кибет буйлап йөреп, кешегә матур кием сайлауның нәрсәсе бар инде аның?» – дияргә мөмкин. Модадагы соңгы яңалыклардан хәбәрдар булу, кайсы кибеттә нәрсә сатканнарын белү – нәрсә кияргә икәнен беләм дигән сүз түгел әле ул. Әйткәнемчә, һәр кеше индивидуаль. Бөтен нәрсәне дә исәпкә алырга кирәк: гәүдәсен, буй-сынын гына түгел, чәч, күз, тән төсен дә. Әйтик, алсу төснең әллә ничә төсмере бар, һәм аның берсе тән тиресен – саргайта, икенчесе – кызарта.

Кемдер аерым бер төсне ярата, тик күп вакыт аның үзенә бөтенләй килешмәгәнен аңламый.

Ничек киенүебез күңелебездәге хисләргә бәйле: һәркем кием аркылы башкаларга үзе турында нидер җиткерә. Әйтик, эшлекле очрашуга барасың: әңгәмәдәшеңнең ничек кабул итүен теләр идең? Яки гашыйк булдың, ди, беренче тапкыр якыннан күрешәсез: сөйгән ярыңа ничек күренәсең килә? «Мин бик тыйнак шул, күләгәдә калуны хәерлерәк күрәм», – дияр кемдер. Моның белән килешмим: һәркем кием белән үзе турында «сөйләргә», нидер җиткерергә тиеш. Кайберәүләрне дөрес юлга кертеп җибәрү дә стилист-шоперның бурычы дип саныйм. Әйтик, шактый ачык кием-салым сайларга тырышучылар бар. Андыйларны ябындыру бик авыр. Мондый очракта алтын урталык табарга тырышам: кешенең үзенә сиздермичә генә психолог вазыйфасын да башкарам. Турыдан-туры: «Сиңа җилбәзәк дип караячаклар, шундый тәэсир тудырасың», – дип әйткән чаклар да бар. Әйе, клиентка болай әйтә алам, чөнки безнең арада шактый якын мөнәсәбәтләр урнаша. Башкача була да алмый: кеше синең алда чишенә, барлык кимчелекләрен күрсәтә. Мин кайчак хәтта үземне табиб кебек хис итәм. «Эчем чыгып тора», «бер аягым кыскарак», «күкрәгемнең бер ягы кечкенәрәк», ди алар. Бөтен тормышларын сөйләп чыгарга өлгерәләр!

Стилист клиентның җанын, күңелен үзгәртү белән дә шөгыльләнә. Моның өчен аңа үз сүзеңне ишеттерә белү кирәк. Кайчак башта: «Тәнкыйтьне кабул итәсеңме?» – дип сорыйм. Миңа килгән кеше аны ишетергә әзер.

Сиңа мөрәҗәгать итү өчен кешенең кесәсендә күпме акча булырга тиеш?

– Һәр клиент белән очрашкач: «Бюджетыгыз ничегрәк?» – дип сорыйм. Бу миңа беренче чиратта, вакытны чамалау өчен кирәк. Әгәр аңа кышкы кием дә, җәйгесе дә кирәк икән, гадәттә, бер сәүдә үзәге белән генә чикләнмисең, башка кибетләргә, шоурумнарга да китәсең. Һәркем үз бюджеты белән килә, әлбәттә. Ким дигәндә 20 мең кирәк, дим. Бер-ике ел элек «распродажа» вакытында 6 меңгә дә киендергәнем булды: 1 меңгә чалбар, 500 сумга итәк, футболка... Шактый кием җыйган идек. Берьюлы 300 меңгә дә киендергәнем бар. Клиентларым белән Мәскәүгә дә баргалыйм. Анда да килүемне көтеп торучылар бар. Киләчәктә хыялым – клиентларны Миланга алып бару.

Ирләрне миңа күбрәк хатыннары җибәрә: башта үзләре килә, аннары ирләрен кодалый.

Хатын-кыз кайсы яшьтә үзгәрү турында күбрәк хыяллана?

– Клиентларым төрле яшьтәгеләр. Бала тапкач килүчеләр бар. «Моңарчы гел ак күлмәк белән кара итәктән йөрдем. Хәзер тормышым, яшәү рәвешем бөтенләй үзгәрде, нәрсә кияргә белмим», – диләр. Яки, киресенчә, декреттан чыгучылар мөрәҗәгать итә: «Әле бер көн дә эшләгәнем юк. Офиста утырачакмын, кием сайларга булыш», – диләр. «Соңгы вакытта тазардым, үземне яратмыйм. Бәлки, яңа кием аша үземне ошата башлармын», – диючеләр бар. Берничә килограммга артуга, хатын-кызда комплекс башлана.

Гардеробка ревизия ясаганда күп әйбер ташлыйсыңмы? Барлык хатын-кызларда да проблема бер үкме: «Шкаф тулы, тик кияргә генә кием юк»мы?

– Төрле гардероблар була. Мәсәлән, кемдер 20 ел элек базардан шундый күп кием алган һәм: “Тузмаган, әйбәт бит әле», – дип, ул бүген дә һаман шуларны киеп йөри. Клиентның өенә баргач, шкафны тулысынча бушатабыз. «Болар инде хан заманыннан калган», – дип, кайсын бер кучкә өям. 20 һәм 40 яшьләрдәге хатын-кыз бертөрле киенә алмый бит. «Болары инде яшеңә дә, статусыңа да туры килми», – дим. Кыйммәтлерәк кием-салым алу турында сүз бармый. Дөрес киенгән очракта аңлашылмаска тиеш: әллә 1 миллион сум тора ул күлмәк, әллә 1000 сум... Гардеробны бушаткач, исемлек төзибез: нәрсәләр алырга кирәк? Икенче көнне исә кибеттә очрашабыз.

Кием сайлаганда, гадәттә, нинди ялгышлар ясыйлар?

– Кызганыч, киенә белүчеләргә караганда, белмәүчеләр күбрәк шул... Киемгә акча түгүне мәгънәсез эш дип санаучылар байтак. Элек кием-салымга акча күп тотмаганнар, бала-чагага, гомумән, бер-берсеннән калганны гына кидерткәннәр. Кешенең психологиясендә бу әле дә бар. Әмма бүгенге җәмгыятьтә киемгә карап каршы алалар, киемгә карап озаталар. Кием – үз-үзеңә ясаган иң зур инвестицияләрнең берсе. Әйтик, кемдер әллә кайларга барып белем ала, мастер-класслар уза, әмма киемгә игътибар итми икән, ул барыбер зур уңышларга ирешә алмаячак. Яңа кием алсам, акчасыз калам дип куркучылар бар. Бу күренешне «хәерчелек синдромы» дип атыйм. Чынлыкта, күпме акча туздырасың, шуның кадәр кире керә ул. Гомумән, алган акчаңны өчкә бүләргә кирәк: бер өлешен – үз кирәк-ярагыңа, икенчесен – хәйриягә, өченчесен гаиләңә тотарга. Кирәкмәгән кием-салымны мохтаҗракларга таратсаң да, алар урынына яңа кием кайтачак.

Бездә күпләр ни өчендер җете төсләргә туктала. «Кычкырып» торган, табигатьтә булмаган төсле күлмәк киеп барсам, туйда иң матуры мин булам дип уйлый. Алай түгел шул... Кара төстән куркучылар күп. Ә бит ул шундый затлы төс! Минем үзем өчен иң төп төсләр икәү – ак һәм кара. «Бу төс миңа килешми», – дип кырт кисәргә ярамый: һәрбер төснең әллә ничә төсмере бар. Кемгәдер шуның салкынрагы, ә кемгәдер җылырагы килешә.

Сиңа кемне киендерү җиңелрәк: ир-атнымы, хатын-кызларнымы?

– Әлбәттә, ир-атларны. Аларга сумка, алка кебек вак-төяге кирәкми бит. Күбесе очрашуга әйтеп куя: «Киенеп-чишенергә яратмыйм. Бер кибеткә генә керик тә, шуннан бөтен әйберне алыйк. Ничек тизрәк булса, шулкадәр әйбәтрәк», – диләр. Хәер, шопинг ярата торган ирләр дә бар. Андыйлар беренче образны күрүгә: «Карале, мин нинди икән! Әйдә, тагын нинди киемнәрең бар, алып кил», – диләр. Ир-ат бу мәсьәләдә бала кебек: азрак мактап та җибәрсәң, бөтенләй үсенеп китәләр.

Хәер, хатын-кызлар да шулай. Сайлаган беренче образымны күрүгә: «Мондый чалбар миңа ошар дип уйламаган идем», – диючеләр бар. Кайсы, сөенечтән, примерка бүлмәсендә үк кочаклый башлый.

Синең белән очрашканнан соң, тормышым үзгәрде дип әйтүчеләр бармы?

– Бик күп! Хәтта икенче көнне үк шулай дип язалар. «Берәүнең дә сүз кушканы юк иде, ә бүген лифтта ук таныша башладылар», – диләр. Яңа киемнән хатын-кыз үзен башкача хис итә бит ул. Күңеле генә түгел, күзләренә кадәр үзгәрә. Тирә-юньдәгеләр исә моңа игътибар итми калмый. «Бүтән синнән башка кибеткә бармыйм. Акчамны гел юк-барга әрәм-шәрәм иткәнмен икән», – дип тә язучылар бар. Кайберәүләр кибеткә кергәч югалып кала: «Мин монда нәрсә карарга белмим», – диләр. «Кечкенә кибеткә генә барыйк, зурларында башым әйләнә. Нигә берьюлы 20 джинсы карарга?» – дип аптырыйлар. Көн саен кибеттә йөреп иялләшмәгән кешегә, чыннан да, стресстыр. Ә стилист белән ул мондый стресс кичерми: ияреп кенә йөри – телефоннан сөйләшеп, эшен эшләп... Нинди матур әйбер күрсә, барысын да алырга теләүчеләр бар. «Нәрсәгә сиңа моның кадәр кием? Соңрак тагын алырбыз», – дип туктатам. Кием бит ул гел яңарып тора.

Бер-ике тапкыр миңа шопингка килүчеләр киемгә башка төрле карый. Үз стильләрен табып бирәм: инстаграмдагы рәсемнәрдән алар аны таный, таба башлый. Нәрсәдер ясарга өйрәнгән кебек, моңа да өйрәнеп була. Кием дә кешене үстерә дип гел кабатлыйм. Тормышын үзгәртә! «Алмыйм, аны киеп барыр урыным юк», – диләр. «Кием булгач, андый урын табылачак!» – дим. «Бу күлмәкне кияргә сәбәп юк», – диючеләргә: «Чөнки синең моңарчы күлмәгең юк иде!» – дип җавап бирәм.



Мәдинә
АВЗАЛОВА

ИделиЯ

Американың Төньяк Каролина штатында басылып чыккан 2020 елгы календарьда татар кызының татар авылы тормышын сурәтләгән фотосы дөнья күрде.

Туган җиреңне сагыну, аяк табаны астындагы туфракның җылысын, шаулап аккан елгаларның, башы күкләргә ашкан урманнарның гүзәллеген тою, кабарып пешкән тәмле исле икмәкнең кадерен белү өчен еракка китеп кара икән ул. Күз күрмәгән җирләргә – гайрәтле океаннар артына. Хәер, алай дисәң, Хисмәтовлар гаиләсе Төньяк Каролина штатына килеп урнашканда, кызчыкка нибары 4 кенә яшь була әле. Әнисе Чулпан белән әтисе Алмазның ул чагында әле бердәнбере, зур кызы.

Ул вакытлар сизелми дә үтеп китеп, күптән инде артта калган. Иделия 12 нче сыйныфны «бик яхшы» билгеләренә тәмамлаган. Укыганда ук үзе теләгән һөнәрне сайлаган. Әнисе Чулпан әйтмешли, инша язып, шигырь ятлап йөргән бала түгел: алар анда киләчәктә сайлаячак һөнәрләре өчен нинди фән кирәк, шуны укыйлар. Кыз биология һәм экология фәннәрен өйрәнә. Чыгарылыш сыйныфын тәмамлаучылар арасында алтын медаль алган унсигез укучының берсе була ул. Меңләгән бала арасында!

Американың иң күренекле биш университетына гариза тапшыра Иделия. Һәм шуларның өчесеннән: «Кабул итәбез», – дигән хәбәр килә. Кыз әти-әнисе, энесе яныннан еракка китмәскә була: Төньяк Каролинаның Чапел Хилл шәһәрендә урнашкан университетка укырга керә. Укыган чорда төрле бәйгеләрдә катнаша, спорт белән шөгыльләнә, мәктәптә укучы инвалид балаларны биергә өйрәтә. Дәүләтләре булмаган аз санлы халыкларның тормышы, язмышы белән кызыксына, дистәләгән докладлар белән чыгышлар ясый. Ә үзен исә: «Мин – дөнья гражданины», – дип атый.

Иделия рус, инглиз, француз телләрендә иркен аралаша. Менә дигән итеп татарча сөйләшә. Җәйге каникулларда ул энесе Рәфыйк белән Казанга кайтып йөри. Әби-бабасының туган ягы Кукмарада да була.

– Иделия 8 нче сыйныфта укыганда туган көненә акча бүләк иткәннәр, – дип сөйли дәү әтисе Гарәфетдин Хисаметдинов. – Анда шундый гадәт бар: бүләккә бирелгән акчаны алар йә хәйрия фондына, йә Картлар йортына күчерәләр. Бик сирәк очракта гына үзләренә алып калалар. Оныгым үзенең бер теләге барлыгын җиткерде: бүләккә бирелгән шул акчага кәҗә сатып алып, аны шикәр авырулы берәр кешегә бүләк итәргә тели икән. Бу хыялын тормышка ашыруда ярдәм итүебезне сорады. Андый кәҗәне без Арчадан, ә кәҗә сөтенә мохтаҗ кешене Кукмараның бер авылыннан эзләп таптык. Иделия безгә җәйге ялга кайткач, шул теләген тормышка ашырды. Кәҗәне Сазтамак авылында яшәүче Сәрвиназ апага илтеп бирдек. Килүебезнең максатын белгәч, ул кызыбызны кочаклап алды, чиксез рәхмәтләрен белдерде. Шул чагында Иделия авыл тормышын күрде дә инде: көтүдән сыерларның адашмыйча туп-туры үз өйләренә кайтуын гаҗәпләнеп күзәтте, фотога төшереп алды.

Соңыннан ул фото Төньяк Каролина университетының Халыкара Инициатива Үзәге үткәрә торган фоторәсемнәр бәйгесендә дөньяның иң кызыклы урыннарын яктыртучы эш буларак, 2020 елгы календарь өчен сайлап алына! Экология факультетының беренче курс студенткасы Иделия Хисмәтованың «Кукмара, Татарстан, Россия. Татар йорты яныннан узып баручы сыер» дип исемләнгән фотосурәте күпләрне хәйран калдыра.

ИделиЯ исемендә соңгы хәрефне аерып, «зурлап» күрсәтүгә бер дә гаҗәпләнмәгез. Аны ИделиЯ үзе уйлап чыгарган. Исемен дөрес әйтсеннәр дип, үз илендәгечә, туган җирендәгечә...





МИН БӨТЕНЛӘЙ БАШКА!

Ул чынлап та башкаларга охшамаган. Уй-фикерләре дә, йөз-кыяфәте дә, иҗаты да үзенчәлекле аның. Зәңгәр күзле, вак бөдрә чәчле, чандыр гәүдәле җырчы Илнар МИРАНОВ тавышы, моңы белән күпләрне үзенә гашыйк иттерде. Татарча моңлы җырлар җырлыймы ул, соул стилендә рус җырларын башкарамы, барысы да, ничектер, ихлас һәм камил килеп чыга. Татар эстрадасының 80 нче елларында популяр булган «Зәңгәр томан»ны кабат сәхнәгә алып менеп, аны хәтта инглиз телендә дә җырлый әле ул. Илнар кысаларга кереп яшәргә теләми, аның өчен чикләр юк!



Син – гап-гади авыл егете. Ышанасы да килми! Башкорстанның Дәүләкән районы Бик-Карамалы авылында үскән малай кечкенә чакта нинди иде ул?

– Кечкенәдән үк башкалардан аерылып тора идем мин. Дөньяга карашымны яшьтәшләрем бөтенләй аңламый иде. Хәер, хәзер очрашсак та, аңламаслар, мөгаен. Малайлар белән артык дуслашып үстем дип әйтә алмыйм, «әни малае» да түгел идем. Әти-әнием – гап-гади авыл кешеләре. Энем бар. Ул астрономиягә мөкиббән. Әти дә, әни дә җырлыйлар. Әти баянда уйный. 15 яшьтән үк өйдән чыгып киттем. Мәктәпне тәмамлагач, Уфа сәнгать училищесына укырга кердем. Үз көнемне үзем күрдем. Кем генә булып эшләмәдем: элемтә салонында сатучы-консультант, промоутер, Макдоналдста да, суши ясаучы булып та... Болары әле искә төшкәне генә. Мөстәкыйльлеккә ирешергә теләвем булгандыр инде ул... Акчаны үзең тапсаң гына башкалар фикереннән азат булып яши аласың дип уйлыйм.

Илнар, ә ни өчен Казанны сайладың?

– Сәнгать училищесында академик вокал классында укыдым. «Син Казан консерваториясенә укырга керергә тиеш!» Педагогым гел әнә шулай дип әйтә иде. Күрәсең, Казан үзенең чынга ашмаган хыялы булгандыр. Аннан соң шәхси мөнәсәбәтләрем дә башка шәһәргә китү уена урын калдырмады. Яраткан кешем Казанга китте. Мин дә аның артыннан Татарстан башкаласына юл тоттым. Без икебез дә Казан сәнгать һәм мәдәният институтында укыдык.

Сине Казанда консерваториягә укырга алмадылар... Тагын бер кат көчеңне сынап карарга теләмисеңме?

– Юк, юк, юк... Бюджет урынга алабыз дисәләр дә бармаячакмын. Мин элек академик вокал дип яндым, тик имтихан алучылар тагын бер кат училищега барып укырга кирәк дигән киңәшләре белән бөтен теләгемне, барлык хыялларымны юкка чыгардылар. Үземне опера сәхнәсендә дә күрмим. Классик стильдә иҗат итсәм дә, бары тик камера сәнгатендә генә.

Син бик күп бәйгеләрдә катнаштың. Популярлыкны «Үзгәреш җиле» алып килде.

– Әлбәттә, бу проект зур сәхнәгә юл ачты. Иҗат кешесе буларак асылымны ачып бирде ул. Дөрес, беренче сезонда оялчанлыгым, артык нык тыйнаклыгым иҗади фантазияләремне чынга ашырырга комачаулады. Хәзер мин «Зәңгәр томан»ны бөтенләй башкача җырлыйм. Тәҗрибә белән бергә ирек тә килә икән ул. Ә ул вакытта барысы да беренче тапкыр иде бит. Зур сәхнә, академист беренче тапкыр эстрадада...

Сине эстраданың «ала каргасы» дип әйтәләр. Үпкәләмисеңме?

– Юк, мин аны хәтта комплимент итеп кабул итәм. Башкаларга охшамаганлыгымны беләм, бу ягым үземә бик тә ошый. Уйнарга, кыланырга, кемгәдер ярарга тырышырга яратмыйм. Зур компанияләр минеке түгел. Янымда аралашыр өчен берничә якын кешем бар. Шулар җитә.

Америкада «Карнеги-холл»да чыгыш ясадың. Үзеңне анда ничек хис иттең?

– Миңа аларның мәдәнияте дә, менталитеты да якын. Үзеңне танытуда, иҗатта ирек күп анда. Ә бездә – кысалар. Алардан чыгарга телисең икән, тәнкыйть утына эләгәсең. Ә мин, әйткәнемчә, кагыйдәләргә буйсынып яшәргә яратмыйм.

Син сәхнәдә бик нәзакәтле, нәфис, нәзберек. Шундый булуың тормышта комачауламыймы?

– Сәхнәдәге Илнар белән тормыштагы Илнар – икесе ике кеше. Музыка минем өчен сихри, изге әйбер. Сәхнәгә чыккач, мин үземне күкләр белән бәйле итеп тоям. Башка дөньяга очам! Ә көнкүрештә... Юк, син уйлаганча йомшак кеше түгелмен. Якыннарым белә: шактый кырыс. Турысын әйтәм. Дөрес, андыйларны яратмыйлар. Холкым бал түгел. Җыр ошамый икән, продюсер әйткәнгә генә җырламаячакмын. Гомумән, минем хактагы беренче тәэсирләр алдавыч.

Иҗат утында янган кеше хыялларга күмелеп яши бит инде ул...

– Хыялларым – җырлар, гастрольләр, концертлар... Тарихта калырлык моңлы җырлар иҗат итәсем килә.

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА әзерләде.
Фото: Анна АРАХАМИЯ.
Видео: Фәнис САДЫЙКОВ.





ӘНКӘЙ БЕЗНЕ ҖӨННӘН АЛЫП КАЙТКАН...



Эльмира
ЗАКИРОВА

Фәттаховлар гаиләсе – үзе бер кечкенә дәүләт кебек. Үз кануннары, тәртипләре, матур традицияләре бар аның. Уңышларга ирешү, алдынгы булу, җиңә белү серләре бар... Ачасы иде шуларны.









Аның балалары хәзер республикада танылган кешеләр!

Рәйсә апа Фәттахова турында азмыкүпме беләм дип йөри идем. Актаныш районы Чишмә авылыннан... Зирәклеге, булганлыгы, кешеләр яратуы турында сөйләгәннәрне дә колакка кергәне бар... Ире – сугыш ветераны, II группа сугыш инвалиды, тирәякта исеме билгеле атказанган укытучы Нәвап абый Фәттахов белән биш бала тәрбияләп үстергәннәр. Юк, алай дип кенә әйтеп узасы килми әле. Кызлары Лина, Гүзәл, Тәслимә – әтиләре юлын сайлаган. Өчесе дә Татарстанның атказанган укытучылары! Рәйсә апа кебек төгәл фәннәр яраткан Вәрисәләре төзелеш-архитектура институтында укып үз юлын тапкан. Төзелеш эшләре, хуҗалыкны алып барырга булышу, җай чыккан саен авылга кайтып ярдәм итеп торулар тәвәккәл Вәрисәгә килешеп кенә тора!

Төпчекләре – көтеп алган ир бала Энгельгә исә әти-әнисеннән дә, апаларыннан да күп асыл сыйфатлар күчкән... Энгель Нәвап улы диюгә үк, һәрчак яңалыкка омтылучы абруйлы җитәкче – Актаныш районы башлыгы күз алдына килеп баса... Аның Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры булып эшләгән еллары исә мәктәп, мәгариф, вуз дөньясында яңа казанышлар чоры булып тарихка кереп калыр...

Кызганыч, Нәвап абый арабызда юк инде... Укучыларына шәхес итеп карый белгән, аларны тормыш фәненә, мөстәкыйльлеккә өйрәткән чын педагог булган ул!

Рәйсә апа дидем дә... «Ел хатынкызы» республика бәйгесендә «Хатын-кыз – ана» номинациясендә җиңүче булып, «Пирамида» сәхнәсендә балкып елмаеп торуын да күрдем бит мин аның. Чая, җор телле, җитез хәрәкәтле матур апа булып истә калган... Чәчәкле кызыл яулыгы, иңсәсенә салган бүләк туны ул көнне ничек килешә иде үзенә! Һич тә яше 80 нән өстә димәссең...



■ ...Һәм аның беркайчан да үзе турында уйлаганы юк. Гел кеше турында уйлар, гел башкаларны кайгыртыр. Каникул вакытларында җәйге лагерьдан ким түгел: унҗидешәр бала була – детсад! Ничек җитешкәннәрдер?! Ә балалары берсен-берсе карап үскән. «Бер алманы бишкә бүлеп ашаган балалар алар», – ди әнкәләре.

Фото: Анна Арахамия

Сөн буенда Чишмә авылы...

Ә Рәйсә апага бу көннәрдә 95 яшь тула икән! Һаман шулай тынгысыз, хәтере дә шәп, үзе дә һич тиктормас, диделәр. Замана әбисе дә ди әле, җитмәсә! Гаиләсе белән Англиядә яшәүче оныгы Гөлнарга шалтыратып хәлләрен белешеп торгач соң... Оныгы Алсуның кызы Нәфисә әнә сугыш елларында хисапчы булып эшләгән әбисе турында «әле хәзер дә төймәле счетта алты урынлы саннарны бер хатасыз куша, ала, бүлә, тапкырлый», дип язган иншасында. Ымсындырып, гаиләләренең кызыл папка серләрен ачарга тырышкан... Ә анда – бер гаилә язмышындагы ил, республика тарихы!

Менә шулай Чишмәгә җыенып чыгып киттек. Рәйсә апа янына! Юл – озын, Чишмә – ерак. Башкортстан чигендә, Сөн буенда утырган бу авыл турындагы җыр әле Фәридә Кудашеваның моңлы тавышы, әле Зөһрә Сәхәбиева аһәңнәре белән гел күңелдә яңгырап бара. «Нигә туып үсмәгәнмен / Шул Чишмә якларында...» Элек-электән әкияти матур авыл дигән даны таралган. Мөгаен, җырга оста Рәйсә апа белән Нәвап абый да үз иткәндер бу җырны. Тукта, Тәслимә нәрсә диде әле... «Роберт Миңнуллин белән Сара Садыйкованың «Әнкәй безне Сөннән алып кайткан...» җыры безнең гимн булды инде. «Без биш бала үстек – бер йодрык» – гел безнең турыда кебек!.. Роберт абый үзе дә Сөннең теге ягыннан, Шәммәттән генә бит...»

Сәнгать кешеләре – шагыйрьләр, язучылар, җырчылар үз итеп кайта, яратып китә торган яклар бит ул.

Меңнәр Чишмәгә күренеп кенә тора, аралары өч чакрым гына. Нәвап абый белән Рәйсә апаның балалары Чишмә башлангыч мәктәбеннән соң Меңнәр сигезьеллык мәктәбенә көн саен җәяү йөреп укыганнар, кыш көне ул араны чаңгыда уза торган булганнар. Кышкы чатнама суыкларда, кар-буранлы көннәрдә исә аларны Рәйсә апа бәйләп кидергән бияләй-оекбашлар гына да түгел, гамаш, джемперлар, шәл-башлыклар да җылыткан. Нинди генә төсләргә манып, нинди генә бизәкләр төшереп бәйләмәгән ул аларны!..

Меңнәрдән бераз арырак тагын матур Сөн буе авыллары тезелеп китә. Ахун, Аккүзләр... Ахун – Рәйсә апа туган авыл. Ахуннар – җырчылар, биючеләр, гармунчылар, курайчылар. Рәйсә апаның якын әбекәе Фәрхинур озын булып үсеп корыган кәҗә сакалы үләнен алып кайтып, шуны тишеп курай ясап уйный торган булган. Табигатьтән шундый талант бирелгән аларга. Хисле, моңлы

Фотолар: гаилә архивыннан

Тормышка карата үз фәлсәфәсе, үз карашы. Шуны оста итеп аңлатып та бирә.

халык. Менә ни өчен балалары барысы да җырлый да, бии дә, гармунда да уйный икән! Берчак Камал театрында республика җитәкчеләре катнашында концерт булган иде. Энгель Фәттахов гаиләсе белән биеп бөтенесен шаккаттырганы әле дә хәтердә... Үзе шәп биюче, үзе көрәшче, үзе чаңгычы, үзе фән кандидаты диләр аның турында. Шуларның барысына да оеткы туган авылда, әти-әни тәрбиясендә салынган инде.

Ә Минзәлә педучилищесы Фәттаховлар гаиләсе өчен академиягә тиң атаклы гаилә мәктәбе ул. Әтиләре дә шунда укыган, кызлары Лина, Гүзәл, Тәслимә дә Минзәләне – педагогика училищесын сайлаган.

Күпме иелсәң, шулкадәр озаграк яшисең...

Менә ул 1962 елда Нәвап абый белән Рәйсә апа салып кергән өй. Төпчекләре Энгель тәпи атлап киткән, балалар үскәндә шау-гөр килеп торган йорт. Тәрәзә саен яран гөлләр көлеп тора. Стеналарны чигүләр, рамадагы фотолар, гаилә шәҗәрәсе, шәмаилләр бизи. Рәйсә апаны хәзер ялгызын гына калдырмыйлар. Кызлары алмашлап кайтып тора. Без килгәндә Кәзкайдә яшәүче Гүзәле янында иде. Актаныштан килене Сәрия дә хәл белергә килгән. «Әнкәй, әнкәй» дип янында бөтереләләр. Ә Рәйсә апа – матур! Фирүзә төсендәге күлмәге дә, ак яулыгы, мәрҗәннәре дә бик килешле үзенә. Безне кыстый-кыстый, «бәбекәйләрем», «сылуым», «апаем» дигән матур сүзләре белән чакырып табынга утырта. Чөгендерле катык, балан бәлеше, алма кагы, миләш кайнатмасы...

«И-и-и, Сөн буенда, Кыпчак ягына чыгып, көянтә-бидрәләп җыябыз ул баланны», – ди Рәйсә апа. Ә Рәйсә апаның ашына берәүнеке дә җитмидер! «Әнкәйнең ашы, әбекәйнең ашы» дип кайталар бар да. Чөнки әнкәй кош итен дә, сыер итен дә, күркә итен дә бергә пешерә. Кишерен дә, кәбестәсен дә, токмачын да сала. Иң тәмлесе – аның шулпасы. Кем килсә, кем кайтса да шулпасы әзер, киселгән токмачы бар, – ди Гүзәл. – Без бәләкәй чакта да әнкәй көн саен мичкә салам ягып, чүлмәккә бәрәңге шулпасы утырта иде. 11 тулырга 15 минут кала әткәй дә, без дә озын тәнәфестә өйгә ашарга кайта идек. Ул ашның тәмлелеге!..»

...Нигә шулхәтле төгәллекме? Сугыштан инвалид булып кайткан Нәвап абыйның сәламәтлеге турында кайгыртып, көндәлек режимны әнә шулай сакларга тырышкан Рәйсә апа. Нәвап абый үзенең 80 яшен тутырган юбилеенда: «Мин Рәйсәнең тырышлыгы, аның тәрбиясе аркасында гына шушы яшькә җитә алдым», – дигән. Ул 83 яшендә бакыйлыкка күчә. Бөек Җиңүнең 75 еллыгын каршылаган көннәрдә балалары аның сугыш хатирәләрен кат-кат искә төшерер әле. Фашист снайперы пулясыннан Нәвап маңгай сөяген югалта... Сугыштан инвалид булып кайтса да, авылында яраткан эшен дәвам итә: Чишмә башлангыч мәктәбендә директор, башлангыч партия оешмасы җитәкчесе булып эшли.

...Әнә шулай без авыл-шәһәр тормышы, дөнья хәлләре, балалар үскәндәге кызыклар, эш рәте белү турында сөйләшеп утырабыз.

Тәрәзәдән ишегалды, бакчалар күренә. Һәркайда тәртип, чисталык.

– Ул чисталыкны, ул матурлыкны җәй көне күрсәгез иде сез! Ишегалдындагы чәчәкләре уш китмәле! Бакча да олы! Әнкәй үзе, кулы белән эскәкләп, чистартып тора аны, – ди Гүзәл. – Башын да күтәрми. Хәзер әйтәм инде, әнкәй, озак яшәүнең сере шулдыр, күпме иелсәң, шулкадәр озаграк яшисең, дим. *(Көлешәбез.)*

– Чүп беткәч, аптырап, әнкәй күршеләрнекен чистарта башлый әле үрелеп. Койма арасында бер чүп тә калдырмый... – Боларын Сәрия әйтә.

– Тамырларын тәки казып алып бетердем! – дип көлеп сүзгә кушыла Рәйсә апа. – И-и-и, шуны эшләсәм, бер авырткан җир дә калмай! Аяклар да авыртмай. Эшләмәдең исә чирләйсең. Менә бу физкультура, ичмаса! Хәзер әнә врачлар сөйләй бит җәяү йөрергә кирәк дип... Минем урамга чыгарга, башымны калкытып капкага карарга вакытым булмай. Бөтен эшемне бетерәм. Менә шулай инде, бәбекәем, җәй көне кулдан кәтмән, кышын көрәк төшмәй... Килгән берсе җәен ындырны, кышын капка төпләрен күреп шаккатып китә. Әнә күрше Рөстәм нәмә дигән: Рәйсә апа кар көрәп йөри иде, аның көрәге ыргыткан карлар безнең капка төбенә кадәр җитә, ди икән. Нык очырып көрәй инде карны дип әйтә ди. *(Көлешәбез.)* Рәйсә апа безнең капка төбен дә көрәп куймас микән, дип тә шаярткан булалар әле. Балалар килгәнче бетсен, аларга калмасын дим инде. Кеше күрмәсен дип, төнлә чыгып ут яктысында көрәем.

Кара бу Рәйсә апаны! Берүзе Тимур командасына торырлык! Ә ул: «Эш кирәк! Эш кирәк! Сәламәт буласың килсә!» – дип кабатлый.

– Күзлек кигәне юк. Китапны күзлексез укый. Гомергә санаторий-фәләнгә барганы, дару эчеп зарланып ятканы юк. Үз дарулары бар аның: ачы кызыл борыч, сарымсак, суган, мәтрүшкә... Әйе бит, әнкәй?

Без биш бала үстек...

Рәйсә апаның биш вакыт намазны калдырганы юк. Аның сөйләшүе дә үзенчә матур, җырлап тора. Сүзләрен әдәби телгә күчереп бирә башласам, аның бар яме югалыр төсле.

– Елап, ярсып беткән чаклар да була. Төне буе уйлап чыгам да... Картайгач уйлайсың диләр ие, дөрес икән. 51 булдык бит хәзер бөтенебез. Килен, кияүләр, балалар, оныклар... Барысы өчен дә борчылам. Марс әйтә, әбекәй, син мине җәй көне тәрбияләмәсәң, эшкә өйрәтмәсәң, мин юрист булалмас идем, ди. Аның белән тау астына төшеп керләр дә юдык, торф та чыгардык, ягарга юк иде бит. Ул таска тутыра да, икәүләп күтәреп кайтабыз... Алсуыбыз Нәвап белән икебезнең арабызда үсте инде. Алтынчы балабыз булып, бәбекәем. Күпме каз бәбкәләре, үрдәк бәбкәләре үстердек аның белән! Кеше сатып

алып үстерә. И-и-и, үстерүмени ул алай! Үзеңдә утыртып чыгармагач...

Таяк белән йөрим – әллә нәрсә аламаландым әле. Ул таягы әллә ничә югалып, әллә ничә табылды инде. Вәрисә оныклары Динә белән Рузинә, әбекәй, менә бит таягың, кура җиләге җыйган җирдә калдыргансың, диләр. Ә мин бер атна эзләдем! Тылсымлыдыр бу таяк! Ә Вәрисәнең бер кызы курайда уйнай икән. Әйтәм бит, безнең нәселдә бар ул.

Рәйсә апа оныкларын барлап чыга шулай.

Олы бала Лина беренче булып чыгып китә өйдән. Минзәлә педучилищесында сагынып, кайтам дип елаулары... Бигрәк моңлы бала була ул. Җырлый да, мандолинада да уйный. Әле өйләрендәге калай мичне, күл буенда бәбкә саклауларын, әле әнкәсенең бәйләм йомгакларын сагынып. шигырьләр яза... Бер зур йомгагыңны сүтсәң, әнкәй, Җир шарын ике мәртәбә әйләндереп урап булыр иде, дип... Күз алдында – әнисе пешергән паштет, прәннекләр, җитен чәкчәге, ул киптергән кабак төшләре, этисенең олы табакка бал аертып чыгып, бөтен тирә-юнь балаларын җыеп сыйлаулары, өйдә бергәләп меңәр пилмән ясаулар, әнисенең шул пилмәнне чиләк-чиләк катырып, чоланга чыгарып куюлары...

– Печән алып кайтырга да транспорт юк заманалар бар иде. Лина апа кияүгә чыккач, җизнинең мотоциклында безгә бөтен нәрсәне ташый болар. Шунда эткәй: «Без дә кешечә яши башладык», – дип и сөенгән иде инде! Ә безнең бәләкәй чакта һәркайсыбызның үз вазыйфасы бар иде. Һәркемгә бүлеп куелган, һәркем торуга үз эшен эшли, – дип тезә Гүзәл.

– Богады авылына барып чыга язып, колхозның гектарлаган чөгендер җирендә таңнан ук бил бөгәбез. Әле аны сирәклисе, утыйсы, өч тапкыр эшкәртәсе... Бакчада үзебезнең 25 сутый бәрәңге көтә. Ашарга әзерлисе, маллар карыйсы. Идәнне ничек инде әнкәйдән юдырасың? Гомер булмаганны! Без үскәндә аның беркайчан да идән юганы булмады... Эшләрне бетергәч, кич клубка да чыгасы килә бит. Йөгерә-йөгерә эшлибез. Ул арада көтү кайта. Аннан кыярларга су сибәсе. Аннары тау астыннан көянтәләп су ташып, мичкәне тутырасы... Ә Сөн ягында инде кояш байый. Меңнәр, Ахуннар ягына таба тәгәрәп төшеп бара. Их, тагын Сөн буена төшеп су керергә җитешмибез инде, – дип, балачагын кызык итеп искә төшергән иде Тәслимә дә.

Гүзәл көлеп тагын дәвам итә:

– Бүрәнәләрен юкә мунчала белән ышкый-ышкый өйне дә үзебез юабыз. Үзебез чиккән чигүләрне үтүкләп, төрлечә элеп өйне бизибез. Аннан соң әле күршеләрнекен дә карап чыгабыз: сезнеке ничек дигән булып... Эткәй белән әнкәй эштән кайтуга табын әзерлибез. Әнкәй кайтырга чыктымы дип карап торабыз әле башта. Кайнар килеш ашатасы килә бит. Җәй көне тышка – баскычка ук табын әзерләп куябыз. Бер көнне Энгель гимназиядә малайларга токмач кисеп күрсәткән әнә. 7-8 нчеләрдә укыганда үзе генә калды бит. Без, апалары, төрле җирләрдә укый идек. Эткәй белән әнкәй эштән кайтуга токмач кисеп, аш пешереп тора торган булган. Чөнки без өйрәттек! – ди Гүзәл.

Әнкәйнең догалары

Рәйсә апа юмор кушып, тәмләп сөйли. Аны тыңлавы рәхәт.

«Әрвахларны сөендерәм, аларга дога җибәрәм, теләк теләем. Безгә биргән сугышларны бирмә бәбекәйләремә, дим. Нәрсәдер сораганда һәрберсен кыенсынып кына сораем. Бусы да рас килер микән, бусы да уң як фәрештәнең амин дигән чагына туры килер микән дип. Тамчылап кына коедан су чыкса да риза булыр идем, дидем берсендә. Кое казыган иде Энгелькәем, бер безнекендә чыкты су! Искитмәле! Әллә кемнәрнеке җир астына сеңеп бетте. Менә хәзер өйгә үк кертеп бирде Аллаһы Тәгалә. Җәй көне Чишмәдәге бөтен өйләргә су үткәрделәр. Балалар үстергәндә интеккәннәр өчен Аллаһы Тәгалә оҗмахта яшәтәдер дим».

Сугыш башланганда Рәйсә апага 16 яшь була. Ак алъяпкычлардан 7 нче классны тәмамлап йөргән көннәре. Өздереп гармунда уйнаучы укытучы Мулланур абыйларын елыйелый сугышка озаталар. Аннары Рәйсә Пучыда хисапчылыкка укыганда әтисе Мирзасалих китә. Рәйсә күрми дә кала. «Догаларыбыз кабул булгандыр: эткәй дә, Мулланур абый да исән-сау әйләнеп кайтты», – ди ул. Олыгайган көндә янібызда саулыгыбызны кайгыртып торучы булса иде дип теләгән теләкләре дә рас килә Рәйсә апаның: килене Сәрия шәфкать туташы булып чыга. Килен – кайнана туфрагыннан диюләр дә хактыр. Сәрия кайнанасына охшаган. Алай гынамы: иренең апалары белән бутап бетерәләр икән үзен.

«Энгельнең Актаныш мәктәбендә укыган чагы иде. Кайткан бу теге «беттем-беттем» «чыпчык» матае белән. Аталары чирләбрәк тора иде. Бөтен кешенең эти-әнисе була, әнкәй, син бар инде җыелышка, ди. Киттем бит артына утырып. Кайтканда тәгәрмәче тишелде, тыны чыга. Әлем урманы янында икәүләп мотоциклны сүтеп, әллә ничәнче ямауны салдык. Менә хәзер, Аллаһы Тәгалә үзен машиналы итте, юлын да булдырды, рәхмәт яугыры! Интекмәй генә рәхәткә чыгып булмай ул...»

«Энгельне Казанга эшкә алгач и борчылдым инде. Эчтән генә көн саен Аллаһы Тәгаләдән улымны үзебезнең якларга кайтаруын сорай идем. Аллага шөкер, ишетте үтенечләремне, – дип сөенә ана кеше. – Авыл тормышкайларына җитәме соң?! Үзебезнең Сөн буйларысыз, чишмәләрсез ничек яшәмәк кирәк!»

Беркөн Рәйсә апа Путин белән Эрдоганның Мәскәүдәге очрашуын телевизордан күрә алмый калган. Биш сәгатькә сузылган сөйләшүләр соң беткән. Төркия президентының кәефе юк иде бугай, һай, ничек килештеләр икән дип, тәмам хафага төшкән. Төн уртасында балаларына шалтыратып, сөйләшүләрнең уңышлы үткәнен белгәч кенә тынычлап йокларга яткан, ди. Илләр тыныч булсын, сугышлар күрсәтмәсен балаларга дип чын күңелдән теләгән догалары да булышмаса соң!

...Ә без сиңа, Рәйсә апа, рәхәт матур тормышта балаларыңны, оныкларыңны, аларның балаларын озак сөендереп яшәвеңне телибез. Син бик кирәк аларга!

Син – дөнья бәясе кеше!









САБА КӨМЕШЧЕЛӘРЕ



Лилия ГӘРӘЕВА

Татар көмешчеләренең даны кайчандыр дөньяга таралган булган. Болгар бабаларыбыздан ук башланган бу осталык (бәлки, аннан да иртәрәктер әле!) – Казан ханлыгы чорларын узып, безнең көннәргә кадәр килеп җиткән иң борынгы һөнәрләрнең берсе. Саба яклары – гомер-гомергә әнә шул борынгы һөнәр ияләре – зәркәнчеләр төбәге саналган. «Саба көмешчеләре ерак-еракларга барып чыгып, алка, йөзекләрен сатып йөргән», – дип сөйлиләр. Димәк, Саба осталарының ювелир эшләнмәләре әллә кайларга кадәр барып җиткән!

Борынгы һөнәр ияләре белән танышырга, эшләрен күрергә дип, шул якларга ашкынсак та, әлеге эшне белүчеләрдән Теneки авылында бер Хәлим абый Габдрахманов кына калган булып чыкты. Югыйсә бу авылда көмешче осталарның алка-беләзекләре һәр гаиләнең дияр-лек кадерле ядкаре булып саклана әле. Хатын-кызларның колагында борынгы калач алкалар ялтырап киткәли, «кара алтын»лы беләзекләр, басма йөзекләр дә әллә ни ерак куелмаган...

Рәссам егет

Хәлим абый тумышы белән дә, яшәве белән дә Тенеки авылыннан. Гап-гади татар авылында туып-үскән егеткә рәсем сәнгатенә һәвәслек кайдан килгәндер, мәктәптә укыганда ук рәссам булырга хыяллана ул. «Әй улым, сурәт төшереп утыру ир-ат эшемени?!» – ди әтисе Афзалетдин агай. Гомере буе колхозда бригадир булып эшләгән Бөек Ватан сугышы ветераны бу шөгыльне чүп эш итеп кенә күрә. Казандагы сәнгать училищесына тапшырырга дип әзерләгән документларын механизаторлар курсына илтеп бирә Хәлим абый. Белем алып, армиядән әйләнеп кайткач та, хәтта механизатор булып эшкә урнашкач та, хыялы барыбер сүрелми аның. Бернигә дә карамый халык һөнәрләре йортындагы курсларда укып, кулына рәссам-бизәүче таныклыгы алган егетне Мәскәү көтә! Читтән торып белем бирүче Н. Крупская исемендәге сынлы сәнгать халык университетын 1984 елда тәмамлый ул. Колхозлар әле гөрләп тора, рәссам-бизәүчегә эшнең бетәсе юк. «Агитатор почмаклары», Мактау такталары, плакатлар, лозунглар.... Фермада сыерларның исемнәренә кадәр язып элә идек», – дип көлә Хәлим абый. Соңрак аны Ленинградка ук чакыралар. Кассадагы бар булган 300 сум акчасын алып Казанга килгәндә, бергә укырга тиешле төркем инде юлга кузгалган була. «Самолетка билет алсаң, алардан иртәрәк тә барып җитәчәксең», – диләр аңа. «Мин барыбер авылда калам бит инде», – дип, кире борыла ул, һәм шушы гамәле өчен әле дә булса күңелендә үкенү яши.

Соңгы көмешче

Безне исә Хәлим абыйның борынгы һөнәргә маһирлыгы кызыксындыра. Гади генә шөгыль түгел бит! Кайдан өйрәнгән, кемнән откан?

– Остазым – Хәбибрахман ага иде, – дип сөйләп китте ул үзенең һөнәрчелек тарихын. – Армиядән кайткач, янына үзем барып, әлеге эшнең төп нигезләрен өйрәндем. Ә бөтен нечкәлекләре бары тик эшли-эшли, тәҗрибә белән генә килә. Карап торып кына өйрәнеп булмый.

Әле монда килгәнче үк Хәбибрахман ага Ганиев турында ишеткәнебез булган иде. Тенекидәге иң атаклы көмешчеләрнең берсе ул. Исем-фамилиясе 1990 елда Мәскәүнең «Советский художник» нәшриятында басылган «Декоративно-прикладное искусство казанских татар» китабына да кертелгән. Авылдашы – тарихчы Илдар Сафинның туган авылы турындагы «Юлбатым Ямбулатым» дип аталган истәлекләр китабында да аның турында бүлек бар...

Хәбибрахман аганың әтисе Габделгани дә зәркәнче була. Кызганыч, әмма беренче Бөтендөнья сугышыннан әйләнеп кайтырга язмый аңа. Хәбибрахман ага үзе дә Бөек Ватан сугышында бер аягын калдырып кайткач кына балачакта әтисеннән откан һөнәргә тотына. Бүгенге көн зәркәнчесенең өстәлендәге эш кораллары – остазының ядкаре. Шөшлеләр, кыскычлар, игәүләр, безләр, эскәкләр, чүмечләр, сандал һәм чүкеч, гурна – көмешченең төп эш кораллары. Хәлим абый үскән чорда да авылның берничә йортында көмешчеләр яши әле.

– Галимҗан, Фәттахетдин, Вилдан абыйлар, Хәбибрахман абый – мин күреп белгән көмешчеләр дүртәү иде. Анда да иң авыр эшләрне барыбер Хәбибрахман абый башкарды шикелле. Ул эретеп, формага салганны башкалар ялтыратып, шомартып кына бирәләр иде дип хәтерлим, – ди Хәлим абый. Ә бүген, әйткәнебезчә, бу һөнәрне Тенекидә бары тик ул гына саклый. Ни өчен яшьләрнең кызыксынмавын белешәм. Югыйсә алтын-көмеш бизәнү әйберләренә ихтыяҗның кимеп торганы да юк бит...

Зәркән эше белән хатын-кызлар да шөгыльләнгән. Аларның бизәкләре нәфисрәк, затлырак саналган.

Кыйммәтле хобби

– Көмеш эше белән бары тик хобби буларак кына шөгыльләнергә мөмкин. Әмма бик кыйммәтле хобби ул. Аның белән тормыш итеп, тамак туйдырып булмый. Хәзер бит алтын-көмеш кибетләрендә ни генә сатылмый! Кулдан ясаганына караганда, алар арзанрак та, матуррак та... Халыкта көмешче һөнәренең онытылуына әнә шул төп сәбәптер, бәлки. Аннары, йөзек яки беләзек ясар өчен яхшы чимал кирәк. Анысын каян аласың?

– Әүвәл чималны кайдан табалар иде?

– Элегрәк халыкта Николай акчасы дигән көмеш тәңкәләр бар иде, – ди оста. – «22 доля златых» дип язылганы – иң чиста көмеш санала. Хәбибрахман ага күбрәк шулардан ясады. Көмеш кашыкларны, савыт-сабаларны эретеп ясатучылар да булгандыр. Әле үз әтием дә сугыштан кайтканда Германиядән берничә пар көмеш кашык алып кайткан иде. Мәҗлес уздырган саен кими торгач, нибары берсе генә калган. Анысы да таба кыра-кыра тәмам юкарган инде. Әти төсе итеп саклыйбыз.

Иң беренче йөзеген Хәлим абый хатыны Гөлчәчәккә ясый. Бүләк йөзек әле дә исән, бизәк өстендәге «кара алтыны» да купмаган – оста кулыннан кичә генә төшкән кебек...

– Хәбибрахман абый белән бергә эшләгән идек. – ди Хәлим абый. Аның тәүге эшләнмәсен әйләндерә-әйләндерә карыйбыз. Йөзеккә әверелгәнче борынгы тәңкә булган бу көмеш кисәгенең нинди юллар үтүе кызык. Ә Хәлим абый ялындырмый: әле бер, әле икенче эш коралын кулына ала-ала, тылсымлы һәм гаҗәеп шөгыль – көмеш кою серләрен ача безгә.

– Көмеш тәңкә булса, эретеп тә күрсәтер идем, алары калмады шул, – ди оста, көрсенгәндәй итеп. – Иң элек тәңкәне калай кайчысы белән ваклап, чүмечкә тутырабыз, – дип, кулына уч төбедәй генә бәләкәй

Фото: Анна Арахамия

Саф көмеш чак кына саргылт була. Хәзерге көмешләргә цинк кушалар, шуңа ак ул.



Ике ягыннан ике кеше әйләндерә торган бу җайланма «вальцы» дип атала. Көмешне бөгү өчен кирәк ул.

тимер чүмеч ала. – Көмешне гурнага – күмер өстенә куйгач, син дөньяның бар мәшәкатен онытып торырга тиеш – телефоның шалтыраса да, сыерың мөгрәсә дә, күршең йомышка керсә дә, күзеңне чүмечтән алмаска тиешсең… Күмер өстендәге көмешкә бор сибә-сибә – анысы көмеш таралып китмәсен өчен кирәк – кайнау хәленә килгәнче эретәбез дә формаларга агызабыз.

Бу юлы оста кулында бәләкәй генә улак пәйда була:

– Беләзек формасы бу. Хәбибрахман абый истәлеге. Менә бу сандал белән чүкеч тә аныкы.

Өйгә моңлы гына булып, сандалга салып көмеш чүкегән тавыш тарала: тең-тең-тең… Үзе чүки Хәлим абый, үзе аңлата:

– Көмешне кай якка таба җәяргә кирәк, чүкеч белән шул яккарак этәрәбез. Суынса, күмер өстендә тагын кыздырып алабыз. Суккан саен көмеш катылана бара…

Кайчандыр ясый башлаган беләзеге безнең килүне көткән икән…

Беләзекне тиешле калынлыкка һәм озынлыкка җиткәнче чүкегәч, өслеген шомартып тигезләгәч, бизәкле форма өстенә куеп, көмешкә бизәк төшерелә. Басма бизәк төшерү технологиясе дип атала ул.

Өстәлдә тезелешкән шөшлеләр, безләр берәм-берәм оста кулына күчә барган саен, бизәкләр тирәнәя, ачыклана, камилләшә…

– Көмеш коюның һәр этабы четерекле. Чималын да сайлый белергә кирәк. Әле Хәбибрахман абый үзе исән чакта ук «польский» көмешләр чыга башлаган иде. Аның составында цинк күп, эреткәч, көмеше бик аз гына кала. – Шуңа ялгап, остазына бәйле бер мәзәк тә сөйләп ала зәркәнче: «Хәбибрахман абый алтын белән дә эшли иде. Берсендә, имеш, чегәннәр алтын алып килгән. Алдамасын дип, эреткәнен карап торалар икән. Хәбибрахман абый исә алтынны эретә бара, кулына ураган бакыр чыбыкны акрын гына чүмечкә батыра бара…» Алтынның эрү температурасы 1200 градус, бакыр исә 800–900 градуста эри. Чегәннәрнең үзләреннән дә хәйләкәррәк булып чыккан оста. Чындырмы, юктырмы, анысын белмим…

Көмешне каралту – шулай ук бик борынгы ысулларның берсе. Хәлим абыйның беренче йөзеге дә шушы технология белән ясалган.

– «Кара алтын» ясау өчен тәҗрибә кирәк. Вак-төяк калдык көмешне каралганчы эретеп ясала ул. Көмешне чүмечкә салып, күкерт куша-куша кайнатасың. Аннары сандалга салып, он хәленә китереп төясең. Беләзекнең бизәкләре өстенә бор сибеп, өстән «кара алтын» коела.

Хәлим абый өстәлгә куыксыз лампа китереп куя, бер кулына беләзек, икенче кулына тимер көпшә ала. Көпшә аша өреп, ут ялкынын кирәк якка юнәлдерә оста – уентыларга тутырылган порошокны көмешкә эретеп ябыштыра. Бор белән кушылган «кара алтын» ялкын өстендә күперә-күперә кайный, бизәкнең һәр уентысына тула.

Оста кулындагы игәү борыла-сырыла беләзекне шомарта, тигезли. Бизәк белән көмеш өслеге тип-тигез калырга тиеш. Бармак йөзе сизәрлек кенә уенты калса да, эшең барып чыкмады дигән сүз икән.

Моның белән генә эш бетми әле. Беләзекне бөҗралап бөгү өчен «вальцы» дигән җайланма кирәк. Анысы белән Хәлим абый безне Юлбат мәтәбендә оештырылган туган якны өйрәнү музеенда таныштырды. Музейда Тенекинең көмешчеләр авылы булуын раслаучы борынгы ядкарьләр шактый.

«Болары минекеләр», дип, Хәлим абый кулына пәрәвез кебек кенә үтә нәзек чыбыктан челтәрләп үрелгән яка чылбыры алды. Әлеге технологияне әүвәлгеләр сәркә, хәрем дип атаганнар. «Скань» зәркән эшенең иң катлаулы ысулы санала. Борынгы чорда мондый ысул кулланучыларны җыпкырчы дип атаганнар. Ак эш саналган ул. Хәлим абый исә аны Казан осталарыннан өйрәнгән.

Йөзек-беләзекләрен сату өчен эшләми ул. Бары тик истәлеккә, бары тик иң якын туганнарга дип кенә. «Күңелемне, җанымны биреп эшләгән эшне сата алмыйм. Картиналарымны да шулай», – ди ул. Өйләренең бер бүлмәсе бәләкәй генә галереяга әйләнгән. Хәлим абыйның төрле күргәзмәләрдә катнашкан картиналары биредә.

Музейда йөргәндә дә, оста белән сөйләшкәндә дә тел очымда гел бер сорау торды: «Бу һөнәр шушылай онытылыр микәнни инде? Аны дәвам итүчеләр булырмы соң?»

Хәлим абый үзе белгәнне башкаларга өйрәтергә һич тә каршы түгел. «Өйрәт», – дип килүчесе генә юк әлегә. Әлегә…



Апрель сулышы, Тукай ае, Шигырь бәйрәме кайтавазы булып редакциябезгә Мәсгудә ЗАКИРОВА исемле укучыбыздан бер шәлкем шигырьләр килеп төште. Алардан авторның күңел халәте, милли рухы, туган ягын ярату хисләре түгелә. Хаты аша туган авылы Иске Кормаш, мәктәп еллары, шигърият дөньясына алып кереп киткән укытучы-шагыйрә Тәгъзимә апасы Мөхетдинова, матбугатта шигырьләре басылып чыгу, Минзәлә педучилищесында һәм Казан университетында укыган еллары, КамАЗда, Себернең Лангепасында эшләгән чаклары, хәзер гаиләсе белән гомер кичергән Такталачык турында беләбез. Иҗатын авылча гадилек, җылылык, тыйнаклык бизи.

Рамазан

Гает көне, Корбан бәйрәмнәре
Календарьда урын алмаган.
Тик шулай да бала чагымнан ук
Якын бәйрәм миңа Рамазан.

Хәтеремдә калган: бәйрәм җитсә,
Коймак төшә майлы табадан.
Нинди бәйрәм бүген, әйтче, әбкәм?
Бик зур бәйрәм бүген, бәбкәм,
Рамазан!

Әбиемнең изге догалары
Колагымда яңгырый яңадан.
Татлы бала чагым, әбкәм назын
Хәтерләтә миңа Рамазан.

Чәкчәк

Өстәл өсте бигрәк күркәм!
Чәкчәк бизәп тора икән!
Чәк-чәк кенә авыз итсәм
Әбекәем сизәр микән?

Ай-яй тәмле, тел йотарлык,
Балы да күп, мае да мул!
Чәк-чәк кенә каба торгач,
Чәкчәк бетте-китте дә шул!

Исеме дә чәкчәк кенә!
Капкан идем чәк-чәк кенә...
Туктый алмый сыпырткамын
Онытылып, тәмләп кенә!

Әбекәем сүз әйтмәде,
Сау бул, бәбкәм, зур үс, диде!
Чәкчәк кебек тәмле телле
Син булырга тырыш, диде.

Әнкәй оекбашы

Чорналанып беткән уйларымны
Охшатамын әнкәй йомгагына.
Бишинәдән төшкән оекбашны
Киеп йөрдем әле яңа гына.

Җылы оекбашлар, бияләйләр
Күпме салкыннардан саклаган.
Кичләр буе йонын язып, эрләп,
Бәйлим диеп, әнкәй ятмаган.

Бик кадерләп саклыйм соңгы парын,
Сирәк кенә аны киямен.
Әнкәй кулларының җылылыгын
Мамык йоннарында тоямын.

Барыбер юлны табам

Күз алларым томан
Чыгалмамын сыман...
Нигә, Ходай, мине
Гел сыныйсың һаман?

Уйларымда буран
Ак юрганын сырган.
Атлап булыр микән?
Чыгалмамын сыман...

Юк, чыгарга кирәк!
Атлыйм алга таба.
Юк, атларга кирәк!
Хәзер юлны табам!

Яран гөлләрем

Яран гөлем кызыл чәчәк атты
Тәрәз төпләремне балкытып.
Эх, яшисе иде янып-кызып,
Сүндермичә йөрәк ялкынын!

Яран гөлем алсу чәчәк атты
Алсуланып таңнар атканда.
Таң артыннан яңа көннәр туды,
Яшәү матур, ямен тапканда!

Яран гөлем ап-ак чәчәк атты
Аклык белән бизәп көннәрем.
Күңлемне пакьләп,
тәрәз төбем ямьләп
Чәчәк ата яран гөлләрем!

Таллыкое

Тешне сындырырлык салкын суы,
Сусауларны бастык җәйләр буе.
Балачакның хатирәсен саклый
Җанга якын чишмә – Таллыкое!

Кер чайкадык агач улагында,
Су ташыдык аннан еллар буе.
Җанга рәхәт, тәнгә сихәт бирә
Көмеш сулы чишмә – Таллыкое!

Суларында энҗе бөртекләре,
Талларында парлы кошлар туе.
Челтер-челтер ага туктамыйча,
Мәңгелек ул чишмә – Таллыкое!

Болытлар

Зәңгәр күктә ак болытлар ага,
Хәтфә болыннарда мин ятам.
Чәчәк иснәп, болытларны күзләп
Хыялланырга мин яратам.

Серле җанвар сыман ак болытлар
Еракларга алып китәләр,
Сахраларга илтеп җиткерәләр,
Диңгезләргә мине илтәләр.

Гөлбакчалы илләр, комлы чүлләр...
Бар җиһанны айкап гизәмен!
Күрер өчен Җирнең гүзәллеген
Болытларга утырып йөзәмен.

Әллә каян чыккан кара болыт
Һавалардан җиргә кайтарды.
Дәһшәтләнеп килгән җил-давылы
Күңелемне минем актарды.

Битләремә төшкән тамчылары
Әйтерсең лә тамды каныма.
Кара болыт кара шомын салды
Әрнеп өзгәләнгән җаныма.

Кара болыт кара козгын сыман
Ябырылып төште җирләргә.
Дөньяның да ак-карасы була,
Төрле яктан исә җилләр дә.

Алып килде җилләр ак болытлар,
Кара болыт качты күгемнән.
Яңгыр үтте, балкып кояш чыкты!
Кара уйлар китте күңелдән!



«Кыска гомерле йолдыз». Татарстанның атказанган артисты, Татар дәүләт опера һәм балет театры солисты Шәфика КОТДУСОВАны сәнгать белгече Зәйнәп Хәйруллина шулай дип атый. Күктәге йолдызлар да мәңгелек түгел, алар да сүнә, әмма йөз-мең еллар буе очсыз-кырыйсыз җиһанга нур сибеп, яктыртып тора торганнары да бар икән. Йомшак-ягымлы, моңлы, югары лирик колоратур сопрано тавышка ия җырчы Шәфика Котдусова опера театры сәхнәсендә тудырган образлар – Алтынчәч, Сусылу, Карлыгач, Гөлйөземнәр, чит ил классикларының үлемсез әсәрләрендәге героинялар халык күңелендә уелып калган икән, димәк, сәнгать дөньясында аның үз урыны, үзе яулаган биеклек булган. Йолдыз кебек нурлы, якты шәхес дип бәяләүләре юкка түгел.

Роза
МУЛЛАНУРОВА

«ХУШ, ЯКТЫ ЙОЛДЫЗЫМ»

«Мин бәхетле»

Мәгърифәтле, динле зыялылар гаиләсендә туып-үсүе аның бәхетедер, мөгаен. Йосыф Рәхимовның нәсел-нәсәбе Сембер ягында, Яңа Мучали авылы муллалары булып торган. Йосыф дин сабакларын әтисе Исмәгыйль хәзрәттән ала, Буа мәдрәсәсен тәмамлый. Сәләтен, дин эшенә күңеле ятуын күреп, шул якның хәллерәк кешеләре акча җыеп, аны Төркиягә укырга җибәрә. Истанбулда ул кырымлы Исмәгыйль Гаспралы белән якынаеп китә. Укып бетергәч, дусты аны Кырымга кайтып, шунда мәчет төзү эшләрен үз кулына алырга күндерә. Севастополь–Акъярда беренче, бердәнбер дин йорты сафка баскач, шул чакта Бахчасарай шәһәре башлыгы булып эшләүче Гаспринский үзе Акмәчетне ачу тантанасына килә. Ике гаилә аралашып, дус яши. Гаспралының җәмәгате Зөһрә ханымның Сембер эшкуарлары Акчуриннар нәселеннән булуы да эзсез үтмәгәндер, якташлар бит! Кызы тугач, Йосыф хәзрәтнең Шәфика дип исем кушуның да хикмәте бар: Гаспралыларның кызы да Шәфика атлы ич!

Ничек кенә гаҗәп тоелмасын, имам йортында азан-намазлар гына түгел, көй-җырларга да урын түрдән. Хәзрәтнең ишле гаиләсе җыр-музыкага битараф түгел, чөнки Одессада үскән җәмәгате Фатыйма ханым моңлы көйләргә гашыйк. Тукай иҗатын яттан белә, татар халык җырларын ярата.

Әнисе моңлана башласа, Шәфика шым була. Мөкиббән ул җырга. Кызның теләген сизеп, әтиләре каяндыр тотылган пианино юнәтә. Укытырга Одесса опера театры концертмейстеры булып эшләгән Елена Остромен-

скаяны чакырталар. Шәфиканың сәләт-мөмкинлекләрен ачу, үстерүгә остазы зур өлеш кертә. Тәҗрибәле музыкант аны Мәскәү консерваториясенә әзерли. 16 яшендә Шәфика Камил абыйсы белән Мәскәүгә килә. Кабул итү имтиханнарында педагоглар кызның сәләтле, әзерлекле булуын бәяли, билгеләре дә яхшы. Ләкин укырга керүчеләр исемлегендә ул үз исемен тапмый. Мулла кызы дигән бер сүз юлына киртә кора. Киртәләр еш һәм күп очраячак әле аңа. Бу беренчесе, әмма соңгысы түгел. Тукайча: «...тибәм дә аударам!» дип котыла да алмастыр.

Кайгырып утырмый, кире Акъярга кайта. Камил абыйсы оештырган уен кораллары ансамбле Очаков урамындагы милли клубта татар көй-моңнарын уйный. Абыйлары Наил мандолина кылларын чиртә, Фазыл гармун телләрен биетә. Соң, Шәфика читтә калырмы?! Ә бәлки спектакль әзерләргәдер?! Уйлаган эш – беткән эш! Азәрбайҗан композиторы У. Гаджибековның «Аршын мал алан» музыкаль комедиясен сәхнәләштерәләр. Чиратта – М. Фәйзинең «Галиябану»ы! Гөлчәһрә роле дә, Галиябану да, әлбәттә, Шәфиканыкы!

«Мине яраттылар»

Юрист булып эшли генә башлаган Абдраим Котдусов Шәфиканы сәхнәдә күреп гашыйк була. Кичке спектакльләрнең берсен дә калдырмый йөри торгач, очрата да, мәхәббәт аңлатырга тотына егет. Әмма кыз сорарга барса, Йосыф хәзрәт сүзен өздереп: «Юк, кыз яшь әле. Укысын, һөнәр алырга кирәк!» – ди. Кыз урлау мөселманнарга ят гадәт түгел. Бәлки, кәләш үзе дә каршы килмәгәндер...

Ә Йосыф хәзрәт моны олы фаҗига итеп кабул итә. Өч көн өеннән чыкмый, берәү белән дә сөйләшми. Якыннары Шәфика исемен телгә алырга да курка.

18 яшьлек Шәфиканы улы Җәвидне табар алдыннан ире әниләре янына Симферопольгә кайтарып куя. Симферопольнең Җәмигъ мәчете имамы Котдус хәзрәтне егерменче елларда кызыллар аткан. Абдраим исә мулла малае булуын яшереп партиягә керә. Укый, юрист һөнәре ала, җаваплы эшләрдә эшли. Карасубазарда прокурор була. Җае чыкканда йөк төяү, бушату ише кара эштән дә чирканмый, чөнки аның өстендә ике гаилә: яшь бала белән хатыны өйдә утыра; ятим калган ике сеңелкәше, әнисе дә аның ярдәменә мохтаҗ. Ә партия көн дә фидакарьлек, зур эшләр күрсәтүне көтә. Ерак бер авылга колхоз рәисе итеп җибәрәләр аны. Халыкның, янәсе, яшерелгән, ә чыны – актык ризыгын: икмәген, терлеген, ит-маен, киптереп кышка әзерләгән җиләк-җимешен җыярга! Тентергә, тартып алырга! Гади халыкны талау сәясәте белән килешмәгән, чыгышын яшергән рәисне ни көтә? Партиядән чыгаралар. Эшкә урнашу мөмкин түгел: Котдусов эш эзләп, чынлыкта эз югалту өчен, илдән чыгып китәргә мәҗбүр. Әмма Мәскәүдә да эш әзерләп куймаганнар аңа.

Димәк, Шәфикага үз көнен үзенә күрергә кирәк. Әти-әнисе еракта, алардан ярдәм өмет итә алмый – ата ризалыгын алмыйча башлады ич тормыш юлын.

Шәфиканың уллары яшьтән үк Тукай шигырьләрен ятлап, туган телдә аралашып үсә.

Әле ярый сигез сыйныф белеме бар. Заманасы өчен белемле, грамоталы хатын ул!

Керчьтагы балык эшкәртү трестының планлаштыру бүлегенә эшкә урнаша. Музыкага гашыйклыгы, остазының дәресләре ярдәм итә, тавышсыз фильмнар күрсәтелгәндә, караңгы залда фильм эчтәлегенә туры килә торган көйләр, дөнья классикларының билгеле әсәрләрен пианинода уйнап, халыкның күңелен ача. Тапер һөнәре күптән инде тарих чүплегендә, ә ул чакта бу эшне иң оста пианистлар гына башкара алган.

Шәфика 1934 елда икенче улын таба. Абдраим кайткалап-киткәләп йөри. Эрнст Тельман исемен ошатып, улына Эрнст дип куша. Ә әби-бабай өчен ул – Ирек. Рәхимовлар белән Котдусовларның арасы якынаюга сабый-илче сәбәпче була.

Шәфика эштә, төш вакытында кайтып сабыен имезә. Бала карарга авыл кызын табу читен түгел, илдә ачлык, азык-төлек талонга гына бирелә. Талонга тигәнне дүрт җанга бүлү кыен. Фатыйма абыстай килеп кызына ярдәм итмәсә, малайларның олысын Акъярга алып китмәсә, тагын да авыррак булыр иде.

Җаны-тәне белән җыр-музыка дөньясын үз иткән Шәфика эштән соң баласын күтәреп трест клубына репетициягә йөгерә. Ял көннәрендә ул тапер!

Ниһаять, гаилә башлыгы Абдраим да берничә буталчык эшне уңышлы башкарып чыгып, Мәскәүдә үзен сәләтле юрист-адвокат итеп таныта. Аңа фатир вәгъдә итәләр. Канатланып, гаиләсен алырга дип кайтса...

Ничек кенә гаҗәп тоелмасын, Мәскәүгә күчеп, хуҗабикә булып өйдә утыру ихтималы сөендерми хатынын! Аерым яшәгән авыр еллар көч биргәнме, үзенә ышаныч уятканмы, әйтүе кыен. Укырга теләвен, музыкаль белем алу хыялы белән яшәвен иренә аңлатырга тели ул. Уйлый торгач, аңлый аны ире, килешә!

26 яшьлек Шәфика Симферополь музыка училищесына укырга керә. Вокал-җыр бүлегенең – беренче, фортепиано классының икенче курсында укый. Фортепиано классын бер елда тәмамлап кырым татар җыр һәм бию ансамблендә солист-вокалист, шул ук вакытта Кырым радиосында концертмейстер-аккомпаниатор булып эшли башлый.

«Сәнгатькә, халкыма хезмәт иттем»

Казан гөрли. 1941 елның июлендә Мәскәүдә үтәчәк татар сәнгате һәм әдәбияты көннәренә әзерлекнең кызган чагы. Опера һәм балет театрында чыгыш ясау, шул бәйрәмдә катнашу Шәфиканың да иң зур хыялы бит! Тик ничек? Ул – Кырымда, ә ире бу хакта ишетергә дә теләми. Ашкынулы йөрәк хәйлә корып карарга була: янәсе Мәскәүдә яшәүче рәссам абыйсы Наил, сеңлесен

Ипле, зыялы ир аны чын-чынлап ярата. Чәчәкләр, бәхет, сөенечләр гүя күктән иңә.



«Башмагым» (Җәүдәт Фәйзи) комедиясендә – Сәрвәр ролендә. 1954 ел. Фото: Нариман Гарипов.

ашыгыч кына чакырып, телеграмма суга. Мәскәүдә поезддан төшүгә сеңлесенең кулына билет тоттыра Наил. Казанга! Шәфика, канатланып, хыялындагы театрга оча.

...Камал театры бинасында репетиция бара. «Алтынчәч»не декадага әзерләүче баш дирижер Җәләл Садриҗиһанов янына зифа буй-сынлы, тулган ай кебек балкып торган йөзле бер чибәр килеп баса. «Мин Кырымда үскән татар кызы. Хыялым – Алтынчәч партиясен җырлау. Тыңлап карагыз мине!» Берәүгә дә билгесез кызның әрсезлегеме бу? Кыюлыгы, тәвәккәллеге ошыймы, гүзәллеге әсир итәме – тыңлап карарга булалар. Югыйсә Алтынчәчне җырларга атлыгып торучылар бихисап. Беренче көнне үк Галия Кайбицкая җырлаячагы да инде хәл ителгән. Икенче составта җырларга да җиде җырчы дәгъвалый.

Менә бәхет, «Алтынчәч»кә «җан өргән» композитор, театрның сәнгать җитәкчесе Нәҗип Җиһанов та, комиссия әгъзалары да лирик колоратур сопрано тавышлы бу җырчының көтелмәгән табыш икәнен аңлап ала. «Сандугач» булып сайравы – әнисеннән откан бормамелизмнарга бай моңы, «каян килгән бу билгесез?» дип икеләнүчеләрне дә үз ягына аудара.

Канатланып-очынып өенә кайтса... Ире өздереп: «Юк!» – ди. Чыннан да, ире хаклы. Хатын, гаилә хакын хаклап, Мәскәү кадәр Мәскәүне ташлап кайтты бит ул! Туган ягында эш тапты. Кырым татар телен дә, русчасын да су кебек эчә торган юрист бу якта көндез шәм яндырып эзләсәң дә табылмастыр. Шуңа, ахры, уң килде: күпме каңгырып йөргән Абдраимның эшләре гөрләп бара.

«Эшләмичә, күңелең өчен җырлап йөрсәң дә акчага интекмәбез. Сәхнә дип талпыну, ике балалы әнигә сәхнә дип тилерү нигә кирәк?» – дип аптырый ул.

Ярата бит ул хатынын. Хатыны да ярата аны. Дөрес, бер болганмый су да тынмый дигәндәй, аларның да болганып алган чаклары булды. Ике-өч ел элек Шәфикага, «бавыр», дип, Кырым санаториенда дәваланырга кушканнар иде.

Бер көнне санаторий клубына керсә... Фортепиано! Утырды да җилләнеп уйный башлады. Күпме уйнагандыр, алкышлар ишетеп туктап калды. Халык җыелган. Тагын, тагын уйнаттылар аны. Ә берсе, килеш-килбәте дә, сөйләшү рәвеше дә чын зыялыларга тартым яшь кенә чибәр егет, фортепиано артына – янына утырды. Шәп уйный! Музыканттыр, күрәсең. Ул уйнаган көйгә Шәфика романс суздьы. Ял итүчеләргә икәүләп концерт куйдылар. Халыкка да ошады, үзләренә дә. Күңел булды! Атна узгач, кайтыр вакыт җиткәч, шул егет каушый-кабалана аңа мәхәббәтен аңлата башлагач, Шәфика кырт кисте: «Мин гаиләле, балалы хатын. Ташлагыз бу уенны!» «Уен түгел, чын йөрәктән... Беренче тапкыр гашыйк булдым! Без бергә булырга тиеш! Аерылыгыз!»

Нинди җен теленнән тарткандыр, кайткач, көлеп моны Абдраимга сөйләде.

Абдраимны әйтерсең лә җен алыштырып куйды. Кызды, ярсыды, әллә ниләр әйтеп бетерде. Ә Шәфика рәнҗеде аңа: «Әгәр миңа ышанмыйсың, тугры булуыма шик белдерәсең икән, аерылышыйк!» – диде. Каенсеңлесе Зәйнәп арага керде, акыл бирде. «И-и, абый! Ирләр бер чыбыктан сөрелгән икән, хатын-кыз да үзләре сыман дип белә. Әгәр хыянәт итсә, кайтып сөйлиме моны хатының? Акылыңа кил, чишмә суыдай саф күңелле ярыңны югалта күрмә», – дип киңәш бирүе ярады.

Менә тагын җәнҗал чыгарга тора. Монысына чыннан да Шәфика үзе гаепле, ахрысы. Әйе, Абдраим – аның яшьлек мәхәббәте. Гаиләсе бөтен, әмма... Йөрәкне соң, йөрәкне нишләтәсе?! Үзе өчен генә җырлап йөрүгә риза түгел ич җаны. Сәнгать, сәхнә тарта, чакыра аны! Ата-бабаларының рухы – татар иле тарта торгандыр! Зов души, ди моны руслар. Каршы тора алмый ул бу хискә!

Аерылсак, аерылабыз! Балаларны нишләтәбез? «Ирекне үзем белән алам. Җәвид калып торыр...» Ә йөрәкне соң икегә, өчкә ярып бәхетле булып буламы?

Китте Шәфика. Алтынчәчләр, Сәрвәр, Сусылулар язмышын үзенеке белән бәйләп, газиз халкын моңнары белән сугарырга, күңелләрен уятырга дип китте.

Тулай торакларда, почмаклары бәсләнгән салкын бүлмәләрдә калтыранып уянса да, аның җырын тыңлап хозурланган халыкның җанын җылытырга...

Җәвид Абдраим улы Котдусов истәлекләреннән: «Әти аерылышуны бик авыр кичерде. Соң кайта. Салгалап кайтуын сизеп, эш сәгате беткәнче каршы алырга йөгерәм. Эштән чыкканын саклап торам да аңа иярәм. Икебез бергә кайтабыз. Кайчак киногa керәбез. Миңа урам малае булып калырга ярамый, китаплар укыйм, әтигә эчтәлеген сөйлим. Күңелен күтәрергә тырышам. Ул миңа күбрәк игътибар бирә башлады. Сөйләшәбез... Шулай ай ярым вакыт узды. Әти түзмәде, эшеннән чыгып, Иректне алып Казанга китте. Сугыш башланырга ике ай калган иде. Казанда эш табалмыйча, әти Юдинода эшләп, кайталы-китәле йөрсә дә, гаилә бергә, алар әле бәхетле иде. Мин бишенче классны тәмамладым. Сугыш башлангач, җиңелчә, җәйге киемнәрдән генә Фатыйма әби белән без дә әниләр янына чыгып киттек».

Шәфиканың иң бәхетле көне кайчан булды икән? Алтынчәч роленә билгеләнүе турындагы боерыкны кулга алгачмы? Татар операсын яратып, халык театрга агылып йөрүен күргәчме? Әллә либретто авторы шагыйрь Муса Җәлилнең фронтка китәр алдыннан: «Алтынчәч образын сезне күз алдында тотып иҗат иткәнмен гүяки: саф күңелле, мөлаем, гүзәл хатын-кыз образын тудырдыгыз. Рәхмәт!» дип кулын кыскан мизгелме? «Азат хатын» журналы тышлыгында рәсеме чыгу, халык алкышы сөенеч түгелме?! Эзләнә, осталыгын камилләштерә, укый, өйрәнә ул, 41 яшендә консерватория тәмамлый.

Ләкин... Якты кояш астында беркем, берни дә мәңгелек түгел. Күпме хыялланып көткән декада – Татар сәнгате һәм әдәбияты көннәрен сугыш хәбәре өзде. Гитлер һөҗүм итте. Муса Җәлил, үлемсез «Шүрәле» балетын иҗат иткән Фәрит Яруллин, аның Абдраимы да сугышка китте. Берсе дә әйләнеп кайтмады.

Татар сәнгате һәм әдәбияты атналыгы Мәскәүдә үк булмаса да, Казанда – Качалов театры бинасында үтә барыбер. Абдраимны, хәрби белеме булмаганга, әзерлек үтәргә Казаннан ерак түгел Суслонгер лагерена кайтаралар. Хәрби комиссариаттан рөхсәт алып, улы Җәвид белән Шәфика аның янына күрешергә бара. Баянчы табып, ут эченә керергә әзерләнгән ирләргә концерт күрсәтә. Җырлары газиз ярына юлдаш булыр дип ышана. Бу соңгы күрешү, бәхилләшү икәнен тик күңелләр сиздеме икән? Йөзләгән йөрәкләрне җылытып моң агыла, аны кат-кат сорап җырлаталар. Поездга соңга калудан куркып, ашык-пошык саубуллашу...

Сугыш елларында опера һәм балет театры артистлары госпитальләрдә, авыл, калаларда 700 концерт күрсәткән. Шәфика Котдусова исә 300 ендә катнашкан.

«Мин дә яраттым»

Җылы яктан ашыгыч кузгалганга өс-башлары юка, сатып алырга ни акча, ни кием-салым юк. Почмакларын бәс сарган тулай торак бүлмәсендә бишәү: олыгаеп килә торган әниләре Фатыйма апа, фашистлар куып алып китеп кол итеп тоткан һәм шуннан качкан сеңлесе Нурия, ике улы белән Шәфика үзе. Икмәк карточкага. Аны да төн ката саклап алалсаң гына... 13 яшьлек Җәвид хәрби заводта эшли башлагач, аңа икмәк күбрәк тия, ә әнисе белән сеңлесе хокуксыз. Әтиләрен 37 нче елда аттылар. Ире Котдусовның «батырларча, сугышып үлде» дигән хәбәре килде. Кырым татарларын хыянәттә гаепләп илләреннән сөрү шаукымы Шәфикага да кагылмый калмас, ире кырымлы бит – корымлы!

Әллә көнчелек, әллә ни, спектакльләрдән читләштерүләрен башта начарга юрамаска тырышты. Ахыры хәерле булмасын сизенү суырдымы дәрт-дәрманын – тавышы бетте. «Эшкә яраксыз» дип театрдан чыгару турындагы боерык исә үлем җәзасы булып яңгырар дип кем уйлаган. Судта дирижер Җәлал Садриҗиһанов, Хәсби Фазлуллин, атаклы җырчы Фәхри Насретдиновның аны яклап ялкынлы нотык тотулары да карарны үзгәртмәде, судья ирен чите белән генә елмаеп куя. Директор Юрусовның: «Миңа Черек күлдән шалтыраттылар» дию... Хәтта Нәҗип Җиһанов – аның таланты алдында баш июче композитор да КГБ белән бәхәскә керергә җөрьәт итми. Ә 1952 елда, «Алтынчәч»не Бөтенсоюз тавыш яздыру фирмасында яздырып, тарихта калдыру мөмкинлеге тугач, ул нәкъ менә аны – Котдусованы Мәскәүдән чакырып кайтара: Алтынчәч партиясе аның башкаруында яңгырый. Шәфиканы эштән куган директор да: «Нинди талантны югалтканыбызны хәзер генә аңладым», – дип баш кашый. Хәер, аның үзен дә телен теш арасында тотмаган өчен башыннан сыйпамыйлар.

Опера театрындагы гаделсезлек аны аяктан егарга тиеш иде. Ә Шәфикага Ходай көчле рух, эшчәнлек, үҗәтлекне мул биргән. Мәскәү филармониясендә эшли, үзенең концерт бригадасын булдыра. Идел буе, Себер, Урал якларында, Ленинград, Мәскәүдә концертлар бирә. Мәскәүдә, зур залларда И. Козловский, З. Долуханова, С. Лемешев, Р. Байбулатовлар белән чыгышлар ясый.

1952 елның азагында, концерттан соң Шәфика хозурында чибәр ир-ат пәйда була. Кырым санаториенда танышкан, фортепианода уйнап гыйшкын аңлаткан, егерме елдан артык вакыт үтсә дә беренче мәхәббәтенә тугры калган егет – Мамай Алексей Григорьевич икән. Мамайлар токымының ерак бабалары татарлар дип саный, университетта укыта, профессор икән. Сөйләшеп – сүз, бүлешеп истәлекләр бетәрлек түгел. Җитәкләшеп йөреп таң аттыралар. Бер-берсенә тартылган ике йөрәк бүтән аерылышмый. Бәрелеп-сугылып, хак-нахак гаепләр күтәреп яшәп тә сабыр иткән елларның әҗеред бу! Көнкүреше, тормышы көйләнә, ниһаять. Ләкин...

46 яше тулган көнне – 1956 елның 18 мартында Шәфика туган-тумача, дус-ишне чакырып, мул, затлы табын корып кунак сыйлый, уйный-көлә, үзе берни капмый, үз хәлен беркемгә белдерми, ә иртәгәсен... хастаханәгә кереп ята. Яман чир аямый, нәкъ бер айдан күзе йомыла. Сеңлесе Нурия соңгы хатын табып ала:

«Мин бәхетле, сәнгатькә, халкыма хезмәт иттем. Мине яраттылар, мин дә яраттым. Беркемгә дә рәнҗемим. Мине Казанга алып кайтып җирләгез».

Г. Камал театрында җырчыны озату мәрәсимендә соңгы мәхәббәте – Мамай да чыгыш ясый. «Хуш, минем якты йолдызым!» дип, сүзен саф татарча тәмамлый.


Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА

Эльмира Шәрифуллинаның хатын-кызларга багышланган шигырьләр шәлкемен тәкъдим итәбез. Шагыйрә милләт аналарын, халкыбызның талантлы кызлары – танылган шәхесләрне күңел дөньясы аша үткәреп, аларга дан җырлый. Аның гүзәл затлар галереясында – композиторлар, җырчылар, рәссамнар, язучылар, сәясәтчеләр, укытучылар... Һәркайсы авторга таныш, ул күбесе белән аралашкан, иҗади дуслыкта булган.

ҖЫР СОРАП ТИПКӘН ЙӨРӘК БАР...

Бибимәмдүдә

Габдулла Тукайның
әнисе Бибимәмдүдә абыстайга

Каберең кә киләм, изге Ана,
Күземнән – кан, җаннан яшь тама.
Чарасызлык кыскан ул заманда
Кем гаепле Сине, сүз яга?

Бәетләрең бер кырыйда торсын,
Сезнең язмыш мәгълүм чагында.
Җир упмаса, горурлану хисе
Һич туктамас халкың җанында.

Сигез оҗмах насыйп булсын Сиңа,
Насыйп булсын барлык хөрмәтләү.
Гөнаһ булыр шигырь яза торып,
Табына торып, дәхи сүз әйтмәү.

Кешелеккә син Тукайны бирдең,
Җир башында чишмә булдырдың.
Нинди теләк теләп йөрдең икән,
Нинди дога укып тудырдың?

Син дөньяга илаһи зат бирдең,
Кеше бирдең, Бибимәмдүдә.
Син дөньяга бөек Шәхес бирдең,
Шагыйрь бирдең, рәхмәт, Мәмдүдә!

Күрәсе килә

Шагыйрә Гөлшат Зәйнашевага

Гөлшат апа,
Гел шат апа,
Күрәсе килә Сине,
Назлы, сихәтле сүзләргә
Төрәсе килә Сине.
Йомшак, ягымлы тавышың
Сагындырды бит инде.
Юри юксындырдым, диеп,
Йөгереп килеп җит инде.

«Гайфиләрне өйләндерик»,
«Меник Уралтауларга».
«Сандугач»ың сихәт бирсен
Җаны тере, сауларга.

Гөлшат апа,
Гел шат апа,
Юллыйм сәлам хатларым:
«Ак бураннар ярып чапсын
Җыр төягән чаптарың!»

Бирегез мәйдан!

Шагыйрә Нурия Измайловага

Туып кына киләм –
Шатланыгыз күреп.
Җыр сорап типкән йөрәккә
Җилләр генә өрмәсен.
Хис кадерен белмәүчеләр
Килмәсен дә йөрмәсен.

Туып кына килгән чагы,
Һавада сөю өне.
Гашыйк күңелнең колачлап
Сафлык ташыган көне.
Мыскалланмаган ефәктәй
Асыл зат була икән.
Чат сөюдән генә йөрәк
Торса да тора икән.

...Җыр сорап типкән йөрәк бар –
Ягез, мәйдан бирегез!
Күктән төшмәгән бу бәхет –
Кадерләрен белегез!

Кычкырып җырласын.
Ә сез
Җырдан такыя үрегез!

Саҗидә апа

Шагыйрә Саҗидә Сөләймановага
Ай-ли, Саҗидә,
Керләр чайкый сай җирдә...
(халык җыры)

Алкын суга карап уйга чумам,
Дәрья буйларына киләм дә.

Сәҗидә апа,
Ай-һай, керләреңне
Чайкагансың икән тирәндә.

Бөтерелеп ага дәрья суы,
Күтәрелә көмеш күбекләр.
Басма өсләрендә – ак сөлгеләр,
Түрләмәләр –
Кершән кебекләр.
Шундый нәфис, гүя берәмтекләп
Таң нурына манып алынган.
Һәркайсына сеңгән балан исе,
Алан исе сеңгән җаныңнан.

Сәҗидә апа, ап-ак керләреңне
Чайкагансың бигрәк тирәндә.
Ак сурәтең калды күңелләрдә,
Пакь эзләрең йөргән җирләрдә!..

Рәссам

Рәссам Алсу Тимергалинага

Моңланып җәй чигә,
Кулларың көз чигә
Кәгазьгә, ефәккә, диварга.
Кузгатып күз явын,
Сеңдереп буявын,
Тотындың җырлы юл сызарга.

Кулларың яз коя,
Кайчакта кыш сыя
Рамлы кечкенә киндергә.
Айлы төн – ал таңлы,
Таңнарда тиң парлы –
Могҗиза илендә сез бергә.

Кулларың урманнар,
Елга, тау, кылганнар
Ясыйлар күңелгә, күзләргә.
Көч алып урманнан,
Ямь табып кылганнан,
Нур куна сүрелгән йөзләргә!

Калебегез якты чәчә

Мөгаллимә Лина Нәҗметдиновага

Хатын-кызга чибәрлек тә,
Зифа буй да бик кирәк.
Ә Сез тагын, Лина дустым,
Иманлы, Затлы, Зирәк!

Тирән Акыл биргән Ходай
Сезнең нәсел-нәсәпкә.
Әниегезне, ярыйдыр,
«Фәрештәгез!» дисәк тә.
Тирә-юньгә, белгәннәргә
Өлге дә, маяк та Сез!

Сезне белеп шатланучы
Кавеменнән мин һәм без.
Калебегез якты чәчә,
Илаһи бер нур белән.
Олы сөю белән сөйсен
Рафаилең гел-гелән!

Сезгә – Лина ахирәтем,
Сокланып бетеп булмый.
Зур ихтирам хөрмәт илә
Кунагың шигырь юллый.

Милләтемнең зифа каены

Җырчы Зифа Басыйровага

«Бәхете дә, тәхете дә булмас,
Бигрәк моңлы кызың, Фәрхинур, –
Дия торган була Мөслим халкы, –
Киләчәген төргән сихри нур...»
Тәхеткәе олы сәхнә булды,
Бәхетен дә тапты шул юлда:
Туган халкын,
Үзенең татар халкын
Изрәтте моңлы дулкында.

Ятимлектә үсеп кеше булды
Басыйр кызы, җырчы Миңзифа.
Бригада төзеп юлга чыкты:
Мәскәү, Киев, Тула, Ош, Уфа...

Мөслименә атап җыр чыгарды,
Ыгы белән күңелен сугарды.
Йөрәк хисен «Шөгер», «Минзәлә»гә,
«Арча», «Сарман»ына тугарды.

«Хуш, авылым» –
визит карточкасы –
Йөрәк каны сеңгән җыруы.
Олы бәхет туган якларында
Зифа кебек затлар булуы!

Исеменә җисемкәе тәңгәл,
Ихлас хезмәт итте халкына.
...Эчтән янган,
көйрәп-көйрәп янган,
Әмма ләм-мим үзе хакында.

Без ахырдан белдек, соңлап белдек
Фаҗигасен, авыр тормышын.
Авыл халкы, Ыкта чагылгандай,
Әйткән икән алдан язмышын.

Күз алдында, зифа каен кебек,
Сәхнәләрдә басып торуы.
Кешеләрнең күпме җәрәхәтен
Дәвалады аның җыруы.

Дәвалады, дәрман, куәт бирде,
Яшәү көче бирде меңнәргә.
Ә үзенә нинди сабырлыклар
Кирәк булды икән түзәргә?..

Милләтемнең зифа ак каены,
Мөслимемнең зифа Ык талы!
Сагыш сарган моңлы
йолдызларның
Иң яктысы безнең яктагы!.

Моңның йөрәге — синдә!

Композитор Сара Садыйковага

Туган җиргә табынгансың,
Давыл булып кабынгансың,
Кар-бураннар ябынгансың
Көйләреңдә, Сара апа!

Күңелләрдән саркыгансың,
Ефәк нурлар талкыгансың,
Йолдыз булып балкыгансың
Көйләреңдә, Сара апа!

Гөл, чәчәк булып шыткансың,
Утлы күмерләр йоткансың,
Туфан-су булып купкансың
Көйләреңдә, Сара апа!

Шул моңнарың – кышта, көздә,
Шул моңнарың – йөздә, күздә,
Яши илдә, яши бездә,
Моңның йөрәге – Синдә!

Һич китмәссең кебек иде арабыздан,
Искә төшсәң, сагыш сарка
ярабыздан.
Көйләреңнән илһам алып,
сихәт алып
Яши күпләр
Синнән – моңчы апабыздан!

Яшибез. Тик...
Сагынабыз, Моңсарабыз,
Апастагы Тутайга да гел барабыз,
Хыялларга кайтарып
бер терелтәбез.
Мизгел үтә –
Тагын синсез без китәбез...

Һич китмәссең кебек иде арабыздан,
Искә төшсәң, сагыш сарка
ярабыздан.
Бүген дә бит илһам алып,
сихәт алып
Яшибез без
Синнән – моңчы апабыздан!



Казан дәүләт университеты, «Кызыл таң» газетасы, «Азатлык» радиосы, «Идел», «Сөембикә» журналлары... Болар һәркайсы Ландыш Әбүдәрованы иҗат дөньясына күтәргән баскычлар. Бүген ул «Казан утлары» журналының җаваплы секретаре. «Мандариннар» хикәяләр китабы Ландыш Әбүдәрованы укучыларга үзенчәлекле язучы буларак ачкан булса, «Октябрь һәм бәләкәй тылсымчы» әкиятләр китабы исә балаларга зур бүләк булды. Игътибарыгызга авторның Бөек Ватан сугышы елларындагы авыл тормышын тасвирлаган хикәясен тәкъдим итәбез.



Ландыш ӘБҮДӘРОВА

ЙОЛА

Миңниса карчыкның үзе генә белгән бер йоласы бар: гыйнвар суыклары тәрәзәгә – бизәк, агачларга – бәс, өйалларына сыкы сарган кояшлы бер көнне иртән-иртүк тора да кичтән кертеп калдырган каен утынынннан чыра телеп, кече мичкә ягып җибәрә. Аннан соң кичтән баш ясап, изеп калдырган күәс чиләген сәндерәдән ала, аңа җылытып – сөт, эретеп ак май һәм бер уч чамасы шикәр сала, әйбәтләп болгата, шуннан вак иләктән генә иләп, ак он кушып, озаклап баса да ак сөлге белән каплап, чиләкне кече мич өстенә җылынырга алып куя.

Гыйнвар кояшының җылысы кысыр булса да, яктысы күзләрне камаштырыр дәрәҗәдә мул була бит аның. Әнә шул җемелдәп торган яктылык аш өстәленә төшә башлауга, Миңнисаттәй ашыкмый-кабаланмый гына тәрәзә каршына куна тактасын куя, аның өстенә сибәләп кенә он җәйгәч, чиләктәге камырны төшерә. Һәм такта өстендә күпереп яткан йомшак болытны кадерләп кенә, иркәли-иркәли баса башлый. Аның бик күп төрле эшләрне эшли белгән бармаклары ул болыт белән гүя сөйләшә: ни хикмәттер, камыр Миңнисаттәйнең кулына ябышмый да, ул ничек әвәләсә шуңа риза булып, куна өстендә үзенә бер салмак бию башкара кебек. Җитез бармаклар арасында камырдан ялгыш кына аерылып киткән он тузаны, әйтерсең лә тәрәзәдән төшкән яктылык буйлап кояшка омтыла...

Миңнисаттәй камырның җитәрлек дәрәҗәдә әзер булуын әллә каян гына тоемлап, аны йомшак тастымалга бераз тын алырга дип төреп куя да ипи табаларын хәстәрләргә керешә. Үзе белән бергә картайган табаларны мич башыннан алып, кече мич алдында җылыта, аны каз каурыйларыннан ясаган канат белән майлап, куна янына китереп тезә. Шуннан инде янә камырын алып, аны бүлеп-бүлеп, сыйпап-сыйпап, савытларга тигезләп салып чыга һәм күперсен өчен янә кече мич өстенә куя.

Бая телгән чыра белән олы мичне тергезеп җибәрә, коры утын четер-четер итеп яна башлагач кына, Миңнисаттәйнең йөзенә бер олы, үтә дә җитди гамәл кылганнан соң була

торган җиңеллек йөгерә. Аның йөзендәге шушы гали һәм садә җитдилекне берәү дә күрми диярлек, ул аны берәүгә дә күрсәтми дә.

Кышкы зәмһәрир суыкларда әнә шушы рәвешле татлы ипи пешерүе үзенә күрә яшәүгә мәдхиясе аның. Әллә кайчангы – еракта калган 1942 нең гыйнварындагы вакыйгаларны искә төшереп, тантана итүе. Менә бүген дә каникулга кайткан оныкы аның йөзенә чыккан бу тантананы күрмәде. Бигрәк озак йоклый инде хәзерге балалар. Кояш та уята алмый. Хәер, бераздан тәмле күмәч исе һушын алып уятыр әле үзен. Аның исе йоклаганны гына түгел, мәрткә киткәннәрне дә уятырлыктыр, валлаһи. Ә болай уянмавы яхшырак – сөйләштереп, әбкәсенең эшен, алай гынамы – уйларын бүлеп тик йөрер иде. Ә Миңнисаттәй ипи пешергәндә бүлдергәнне бер дә өнәми. Бүлдерә торган түгел аның уйлары, алар да менә шушы түгәрәк ипекәй кебек бербөтен.

Ул елны кыш әче салкыннары белән үзәккә үтте. Сугыш башланган елны бөтен дөньясы безгә каршы, дөньясы гына түгел, хәтта ки табигате дә мәкерләнә кебек иде. Дошманның җан өшеткеч салкын тыны инде башкала өстендә сизелә, диләр. Фронттан килеп ирешкән яңалыклар көннән-көн шомлырак, дәһшәтлерәк була бара. Кыш та көннән-көн зәһәрләнә. Башкаладан ерак түгел яу кырларында күккә ашардай булып җәһәннәм ялкыннары котыра да, икенче көнне хатыннарның йөрәкләрен көлгә әйләндереп, ил буйлап кара кәгазьләр тарала. Миңниса да авылда беренче булып алды андый кәгазьне. Ире Әхмәтнең соңгы хаты белән бергә килеп җитте. Хатындагы: «Балаларны сакла», – дигән әманәте васыять булып иреште... Икенче булып ахирәте Зәйнәпкә килде кара хәбәр. Миңниса кияүгә иртәрәк чыгып, өч бала – ике кыз, бер ул тапкан иде. Зурысына 8 яшь, кечкенәсенең 2 генә яше тулып узган килеш тол калды. Зәйнәп бала таба алмады, ичмасам, юанычы да калмады бит. Эшкә йөрәкле чая хатынны ире урынына бригадир итеп куйганнар иде, иренең батырларча һәлак булуы турында ишеткәч, Зәйнәп дошманга кара үч белән көйде. «Фронтка китәм!» – дип, гариза белән барса да, син монда кирәгрәк дип, алмадылар. Ул бөтен көчен бригадага бирде. Эшне оештыра белде анысы, беренче булып үзе тотына иде. Урып-җыюны алдынгы булып тәгәлләделәр, хәтта планны арттырып үтәделәр. Кырда сыңар бөртек башак та калдырмыйча җыеп тапшырдылар дияргә була. Фронтка җылы кием-салым тегеп, оекбаш-бияләйләр бәйләп җибәрүне дә, ихаталардан сөт җыю эшен дә башлап җибәрде. Берәүне дә аямады Зәйнәп, «Фронт өчен!» – дип, үзе өй рәтеннән йөреп чыкты. Әллә каян ялкынлы сүзләр сөйләргә дә өйрәнеп алган: өй саен кереп, оялта-оялта үгетли иде: «Сез монда җылы өйләрегездә ятканда, ирләрегез, улларыгыз, этиләрегез, абыйларыгыз салкын окопларда тилмерә! Сез иртәгә уянасыгызны белеп йокларга ятканда, алар өсләренә кайчан бомба төшәр икән, дип черем итә! Сез монда йомшак мендәрләр өстендә рәхәт чиккәндә, алар баш астына автомат куеп ята! Сез монда өреп суыта-суыта кайнар чәй эчкәндә, алар салкын ризыкка да сөенә...» Ул шулай сөйләгәндә, карчык-корчык авызын яулык очы белән каплап ләхәүләсен кабатлый, хатыннар, аның карашын күтәрә алмыйча, тагын да ныграк эшкә бирелә, балалар әниләренә елышып елый башлый иде.

Кышка таба бирердәен биреп бетергән Миңниса ахирәте Зәйнәпнең карашыннан кача башлады. Соңгы вакытта: «Сөт нормасын киметәсең», – дип кисәтеп тора. «Сыерыбыз буаз, бозауласын инде, аннары күбрәк булыр», – дип караса да, Зәйнәп ишетергә дә теләми: «Син булып син сүземне аяк астына салып таптасаң, мине кем тыңлар?! – дип зәһәрләнеп кенә җавап бирә. – Балаларыңа азрак калдыр, сугыш вакытында сөт эчмичә дә торырлар!»

Миңниса дәшми, болай да тамаклары туйганчы ашаганнары юк, сөтне дә кашыклап үлчәп кенә салып бирә. Әхмәтенең соңгы сүзе бит ул балалар, ничек итеп авызларыннан ризыкларын тәмам өзмәк кирәк! Зәйнәпнең сүзен сүз итим дип, болай да көнне төнгә ялгап чаба Миңниса. Аның да дошманга нәфрәте көчле. «Аталары үлде, әмма оясында тагын өчәү калды әле аның, болай гына юк итә алмассың безне!» – дип, дошманга үч итеп шушы өч баланы кеше итәсе килә аның.

Зәйнәп тә көрәшә. Беркөнне Миңниса, сыерның җиленнәрен тарткалап, ярты чүмеч чамасы гына сөт савып кереп сөзеп йөри иде. Ишекне каерып ачып, салкын болыты ияртеп, ажгырып килеп кергән Зәйнәпне күргәч, ниндидер гаеп эштә тотылгандай каушап төште хатын.

– Әйттем бит, урлашасың син, дип. Газыйм абый, менә кара, – диде Зәйнәп, үзе артыннан кергән колхоз рәисенә борылып.

Миңниса сөт сөзгечен кая куярга белми аптырап торганнан соң, ике кулын да артына яшерде.

– Нәрсә яшерәсең? – дип, Зәйнәп ике атлап бер сикерде дә ахирәтенең кулыннан сөзгечне тартып алды.

Шунда гына аңына килде Миңниса. Болар юкка каныга түгелме соң? Нинди гаеп эшләгән әле Миңниса? Нәрсә, хәзер мәңге җиңелмәс дигән Кызыл Армия буаз сыерның ярты литр сөтенә калганмыни? Әхмәтнең утка кереп башын салуы гына җитмәгәнмени?

Тол хатын боларны кычкырып әйтеп тормады, аклану көтеп, бәбәкләрен үзенә терәгән бу икәүгә аркасын куеп басты да савыттагы сөтне өч йомрыга салып балаларына тоттырды. Элеккеге ягымлы Зәйнәп апаларының соңгы вакытта ажгырып йөрүенә ияләшкән балалар әниләре ни кушса, шуны үтәргә әзер иде – йомрыларны сүзсез генә кулларына алдылар да «хәзер нишләргә?» дигәндәй, әниләренә төбәлделәр.

– Кайсының кулыннан ала аласың, Зәйнәп? Ал! – диде Миңниса тыныч кына.



Чынлап торып карак тотарга кергән Газыйм абый югалып калды. Бер – Миңнисага, бер Зәйнәпкә карап торганнан соң, хатын-кыз сүзе тыңлап йөрергә туры килүенә үртәлеп, аны-моны аңлатып-нитеп тормыйча гына чыгып китте. Картлык көнендә сызлаган аякларын җылы мичкә терәп, улларына акыл өйрәтеп кенә ятасы урында, колхоз хәтле колхоз рәисе булып, тормыш тәртәсенә җигелеп тарт инде! Өстәвенә, менә шушы ятимнәрнең күпме сөт эчкәнен санап йөрергә дә калгач соң... Тьфү! Бер сугыш җитмәгәнме аның гомеренә?

Аның каравы, Зәйнәп отыры кызды:

– Мин моны болай гына калдырмыйм! – дип янап, пыр-пыр килеп чыгып китте. Миңниса ахирәтенең танымаслык булып үзгәрүенә гаҗәпләнде дә, борчылды да. Әллә соң үзе үзгәрдеме? Әллә соң ул үз кайгысын кайгы итеп йөреп, ил кайгысы турында онытып җибәрәме? Әнә бит, Зәйнәп җаны-тәне белән...

Берничә көннән Миңнисаны районга чакырттылар. «Район кадәр районга тикмәгә генә чакыртмыйлар, – диде Зәйнәп Миңнисаның «Ни йомыш белән икән?» дигән соравына каршы. – Рәхмәт әйтергә түгелдер, шәт».

Колхоз эшенә төшкән җиреннән, җыелган оекбашбияләйләрне, кием-салымны илтергә дип җигелгән атка утыртып җибәрделәр аны. Балаларына хәбәр итә, күрше Фәхриҗамал әбигә «күз-колак бул!» дип әйтә алмый калды. «И Ходаем, Азатымның тәне ут яна иде, шул килеш күтәреп кенә бакчага илткән идем, апасы алып кайта алырмы икән инде? Ичмасам, өйгә утын да кертеп калдыра алмадым, алай-болай бүген кайтмый калсам, алай-болай... бөтенләй кайтмый калсам... Их, никләр генә Зәйнәпкә каршы төштем икән соң? «Балаларны сакла, дигән иде бит Әхмәткәем. Ничекләр генә саклыйм?» – дип өзгәләнде ул юл буе. Тышта суык тәнне өтәрдәй итеп куыра, ә аның йөрәге яна.

Колхозның туры айгыры егерме чакрымны сизми дә үтте. Миңниса хәрби комиссариат каршында Фатыйма апасыннан төшеп калганын юньле-башлы хәтерләми дә. Эче тулы уй, күңеле тулы сагыш иде аның. «Фатыйма апакаем, алай-болай кайтмасам, балаларны...» – диде дә елап җибәрде. Нишләтсен инде аның балаларын Фатыйма? Кайтмый калса, төрмәгә яба-нитә калсалар, өч баланы гына ятимнәр йортына илтерләр әле... Аңа кадәр ягылмаган салкын өйдә катып үлмәсәләр. «Бүген кайчан гына кайтып җитсәң дә, Алла хакы өчен, Фатыйма апакаем, минекеләр янына кереп чык, зинһар», – дип өстәде яшьләренә тыгылып. Фатыйма да пышылдап кына: «Ярар», – диде дә дилбегәне какты. Миңниса аның да яшьләренә буыла-буыла эчтән үксегәнен сизеп калды.

– Абый җаным, минем бер гаебем дә юк, алдынгы колхозчы бит мин... ирләр белән бер рәттән эшлим... фронтовик хатыны... иремнең кара кәгазен алдым... зинһар, балаларымны ятим итмәгез, – дип килеп керде ул өзек-өзек җөмләләрен бер-бер артлы тезәтезә. Аңа кадәр шактый озак көтте әле чиратын. Галифе чалбарлы, кирза итекле, гимнастеркалы чал чәчле абый кабинетыннан бер чыкты, бер керде. Ишек артында кем беләндер тыныч кына, кем беләндер тупас итеп сөйләште. Миңниса әле чынбарлыкка кайтты, әле уйларына чумып, бушлыкта йөзде. Күз алдыннан тәне ут кебек янган Азаты китмәде, балаларының салкын өйдә калтырап утырганнарын күз алдына китереп, акылдан шашар дәрәҗәгә җитте. Чираты җиткәндә, теге гимнастеркалы абыйны чакыртып алдылар. Бераздан күңеле күтәрелеп кайтып керде ул. «Мусина!» – дип Миңнисаны дәшкәндә дә, шатлыгыннан учын-учка ышкып утыра иде. Хатын аңа игътибар итеп тормады, гозерен тезде.

– Тукта әле, сеңлем, нәрсә әйтергә телисең? – дип бүлдерде ул хатынны.

– Балаларны сакла, дип язган соңгы хатында... ачка үтерә алмыйм бит инде мин аларны сөт тә эчермичә... – дип, акланыр өчен алдан уйлап куйган сүзләрен берьюлы әйтеп бетерде Миңниса.

Аннан соң теге гимнастеркалы абый Миңнисаны тәфсилләп сөйләткәч: «Бар, сеңлем, балаларың янына кайт. Бүген безнең Кызыл Армия дошманны Мәскәүдән куып җибәргән. Җиңәбез болай булгач! Кирәкмәгәнгә ятим арттырасы юк!» – дип, хатынны кайтарып җибәрде. Иллә дә мәрхәмәтле булды үзе, сөенче уртаклашам дип, өстәл тартмасыннан бер кәгазь алып, аннан ипи талоны кисеп алып бирде. «Бусы ташбашларыңа күчтәнәч булсын!» – дип елмайды.

Очты гына Миңниса. Буханкалы ипине куенына кыстырды да аның хуш исенә исерә-исерә, куанычыннан елый-елый биш атласын бер атлап, авылына ашыкты. Кара, күрми дә тора икән, гыйнвар суыгы сындырып җибәргән, аяк астыннан җирдән себерә торган җил тәгәри башлаган. Көн яктысына карап кына сәгатьне чамалады да хатын, буран көчәйгәнче тугыз авыл юлы кисешә торган Тугыз түбә дигән җирне үтеп калырга кирәк дип, чапты да чапты.

Җәяүлегә ерак шул, эңгер-меңгер тиз арада караңгыга алышынды. Миңниса Тугыз түбәдә адашканын аңлаганда, буран көченә кереп туза гына башлаган иде. Төнгә каршы башланган бураннан рәхим-шәфкать көтмә инде син. Адашкан кешенең хәрәкәтендә бәрәкәт юк аның. Буранда адашканы исә бөтенләй чарасыз. Атласа да – юк, туктаса да... Туктап калса, кар күмеп китәчәк, йә булмаса, катып үләчәк. Атласа, хәле бетеп егылачак. Куенындагы ипие генә өмет чаткысын сүндермичә җылы биреп тора. Миңниса ипекәйнең кибән башын тешләп алды. Тәмлелеге! Менә хәзер тагын атларга була әле...

Күк белән җир тоташкан, әллә Миңниса үзе күккә оча, әллә күк аның өстенә ишелә. Әллә атлый, әллә йөзә ул. Кар көрте аякка ураламы, аяклары болыт аралап барамы... Әллә бүреләр улый, әллә буран. Ул иксез-чиксез караңгылыкта ялгызы калды. Ник бер таяныр нокта булсын? Ул шушы бушлыкта берүзе. Юк, ул үзе таяну ноктасы. Нишләп гел ялгызы соң ул? Әхмәт үлгәннән бирле гел ялгызы. Нишләсә


Рәсем: Наталья Васильева

дә, җиле каршы исә... Кайгы бөтен илгә килде, ә ул менә гел үзе генә күтәрә.

Ә анда – авылда балалар... Саклый алмыйм бит, дип, күңеле тагын әрнеп сызды. Егерме генә чакрым иде бит соң, инде узган юлы да ике тапкыр егерме булгандыр, нишләп һаман кайтып җитми соң?

Күңелендәге өметсезлек, чарасызлык аякларын богаулый, бөтен тәнен кат-кат урап ала. Их... дигәндә генә Миңниса каршында кайсыдыр авылның көздән калган эскерте калкып чыга. Менә шунда аек акыл аңа: «Сиңа исән калырга кирәк! Балалар хакына!» – дип фәрман бирә. Һәм ул эскерткә оя ясап кереп, яктырганчы шунда көтәргә була. «Катып кына үлмәсен балаларым! Азатым... Үләр микәнни инде? Тамаклары ачтыр инде бахыркайларымның... Сыерым да мине көтеп тилмерәдер. Әй Ходаем!» – дип ялвара-ялвара, минутларны саный-саный, саташулы йокыга тала.

Таң атканда, буран тынып җитмәсә дә, бераз басыла төшә. Черем итеп, азмы-күпме хәл җыйган Миңниса да авыл ягын тиз чамалап ала.

...Кайтып керсә, җып-җылы өйдә балалары тәгәрәшеп йоклап ята, бигрәк тә Азаты ике апасының уртасына җәйрәп төшкән. Әле суынып та бетмәгән мич түрендә – чүлмәктә бәрәңгеле аш.

– Зәйнәп апа килде, сөт алып килгән, Азатка мәтрүшкәле сөт эчерде, кайнатып. Бездән бәрәңге алып менеп, аш пешердек. Бездә кунды, сыерга печән салып китте. Әниегез кайтса, шундук бригада өенә төшсен, диде. Син бар инде, тизрәк шунда бар, – дип, бәйнә-бәйнә сөйләп бирде олы кызы. Ул әнисенең кыштыр-кыштыр йөргәненә уянган иде. Канатлар куйдылармыни Миңнисага? Ахирәте янына чыгып та китә алмады, кочагын җәеп Зәйнәп үзе килеп керде. «Без җиңәбез! Болай булгач җиңәбез!» – дип кочаклашып елаштылар.

Куенында саклап алып кайткан ипине дә бергәләп ашады алар. Аннан соңгыларын да бүлештеләр. Менә шуннан бирле Миңниса сөткә изеп, тәмле күмәч пешерә торган булып китте. Боларны оныкларга сөйләп кенә аңлатып бетереп буламыни?

...Әнә инде күмәчнең хуш исе бөтен өйгә таралды. Гыйнвар кояшы тәрәзә аша өйгә тулды. Онык инде торып битләрен юды да әбисенең күмәче белән чәй өлгергәнне көтеп, өстәл артына килеп утырды. Һәм озак итеп, тавыш-тынсыз гына әбисен күзәтте.

– Бәйрәм кебек бүген, – диде ул, күмәч белән чәй эчкәннән соң, әбисенә ияреп, амин тотып куйгач. – Нинди дер бүтән бәйрәм...



Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Шәһәр транспортында банк карталары белән түләп була дигән яңалыкны бик куанып кабул иткән идек. Чынлап та, бар булган сәмән уч төбенә сыешлы шул пластик картада бит. Кайчак кесәдә акча да булмаска мөмкин. Транспортка көн дә утырырга туры килә, һәм карта белән генә түләү мөмкинлеге бик уңайлы буласы иде. Әмма...

Минем банк картасы белән автобусларның валидаторы, никтер, беренче көннән үк уртак тел «табышмады». Бик сирәк очракта гына карта белән түләргә омтылуым уңышлы тәмамлана. Аптыраш, бер маршрутта бар да яхшы – картаны тидерүгә, билет хакын салдыра да ала. Икенче маршрутка утырасың – «картагыз эшләми!» Метрода да бернинди тоткарлык булганы юк. Валидаторның кайсы төймәсенә басасын өйрәнеп калып, кондуктор вазыйфасын үзем башкарган очраклар да булгалады.

Ә беркөнне... Картаны яңаны ясатып алган идем. «Транспорт кушымтасын» активлаштырыйм дисәм, «картагыз кара исемлектә» дигән язу чыга. Банкка язам – картада акча булса, түләү тоткарлыксыз үтәргә тиеш, диләр. «Транспортная карта» компаниясенә шалтыратам. «Картагыз бернинди дә «кара исемлектә» түгел, түләү узарга тиеш. Автобуста бер булса да түләп карагыз, шунсыз хосусый кабинетыгызга кереп, тикшереп булмый», – дип киңәш итте диспетчер ханым. Быелдан автобуслар яңача электрон түләү системасына күчкән, валидаторлар кибетләрдәге касса принцибы белән эшли икән.

Алай-болай түләп булмаса, дип, кесәмә вак акча салып, автобуска утырдым. Ул арада кондуктор егет яныма килеп тә басты. Картамны сузам. «Эшләми картагыз! Акча түләгез!» – ди. Валидатор экранына тагын бер куеп карарга тәкъдим итәм. Әлеге тәкъдимем кондукторга бөтенләй ошамады, кәгазьгә язарга ярамаслык сүзләр белән ямьсез итеп сүгенеп, сумкамны ишектән ыртыгу, телефонымны бәреп вату белән яный башлады. Билет өчен акча түләнгәч тә тиз генә тынычланмады әле. Мәсхәрәләвенә түзә алмыйча, тукталышыма кайтып җитмәсәм дә, автобустан төшеп калдым... Кызганыч, җәмәгать транспортында мондый хәлләр очраштыргалый шул. Югыйсә бит халык арасына эшкә чыккансың икән, үз-үзеңне тотышың гына түгел, хәтта кигән киемең дә йөзгә кызыллык китермәслек булырга тиеш.

Тиздән Республикабыз ТАССРның 100 еллыгын бәйрәм итәчәк. Кунаклар килер, туристлар... Аларга бит республикабызны иң яхшы яктан гына күрсәтәсе иде. Юылмаган автобуслар, тупас кондукторлар шәһәребезне бер дә бизәми.

Галия КАЮМОВА.
Казан шәһәре.

Фото: Анна Арахамия



Хөрмәтле «Сөембикә» журналы редакциясе! Быел Бөек Җиңүне бәйрәм итүгә 75 ел була. Әнием Сәйфетдинова Миңнегайшә Хәмит кызы бу көннәрдә 85 яшен тутырды.

Ул үзен белгәннән бирле «Сөембикә» журналын яратып укып бара. Кешеләр язмышына багышланган язмаларны йөрәге белән кичереп укып чыга, һәрбер санын көтеп ала. Бу язмамны аңа, сугыш чоры баласына әле күзе күргәндә укысын дип язарга булдым.

Әнием, беркайчан да авырма, йөзең һәрчак бүгенгедәй шат һәм көләч булсын!

«...Минем күргәннәрне китап итеп язсаңмы?!» – әнием еш әйтә бу сүзләрне. И бәгырем, авыр чакларда ничекләр түзгәнсең дә, яшәргә көч кайлардан алгансыңдыр? Ялганны өнәмәүче, эчкерсез, киң күңелле, һәр эшне җиренә җиткереп башкарып, башкаларга үрнәк булган әнием! Синең генә чәчләрең үлән кебек йомшак. Синең генә тавышың җил кебек

назлы. Синең генә күзләрең йолдызлар кебек серле. Салкыннарда күңел җылыңны биреп җылытасың, көннәрем син булганга аяз минем. Синең киңәшләрең тормышымда маяк булды. Сабырлыгың, аклыгың, пакьлегең – бу сыйфатларны санап та бетереп булмас кебек.

«Сабый чагымның иң сөенечле мизгеле – әтием Мөхәммәтшин Хәмит сугыштан кайтып кергән көн. Әти кайта дигән хәбәрне ишетүгә, сулышым капканчы авыл башына, әти каршысына йөгерүләрем, аның мине күккә чөеп сөйгәне, башка китмәячәген әйткәне әле дә күз алдымда», – дип сөйләргә яратасың. Беләм инде, әни, каһәр суккан сугыш урлаган балачагың, алты бала әнисе булган Шәмселбәнатның ару-талусыз эшләүләре, кайткач, озак та тормыйча сугыш яраларыннан үлеп киткән әтиең өчен елауларың, яшең дә җитмәгән килеш торф эшенә китеп, «нужа» арбасына җигелүләрең – болар барысы йөрәгеңә уелган истәлекләр.

«...Сугыш башланганда 6 яшем дә тулмаган иде әле. Әнием, ышанып, миңа бик күп эшләр йөкли иде. Олы апа, әниемнең әниләрен карарга күрше Яңа Сала авылына китте. Әниләр көне-төне кырда. Ашарга юк. Өч бертуган сеңел-энеләрем күземә карап ашарга сорыйлар. Бабай белән әби икесе дә урын өстендә ятып авырыйлар. Әти сугышка киткәндә: «Кызым, бөтен ышаныч синдә, мин кайтканчы эне-сеңелләреңне сакла, әниеңә булыш», – дигән иде. Әтинең шул сүзләре мине гомерем буена көчле рухлы итеп яшәтте», – дип искә төшерәсең. Шул вакыттагы юклыкларны, нәни йөрәгең белән аңлаганга, син бүген бик сабыр гына итеп оныкларыңа булган тормышның кадерен белергә өйрәтәсең. Язлар җитүгә болында, бакчаларда яңа тишелгән нинди генә үлән ашамагансың... Салкында чәчү орлыгы ташу дисеңме, нәни кулларың белән урман кисүме – берсеннән дә калмагансың. Сокланабыз, әнием, сиңа! Тормышыңда әтиебез, (хәзер мәрхүм инде) Балтач авылының «Алтын куллы» Хәмәтгаяны очраган. 49 ел бергә гомер итеп, дүрт бала тәрбияләп үстергәнсез.

Каты авырып, урында яткан кайнанаң – Шәкүрә әбине дә син тәрбияләп озаткансың, ул да бит «синең кулың йомшак, килен, гомер буе игелек күр», – дип күзләрен йомган.

Туганнарыңны да син барлап торучы булдың, җиде буын әби-бабайларны белергә тиеш икәнлегебезне дә аңлатып торасың. Олы апабызның ире балаларының берсенә 6 ай һәм 2 яшь булганда 27 яшендә дөнья куйды. Син бит, әнием, ул ике баланы да үз канатың астына алып, тәрбияләп үстерүче. Шул 2 яшьлек онык – Илнар, бүген төп йортта үз гаиләсе белән яши. Аллага шөкер, бүгенге көндә сигез оныгың һәм алты оныкчыгың бар. Барыбыз өчен дә сабыйларча сөенеп, хәер-дога кылып, кадерле әни, дәү әни булып, кунактан кунакка йөргән мәлең. Исән-сау гына була күр, газизебез!

Тиздән Бөек Җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итәр көннәр дә килеп җитәр. Үзе исән булмаса да, бабабызның фотосын күтәреп, Җиңү көнне «Үлемсез полк» акциясендә катнашабыз. Менә шулай тормыш дәвам итә...

Әнием һәр көнне сугышлар, ачлыклар булмасын дип елый-елый теләк тели. Әтиләре сугышта үлгән сугыш чоры балаларының пенсиясенә йөз сум булса да өстәмәсләр микән, ди. Менә бу акча сугыш аркасында әтисез үскән өчен түләнә дип, күңелемә тынычлык алыр идем, ди. Бәлки, бу сүзләрдә хаклык та бардыр?!

Индира ИЛАЛОВА.
Балык Бистәсе районы,
Балыклы Чүкәй авылы.

Элеккеге вакытларда мин «Азат хатын» журналын һәрвакыт ала идем.

Ә «Сөембикә»не быел гына ала башладым. Журнал матур, эчтәлекле, миңа бик ошый.

Менә журналның икенче санындагы «Капкын» язмасын укыдым да, автор фикере белән килешмәдем, чөнки анда иң беренче шарт – тулы гаилә булу, диелә. Мин алай уйламыйм. Әлбәттә, бу минем фикер, шуңа үзем турында язып китим әле.

Мин авылда туып-үстем. Укыдым, авыл интеллигенциясе булдым. Үзем шикелле яшь егеткә кияүгә чыктым. Башта әйбәт кенә яшәдек. Аннан хәмер куллана башлады, тавыш-гауга күбәйде, кыйнап ташлаулар, ызгыш-талаш... Аерылышу гарьлек иде, барысына да түзәргә тырыштым, чөнки мин абруйлы, яхшы тәрбия алган кыз булып үстем. Бераз шулай яшәгәч, шәһәргә чыгып китәргә уйладык. Шәһәргә күчкәч, ике еллап бик әйбәт яшәдек. Отпускларга кайтабыз, бездәге дуслык-татулыкны күреп туганнар сөенеп туя алмый. Авылда яшәгәндә ул бик каты кыйнаганлыктан, мин инде бала табар хәлдә түгел идем. Дусларыбызның барысының да баласы бар, без генә сабый сөя алмыйбыз. Уйладык та, гаиләгә бала алырга булдык. Шулай итеп, озакламый уллы да булып куйдык. Аңа ул вакытта бары өч ай иде. Ә безнең ызгыш-сугышлы тормышыбыз яңадан әйләнеп кайтты.
Бу юлы инде түзмәдем, аерылдым. Әмма аерылганчы тагын бер кыз алырга өлгердем. Кызым – әле яңа туган, 11 көнлек нарасый иде. Ирем белән бөтенләйгә араларны өзгәндә улыма – 5, кызыма 1 яшь иде. Ялгыз калганыма сөенеп, рәхәтләнеп балаларымны тәртипле, миһербанлы итеп тәрбияләдем. Икесе дә гаилә корды, инде үзләре дә балалар үстерә. Әлхәмдүлилләһи, пенсиягә чыккач мәдрәсәдә укып, дипломлы абыстай булдым. Менә тулы булмаган гаилә тарихы. Әнкәй, дип, бөтерелеп торалар. Балаларым үсеп җиткәннән бирле безне үрнәк гаилә дип йөртәләр: бу сөенеч түгелме?! Шуңа күрә тулы гаиләдә тынычлык булмаса, ялгыз бала үстерү хәерлерәк түгелме икән?!

Ә ул шулай хатын-кызлар сайлыйсайлый йөрде дә, үз-үзенә кул салды, инде 20 ел җир куенында ята. Балалар үскәндә ялгыз анага зарланмыйча яшәү авыр булса да, тормышыңдагы тынычлык күпкә кыйбатрак. Балаларым бәхетле, үземә 80 яшь, исән-сау йөреп торам, Аллага шөкер.

Гыйбрәт булсын өчен язам.

Сәлам белән, Мәдинә апагыз.
Азнакай.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

ДИЛБЕГӘНЕ ҖИБӘРЕРГӘ БУЛДЫМ...


Фото: www.pixabay.com

Казанда яшәгәндә аларның барысы да бик әйбәт иде. Ирек – белеме буенча икътисадчы, Алия – дизайнер. Олы улларының мәктәпкә, кызларының балалар бакчасына барыр вакыты җиткәч, туган якларына – Түбән Камага күченергә уйлады яшь гаилә. Җаның теләгән балалар бакчасына, якындагы мәктәпкә эләгү, ай-һай, катлаулы шул хәзер башкалада. Дәү әти-дәү әниләре дә якында гына булыр, диделәр. Шулай итеп, Казандагысын сатып, Түбән Камадан яңа фатир алып, гаилә яңа тормыш этабы башлады. Әмма язмышның яңа бите барысын да үзгәртер, гаилә сынауларына бай булыр дип кем уйлаган соң?..



Раилә
ХӘЯЛИЕВА

Алия – күптәнге танышым. Бер йортта, төрле подъездларда яшәдек. Икебез дә кызларыбыз белән әниләр һәм бәбиләр өчен оештырылган курсларга йөрдек. Ачык күңелле, сөйләшергә ярата торган уңган хатын дип беләм мин аны. Декрет ялында да һич тик тормады. Төрле мастер-классларда катнашты, үзе дә дизайнерлык буенча марафоннар оештырды. Аның җитезлегенә гел соклана идем! Өйләре дә ялт иткән, Ирек тә канәгать булып эшенә китә, елмаеп кайтып керә. Тик менә Түбән Камага күчкәч, Алиядән күңелсез хәбәрләр килә башлады: «Тормыш бармый әле, малай...», «Ирек юлдан язмаса ярый инде», «Бер үзгәреш тә юк бездә...» Якты булып күренеп торган киләчәк бу гаиләгә бөтенләй килешмәгән төсләр белән чуарланды. Гаилә башлыгы кулындагы йөгәнен бушата төште... Бәхетле көннәрне яңадан кайтарыр өчен чын хатын-кыз зирәклеге, олы сабырлык соралды Алиядән. Казанга килгән арада чәй эчәргә кергән иде әле. Түкми-чәчми барысын да тәфсилләп шунда сөйләде ул:

– Өйләнешеп өч ел яшәгәч, беренче балабыз туды. Беләсең инде, шуннан бирле гел декрет ялында булдым. Гаилә учагы саклаучы хатын-кыз идем бит. Әни кеше – баласына үрнәк, дип, гел матур киенергә, формада

булырга тырыштым. Өйдә мәш килгәнемне, тегесен-монысын үзгәртеп торуымны әй ярата иде Ирек. Кызыбыз тугач, гаилә бәхетебез тагын да артты, мин – чын хуҗабикә, Ирек кайгыртучыбыз булды. Инде минем декрет ялыннан эшкә чыгар вакытым җиткән иде. Ирек тә, мин дә Түбән Камадагы төрле оешмаларга алдан ук резюмелар җибәреп куйдык, эшләр белешкәләдек. Ике шәһәр арасында күченеп йөргән көннәрдә берничә җирдән эшкә чакырулар алдык. Күчеп кайтуга төрле җирләргә әңгәмә узарга йөри башладык. Озакламый мине фатирларга дизайн ясый торган фирмага эшкә алдылар. Кызыбызны балалар бакчасына урнаштырдык, олы улым берничә айдан мәктәпкә керергә тиеш иде инде, шуңа ул йә дәү әниләрендә, йә әтисе янында өйдә калып торды. Мин эшкә чыктым. Клиентларыбыз сирәк, әмма бик бай кешеләр иде. Дизайнерлык белән күптән мавыккач, башкалада алган белемнәрем дә булгач, эшкә бик тиз ияләндем. Фикерләремне хуплап кабул итүләре мине бик илһамландырды. Ә Ирек эш эзләвен дәвам итте... Башта берничә җирдән кире бордылар. Инде бер компаниягә алабыз дигәннәр иде, барып карагач, эшен ошатмады. Күңелгә ятышлы эш урынын сайларга кирәк, без инде хәзер йомышчы малай кебек анда-монда чабып йөри алмыйбыз, азрак көтеп карыйм әле, диде. Үзенең яхшы эшкә урнашасына, кирәкле кеше икәнлегенә ышанычы зур иде аның. Мин ирем белән килештем. Бу юлы да күңеле яткан эш килеп чыгар, сәләтле белгечкә кая да юл ачык, дип илһамландырырга тырыштым. Шулай көннәр уза торды. Гаиләдә дүртәү генә булсак та, чыгымнарыбыз шактый иде. Ай бик тиз уза: фатир, балалар бакчасы өчен түләүләр килеп кенә тора. Кием-салым, ашау-эчү, интернет... Фатирыбыз яңа булса да, су системасы эштән чыкты, аны ясатырга туры килде. Әбием әйтмешли, акчасыз урамга да чыга торган заман түгел бит. Тупланган мая су кебек агып чыгып китә торды. Ирек бертуктаусыз вакансияләр тупланган сайтлардан эш эзли. Ә мин бер генә мөмкинлекне дә кулдан ычкындырмаска тырышам. Өстәмә заказлар алам, ял көне гаиләгә ашарга бирәр нәрсә әмәллим дә, онлайн консультацияләр бирергә компьютер артына утырам. Үземне бөтен нәрсә өчен җаваплы итеп тоя башладым. Нишләтәсең,Ирекнең шундый вакыты, дидем. Ә ул отказ арты отказ ала... Ирек әлегә өйдә булгач, кичкә ризык әзерләү, кайбер вак-төяк мәшәкатьләр аның өстендә булачак, дип килешкән идек. Беркөнне кич мине бик күңелсез каршы алды ул. Ягымлы гына сөйләшергә, хәлләрен сорашырга керештем. Берни дә эндәшмәде. Икенче, өченче көнне дә йөзендә нур күренмәде. Ә дүртенче көнне өйдә каты тавыш чыкты. «Балалар да кара, ашарга да пешер, эш тә эзлә, сез моны ничек күз алдына китерәсез?» – диде ул усалланып. «Мине хуҗабикә урынына күрәсезме әллә?» – дип җикеренде. Бездә мондый тавыш чыкканы юк иде әле. Балалар, куркышып, бүлмәләренә постылар. Тел очымда «өйдә булган кешегә боларны гына эшләп кую кыен түгел бит инде», дигән сүз бөтерелсә дә, ничектер, дәшми кала алдым. Мин дә тырышам бит инде, балаларның да көен көйлим, кайтканда кибеттән сумка

Инде акча эшләвем дә күңелгә ләззәт бирми башлады. Ниндидер эшче ат кебек сизә идем үземне.

тулы азык-төлеген күтәреп керәм. Гаиләне бит ничек тә алып барырга кирәк, акча табарга... Ә акча турында Ирекка, гомумән, бер сүз дәшмим. Кызгана идем мин аны, нинди әйбәт белгеч үзе, ә эшкә чакыручы юк. Ир кешегә хатын-кыздан акча сорау уңайсыздыр дип, икебез дә белгән җиргә акча алып кайтып куям. Казанда яшәгәндә ул шулай итә иде. Дөресен генә әйткәндә, үзем дә бик арыдым ул вакытта, энергиям эреп юкка чыга барды. Эштән суырылып кайтып керәсең – өйдә киеренкелек. Гаиләне икенче көнгә әзерләргә дип йөгерәм-чабам да, арып авам. Иртән йокы туймаган килеш тагын чыгып йөгерәм. Үземне кайгыртырга, элеккечә матурлык үзәкләренә йөрергә, массаж алырга вакыт та, мөмкинлек тә юк иде... Ул вакытта бездәге күңелсезлекне күрсәң! Хәтта өй стеналарында, төрле почмакларда пәрәвезләр күбәйде. Мин чистартам, алар әллә кайдан килеп чыга тора. Көн саен җыештырсам да, өйдә тузан арта. Дөрестерме, чындырмы, өйдә берәрсе үз-үзенә урын тапмаганда, уйлары белән чәчелгәндә өйдә тузан күбәя икән – ахырдан гына белдем аны. Ирек өчен телевизор якын дуска әйләнә барды, ул КХЛ чемпионаты статистикасын фатир өчен килгән счет-фактурага караганда әйбәтрәк белә иде бугай. Элеккечә шаяра-шаяра утырып сөйләшкәнебез дә юк. Кибеткә чыгып китеп, бераз озаграк торып кайтса, эчеп кайгысын басып йөрмәсен дип котым оча... Нишләсәм дә, мин – чарасыз. Елмаеп дәшеп тә карыйм, назларга да телим – кул гына селти... Күңелемнән генә иремә ярдәм итү юлларын эзли башладым. Таныш-белешләр аша эш урыны белешеп карыйм, юаткан булам... Төннәр буе Ирекка хәерле эш сорап белгән догаларымны укыйм, нишләп кенә мондый көнгә калдык, сәбәбен аңласам иде дип ялварам.

Беркөнне Facebookта күземә бер язма чалынды. «...Әгәр дә тормыш йөгәнен үз кулыгызга алгансыз икән, ир-ат аны яңадан үзе сорап алыр дип көтмәгез инде. Һәм аны гаепләмәгез дә!» дигән фикер яңагыма сугып, мине уятып җибәргәндәй итте.

Икенче көнне Ирек «Эссен»га консультант булып эшкә урнашып караганын әйтте. Кире борганнар...

Өченче көнне мин, авырыйм дигән сылтау белән, эштән сорап өйдә калдым. Балаларны озаткач, эчемдә ут янганны сиздермәскә тырышып, бәлеш әзерли башладым. Ирекне җиләк-җимеш базарына җибәрдем. Сатулашып, бераз экономия ясап кайтса, үзен зур эш эшләгәндәй хис итеп йөри ул. Өйдә, күңеле булсын әле!

Бәлешне духовкага озаттым да, китап киштәсе янына килдем. Элек-электән психологиягә багышланган китаплар укырга ярата идем. Шул китапларны идәнгә тезеп салдым. Йә, бүген миңа кайсы ярдәм итә алыр?! Берсен карыйм, икенчесен, өченчесен... Китапларны

Иреңә булышыр өчен иң элек үзеңне тыңлый белергә кирәк. Гаиләдәге бөтен кеше өчен дә әни булырга ярамый.

күбрәк актарган саен, боларның миңа киңәшче түгеллеген аңлый барам. Без барыбыз да күп укыйбыз, күп беләбез. Әмма үзебезне читтән карап бәяли белмибез бит! Иң авыры да шул!.. Мин кәгазь белән ручка алып язарга утырдым. Уйларны җыеп, бер нәтиҗәгә килә алмаганда, җавап табуның шундый бер ысулы бар: ак кәгазь битенә уйларыңны, борчуларыңны язасың, күп итеп, баш бушаганчы барысын да кәгазьгә төшерәсең. Кирәкмәгән йөктән бераз арынгач, бушанып калгандай буласың: фикерләр ачыла, көндәлеге сорауларга җаваплар килә башлый. Мин дә үз җавабымны шулай таптым.

Ирек җиләк-җимеш күтәреп кайтып кергәндә мин инде эштән китәргә карар кылган идем. Әлегә гаиләм һәм шәхси консультацияләрем белән генә шөгыльләнәчәкмен.

Мин шулай итеп йөгәнне җибәрергә булдым...

Өйгә бәлеш, мәтрүшкәле чәй исе таралды. Ирек хуш исле алмалар, мандариннар алып кайткан иде. Яңа фатирыбызда, ниһаять, беренче тапкыр икәүләп чәй әзерләдек. Чәй эчкәндә Ирекка җайлап кына эштән китәргә уйлаганымны әйттем. «Өйдә генә эшләрмен, сезне ешрак күрәсем килә. Калган җаваплылыкны үзеңә тапшырам, Ирек, син булдырасың ул!» – дидем. Ул әлбәттә, бераз аптырап калды, әмма каршы да килмәде.

Шулай итеп, үзем теләп яңадан хуҗабикә булдым.

Тәрәзә төбендә яңа гөлләр үсә безнең хәзер. Шуларга сулар сипкәндә гел уйланам: Ирекне кызганып, үз урынын таба алмаган бала итеп күрә башлаганмын. Үзем дә аңламыйча аңа бу рольне тәкъдим иткәнмен, ә ул аны бик рәхәтләнеп кабул иткән... Ир кешене тыңлый белү җитми, ишетә дә белергә кирәк. Ир кешегә һәрдаим үзенең кирәклеген белгертеп тору, рәхмәт әйтү мөһим. Аны ничек кабул итәсең, ул шундыйга әйләнә, кызгансаң – кечерәя, ышансаң, үзенә ышанычы арта, таулар күчерердәй була.

Татлы тортлар пешерергә өйрәндем, илһам килгәндә рәсем ясарга утырам. Өй җылысы аңа да, балаларга да көч биргәнен яхшы беләм хәзер. Эш аты булырга без – хатын-кызлар бик тиз өйрәнәбез, ә менә ирне ир итәм дисәң, беренче чиратта үзеңнең теләкләреңә ирек бирергә, ә ир кешегә яулар өчен яңа үрләр билгеләп торырга кирәк икән. Менә шундый фәлсәфәләргә бирелә-бирелә, янәдән хатын-кыз булырга өйрәнәм.

Ә Ирекнең эшкә урнашканына инде өч ай була. Икебез дә эшсез утырганда җыелып килгән бурычларны аның беренче премиясе белән яптык. Миңа яңа киемнәр алдык. Янәдән массажга йөри башладым.

Ирек тырышса булдыра ул, мин аңа ышанам!



Роза ШӘФИЕВА,
психолог

Язмада бүгенге көн өчен бик актуаль тема күтәрелгән. Чыннан да, ни өчен хатын-кызлар тормыштагы бар җаваплылыкны үз җилкәсенә алырга тырыша? Беренчедән, әгәр тормышны әнисе тартып барган гаиләдә үскән икән, кыз бала үзе дә шул сценарийны кабул итә һәм гаилә йөген үзенә ала. Икенчедән, ир кеше хатын-кыз идарә иткән гаиләдә җитлеккән булса, үзенең гаиләсендә дә ул әни малае ролен сайларга тырышачак. Гаиләнең төп кайгыртучысы ролен алу аңа шактый авыр бирелергә мөмкин. Бергә яши башлагач, гаиләдә хатын-кыз иренә ни дәрәҗәдә ышанырга әзер, барысы да шуннан торачак. Ирнең бер-ике уңышсызлыгын күрүгә, хатын-кыз, «мин үзем», дия башлый. Хатын-кызга бит үзенә ышану, үзенчә эшләү күпкә җиңелрәк! Шуңа күрә гаиләдә кем нәрсә өчен җавап бирәсен башта ук төгәл бүлешергә кирәк. Ә хатын-кызлардан сабыр, ир кешегә карата түзем булу сорала.

Әлбәттә, һәрбер ир кеше дә «кадерлем, син өйдә генә утыр, мин тормышны үзем алып барам», – дип әйтергә әзер түгел. Шулай да, хуҗа булу, мал табу – ирләрнең геннарына салынган, шуны онытмагыз, кызлар! Иң мөһиме – минем әйбәтрәк килеп чыга, үзем барысын да булдырам, дип, аларга аркылы гына төшмәгез. Янәшәсендә үзеннән алданрак чабучы булганда ир кешегә тормышта мотивация калмый. Андый вакытта аңа эш тә табылмый, юлы да уңмый... Чөнки эчтән генә үзен кирәксез кеше итеп саный башлый. Менә ни өчен ирләргә тормышыгызда аның иң мөһим кеше булуын сиздертеп торырга кирәк!

Язма мисалындагыча, ир кешенең үзенә ышанычын югалтуы бик авыр хәл. Мондый вакытта «синең бар да килеп чыгачак, мин һәрвакыт синең яныңда, бергә булганда уңышка ирешәчәкбез», дигән сүзләрне кызганмаска иде. Үз-үзенә ышанычын кайтарганда гына ир кеше алга таба атлый ала. Иң мөһиме – мондый вакытта ирләрне кызганырга я-ра-мый!!! Алдагы уңышсызлыкларына карап, гаиләне аның кулына калдырып булмый дип нәтиҗә чыгарырга ашыкмагыз. «Минем хәлемнән килми, син генә безне бәхетле итә аласың, син тотынганда гына алга бара алачакбыз. Син безнең терәгебез, гаилә башлыгыбыз, бөтен өмет синдә», – дип, ир кешенең кулына тормыш җаваплылыгын тоттырырга кирәк. Гаиләнең төпкә төшеп баруын, ир кешене үзегез генә тартып чыгара алмавыгызны аңлаганда һич уңайсызланмыйча психологка мөрәҗәгать итәргә була. Сез бит гаилә бәхете өчен көрәшәсез! Ни өчен кеше үз юлыннан тайпылган, бу уңышсызлыклар аңа нинди сабак бирә – алга барыр өчен менә шуларны аңлау мөһим.

ЧЫН ХАТЫН ИРДӘН РЫЦАРЬ ЯСЫЙ



Искәндәр СИРАҖИ, журналист, язучы

Ирләр күзлегеннән

Без үскәндә ир кеше – гаилә башлыгы, хатын-кыз гаилә учагын саклаучы буларак кабул ителә, шулай тиеш дип уйланыла иде. Бүген дөнья шундый нык үзгәрде ки, ир-ат белән хатын-кызның урыны алмашына башлады. Ир вазыйфасы белән хатын-кыз вазыйфаларының гасырлар буена сакланып килгән бүленеше бетә, бары җенес бүленеше генә калып бара. Ир-ат белән хатын-кыз арасында хәзер тигезлек, вазыйфалар да тигез, диләр. Шулай икән, алайса ир кеше хатыны урынына бала тапсын! Ике арада берничек тә тигезлек булалмый. Аллаһы Тәгалә дөньяны яралтканда ук һәркемнең урынын, вазыйфасын тәгаенләп куйган инде.

Узган гасырда туган, шул чорда үскән кеше буларак, миңа кешелекнең элеккеге кануннары якынрак та, аңлаешлырак та. Ир кеше – гаилә башлыгы. Гаиләсенең иминлеген кайгырту, ашату-эчертү, киендерү нәкъ менә аның бурычы. Монда башкача фикерләү була да алмый. Бу – дин буенча да шулай. Аллаһы Тәгалә ир-атны хатын-кыздан өстен итеп яралткан икән, ул бит хатын-кызны үзенә кол итеп тотсын димәгән. Киресенчә, аны тормыш авырлыкларыннан, акча табу, гаиләсен тәэмин итү вазыйфаларыннан азат итү өчен бирелгән ул өстенлек.

Гаиләне тәэмин итү, муллыкта яшәтү өчен ир-атка бик каты тырышырга кирәк. Кайчак хәтта үзеңнең теләкләреңә каршы килеп, горурлыгыңны җиңеп булса да, гаиләң яхшырак яшәсен өчен күңелең тартмаган эшләргә дә риза буласың. Тормышта әллә нинди авыр ситуацияләр килеп чыга. Минем үземнең дә булды андый вакытлар. Редакциядә журналист булып эшләп алган хезмәт хакым гына җитмәгәч, берәрә өстәмә эш итеп таксига да чыктым. Мин инде танылган журналист идем, урамнарда мине таныйлар иде. Шул ук вакытта үзем белгән кайберәүләр 10 мең хезмәт хакына риза булып, «миңа җитә» дип, диванда корсак үстереп ятты.

Гаиләм тагын да яхшырак яшәсен, мохтаҗлык тоймасын дип, төннәрен таксида эшләвемнең бер оятын да күрмим. Эшнең нинди ояты булырга мөмкин?! Эшләмичә, хатын тапканны көтеп, шуңа риза булып яшәү оят! Бу бит альфонслык дип атала. Үзен хөрмәт иткән, чын ир санаган кеше хатын җилкәсендә көн күрми. Теләсә нинди эшкә алына ул. Берничә эштә эшли, әмма гаиләсен интектерми. Сез әйтерсез, белеме, тәҗрибәсе, диярсез, эш таба алмаска мөмкин, имеш... Белгечлеге буенча үзе теләгән эшне ул, бәлки, мәңге таба алмас! Көтеп утырсынмыни инде хәзер лаеклы эш килеп чыкканны? Монысы инде эгоизм! Аяк-кулы сау-сәламәт ир ничек эш таба алмасын?! Эштән күп нәрсә юк! Белемең буенча эш таба алмасаң, йөк бушатучы, ишек алды себерүче булып булса да эшләп торырга була. Гаилә йөген тарту хатын-кызга йөкләнмәгән. Әмма ул шушы йөккә җигелә икән, ир-ат аңа дилбегәне бик теләп тоттыра. «Хатын өстери бит әле», – ди, һәм чын ир-ат булудан туктый. Хатын-кыз эшләсә дә, үзенең кирәк-ярагын алыр өчен генә эшләргә мөмкин.

Безнең татарда бер мәкаль бар: «Ирне ир иткән дә, чир иткән дә – хатын», диләр. Тормышта күп нәрсә хатын-кыздан тора. Ир-ат ул – нечкә инструмент, ә хатын-кыз – хәйләкәр. Шул нечкә инструментта хатын-кыз шулкадәр хәйләкәр итеп уйный ала. Моның өчен Аллаһы Тәгалә аңа талантын да, мөмкинлеген дә биргән. Хатын-кыз үзен ничек итеп тота, ир-ат шундый була. Чын хатын-кыз янындагы ир рыцарьга әверелә. Ул үзен бәхетле, горур хис итә. Аның гаиләсен бәхетле итү өчен тагын да тырышыбрак эшлисе, аларны тагын да рәхәтрәк яшәтәсе килә. Моның өчен ул көченнән килгәннең барысын да эшли, үзен чынлап та гаиләнең башлыгы итеп тоя. Чын хатын-кыз кигән киеме, әйткән сүзе, гамәлләре белән үк ирен шушыңа рухландыра. Ул иренә хәтта исеме белән дә эндәшми: «картым», ди, «әтисе», дияргә мөмкин. Чөнки татарларда бу элек-электән шулай килгән: гаиләдә «панибратство» булмаган. Ирне аны шул дәрәҗәгә җиткерергә кирәк: гаиләсе өчен янып-көеп торырлык булсын. Моның өчен хатын-кызның назы да, акылы да, хәйләсе дә җитәрлек.

«Син фәлән дә син төгән. Әнә тегенең ире шундый уңган», – дип ирен игәүләп яшәгән хатын чын хатын-кыз түгел. Андыйлар иң булдыклы ирдән дә чүпрәк ясый.

Ир кеше үзен баш итеп, гаиләсе өчен әһәмиятле кеше итеп тоярга тели. Ә сез, хатын-кызлар, аңа бу мөмкинлекне бирегез!

Фикерләрне Лилия ГӘРӘЕВА язып алды.







«ӨЗЕЛЕП САГЫНАМ БЕРГӘ ЧАКЛАРНЫ...»

Фронтовик-язучы, шагыйрь Әдип Маликовның «Гомер мизгелләре» дигән китабын укып чыктым. Әлеге документаль әсәрдә автор җәмәгате – танылган шагыйрәбез Сажидә Сөләймановага булган мәхәббәте, икесе арасында бер ел буена җылы хатлар йөрүе һәм әлеге хатлар туачак бәхетле гаиләнең нигезе булуы турында сөйли. Бу әсәр кабат кайнатам белән кайнанам тарихын искә төшерде. Мин аларга килен булып килгәндә, кайнанам олы яшьтә иде инде. Әмма бик якынаеп, бер-беребезгә күңелләрне ачканда, ул миңа берсендә сөйгән яры – булачак ире белән Бөек Ватан сугышына кадәр һәм сугыш елларында җиде ел буе (!) хатлар язышуы турында сөйләгән иде. Кайнатамның аңа язган хатлары исән икәнлегеннән дә хәбәрдар идем. Һәм менә күптән түгел генә ирем аларны миңа тапшырды.
Бу язмам тыл ветераны, Россиянең мәгариф отличнигы Рәхилә Нәбиулла кызы һәм ике Кызыл Йолдыз ордены, күп кенә орден-медальләр белән бүләкләнгән сугыш ветераны, ветеран-укытучы Абдулла Шакир улы Буреевлар турында. Кайнатам вафатына инде утыз елдан артты, кайнанам ахирәткә күчкәнгә дә ун ел булды. Якты рухларына бер дога булсын.

Гөлназ
ИСМӘГЫЙЛЕВА

Абдулла Шакир улы 1916 елның декабрендә Тәтеш өязе Олы Тархан авылында туа. Әтисенең Беренче Бөтендөнья сугышында һәлак булуы турындагы авыр хәбәрне ул дөньяга килгәнче үк алалар. 16 яшьтә тол калган әнисенең Абдулланы үстерергә мөмкинлеге булмагандыр инде: ул башта аны балалар йортында калдыра, аннан әтиләренә кайтара. Бабасы йортында җылылыкның, назның бер генә мыскалын да тоймыйча, «артык кашык» булып яшәгән Абдулланы укырга да бары 11 яшендә генә бирәләр. Аңа 16 яшь тулганда инде әнисе дә вафат була. Ятим егетне Буа шәһәренең Мулланур Вахитов исемендәге мәктәбе сыендыра: мәктәп директоры Шәйхи Шәмсетдинов һәм укытучылар Абдуллага әти дә, әни дә булалар. 21 яшендә генә мәктәпне тәмамлап, остазларының хәер-фатихасы белән мөгаллим булып китә: Буа районының Түбән Наратбаш авылында укыта башлый. 1939 елның август аенда Кызыл Армия сафларына алына, Саратовта танк училищесында укый. Армиягә китәр алдыннан үзе кебек үк ятимлекнең бөтен авырлыгын тоеп үскән Рәхилә исемле мөгаллимә кыз белән таныша...

Рәхилә Нәбиулла кызы 1920 елның ноябрь аенда Буа районының Черки Кильдураз авылында гаиләдә өченче бала булып дөньяга килә. Кайнанам үзе турында бик күп истәлекләр язып калдырган. Анда мондый юллар бар: «Безнең әни бик эшчән һәм уңган иде. Ул безне бервакытта да ач, ялангач йөртмәде. Көнен-төнен эшләде! Безнең биш тәрәзәле өебез, келәтебез, абзарыбыз, мунчабыз да, атыбыз, сыерыбыз, сарыкларыбыз да бар иде. Әни төннәр буе җеп эрләп утыра иде. Үләсе елны, Зәйнәп белән йөкле вакытта, 17 киләп җеп эрләде...» Рәхиләгә 10 яшь вакытта, алты баласын (төпчекләренә ике ай була) калдырып, әниләре мәңгелеккә китеп бара. Гаиләдә һәр бала вакытыннан алда олыгая, олы кызлар бигрәк тә... «1934 елны 7 нче классны тәмамладым. Инде кая барыйм, ни эшлим дип торганда, олы җанлы, шәфкатьле укытучыларым Касыйм Ишмуратов һәм Гөлсем апа Курамшиналар өйгә килделәр, мине Буаның

мәктәпкәчә тәрбия училищесына укырга озаттылар...» Аннан ул педагогика институтында татар теле һәм әдәбияты белгечлеге буенча югары белем ала. Буа районы авылларында укыта.

Ятимлек ачысын тойган ике яшь йөрәк мөгаллимлек хезмәтендә очраша. Алар арасында туган йөрәк хисләре, вәгъдәләшүләр күп еллар буена ике арада йөриячәк хатларга күчә. 1939 елдан башлап 1946 елның азагына кадәр көн саен, атна саен язылган, дәһшәтле сугыш эченнән килгән өчпочмаклы йөзләрчә хатларга, открыткаларга... Алар латин графикасында язылган, күбесенең инде каләм төсе уңа төшкән...

Хатларның һәммәсе дә «Сөеклем Рәхилә!» яки «Бәгърем Рәхилә!» дип башлана һәм гел бер җөмлә белән дәвам итә: *«Хатымның башы белән йөрәгемнән чыккан ялкынлы кайнар сәламнәремне иртәнге таң җилләре аша җибәреп калам. Сәлам соңы буларак, үземнең исәнлегемне белдереп, синең дә исәнлегеңне белеп, сиңа яшьлек тормышыңда зур уңышларга ирешүеңне теләп калам...»*

Әйе, һәр көне генә түгел, һәр сәгате, һәр минуты соңгысы булырга мөмкин дигән уй белән яшәгәндә, беренче эш итеп, әлбәттә, якын кешесенә исән-сау булуын белгерткән Абдулла. Үзенең җылы хисләрен иртәнге таң җилләре аша да юкка гына юлламагандыр. Таң җиле, салкынча булса да, кешене сафландыра, уяу итә, яшәргә өмет бирә, шул ук вакытта яшь йөрәкләр арасындагы хисләрне уята. Сугышның нәкъ уртасында булып – танкы белән ярып барып, үлем белән күп тапкырлар очрашып, яраланып, контузияләнеп, берничә тапкыр хәтта танк эчендә янып та исән-сау кала ул. Мөмкинлеге булган саен Рәхиләсенә хат юллый, аннан да гел язып торуын сорый. Сөйгәненнән килгән хатлар саклагандыр да әле аны!

«Кабат-кабат әйтәм, артык сагынам,
Өзелеп сагынам бергә чакларны.
Шул вакытны искә алу өчен
Язам сезгә сәлам хатларны...
Абдулла.
1941 елның 8 декабре.»

Рәхилә Абдулласыннан килгән хатларны көтеп ала, түземсезләнеп укый. Күп кенә уй-фикерләрен йөрәк серләре сыйган көндәлегенә бушата: *«Мин аның хатларында үземә карата булган якын дуслыкны сизәм. Менә бит ул ничек ачыктан-ачык язган:*

Чит илләрдә күпме яшәсәм дә,
Күңелкәйләремә һәммә нәрсә ят.
Ерак җирләрдән гизеп кайтканчы, көтәрсеңме?
Бәгырькәем, шуннан чыгып әйт.»

Сугыш башланганда Абдулла Сызраньда танк командирына укый. 1942 елның маенда алар дивизиясе Көньяк-Көнбатыш фронтка җибәрелә. Сталинград юнәлешендәге һөҗүмнәрне туктатырга тырышулар барып чыкмый. 1942 елның 17 июлендә Сталинград сугышының оборона чоры башлана.

«Сөеклем Рәхилә! Мин синең җибәргән хатларыңны Мәскәүдә алгач ук, шунда ук җаваплар язып салган идем. Ә бу хатны юлда язарга туры килә. Чөнки кичә Мәскәүдән Украина якларына таба чыгып киттем. Ә менә бүген инде Кызыл Армия тарафыннан азат ителгән Совет районнары аша поездда барам. Бүген кичкә яки иртә белән инде мин фронтовой линиядә булырга тиеш. Поезд шундый кызу бара, хәтта карандашны тоту мөмкинчелеге дә юк. Шуның өчен дә бу хатымны шушы җирдә туктатып торам. Бары исән яшә... Абдулла.
1942 елның 22 июне.»

«...Мин синең 18/VI, 20/VI, 6/VII язган өч хатыңны менә бүген 15 июльдә бергә алып укыдым, тормышларыгыз белән таныштым. Моның өчен сиңа миллионлаган зур рәхмәтләр белдереп калам. Билгеле инде, бу өч хатыңа да җавапны менә шушы бер хатта урнаштырырга туры килә. Һәрберенә аерым-аерым хат язарга минем шартларда һич мөмкинлек юк. Сәбәбе минем һаман да передовой линиядә булуда.

Менә бүген 15 июльдә беркадәр тукталышка туктадык. Кайчандыр моннан өч ел элек груша һәм алма өзеп йөргән Воронеж урамының бер җирендә куе куаклык чыбыкларын үреп ясалган шалашта менә сиңа шушы хатны язып калам. Кем уйлар, моннан өч ел элек шәһәр урамында йөргәндә, көчле урам сугышларында янып сугышырмын дип. Кайчандыр тыныч аккан Дон елгаларында коенган булсаң, ә аңа хәзер бер минут та тыныч агарга мөмкинлек юк. Аңа бертуктаусыз бомба яңгыры явып тора. Әле кайчандыр тыныч вакытта бу куе кара урманнарда карт аучылар ерткыч җәнлекләр аулап йөргән булсалар, монда хәзер кеше аулап йөриләр. Шушы мәхшәрне туктатуны үземнең бурычым итеп саныйм.

Әгәр фронт хәле белән танышасың килсә 13 июль, «Правда» (беренче бит) «Бои на подступах к Воронежу» дигән язманы укы. Анда безнең комиссар Гуляев күрсәтелгән. Чөнки монда бер кәгазь кисәгенә бөтенесен дә яза алмыйсың...
Абдулла. 1942 елның 15 июле.»

Сталинград сугышында Абдулла ноябрь урталарында гына турыдан-туры катнаша. 1942 елның 19 ноябрендә Көньяк-Көнбатыш фронтның танк берләшмәләре һәм пехотасы һөҗүмгә ташлана. 20 ноябрьдә дошман оборонасы өзелә – гитлерчылар чигенә башлый.

Абдулла танк белән дошман танкларын яндырып, батырларча алга бара. Ләкин 1942 елның 2 декабрендә Тацинская бистәсеннән ерак түгел җирдә аның танкына ут каба. Иптәшләрен үлемнән коткарганда, Абдулланың бөтен тәне яна, аяк-куллары йөрмәс дәрәҗәгә килә. Аны Сызраньга госпитальгә кайтаралар. Моңарчы мөмкинлеге булган саен сөйгәненә хат язып салырга тырышкан Абдулладан хәбәрләр килү туктый. Гарипләнгәнлеген белгертәсе, Рәхиләгә авыр йөк буласы килми аның. Тик тәне тазара башлауга, тагын кулына каләмен ала...

«Рәхилә, синең истәлек итеп биргән бер генә рәсмең дә калмады. Моның бөтенесенә сәбәпче сугыш...»

Җылы хисләр белән тулган хат – йөрәк шатлыгы ул. Йөрәге шат сугышчы көчен аны шатландыручыга багышлый.

«Сөеклем Рәхилә! Мин синнән күптәннән бирле хат алганым юк иде. Чөнки моның мөмкинлеге дә булмады. Мин шушы көнгә кадәр фронтта (сугышта) идем.

Сугыш дигәнне үзең аңлыйсың инде. Артык хатлар белән шөгыльләнеп торып булмый. Минем хәлләргә килгәндә, фронттан Сызраньга кайттым. Үзеңнең тормышлар ничек? Мәктәптә нинди яңалыклар бар?

1943 елның 1 гыйнвары.»

Рәхилә көндәлегеннән: *«Бу хатында Абдул үзенең 2 декабрьдә яралы булуы турында яза. Ләкин «ничек?», «Кайсы җире», «Җиңелме ярасы?» – бу турыда бер генә сүз дә юк. Эх, бу кара малай, ни өчен генә минем күңелдә онытылмаслык булып урнашты икән...*

Аның миннән хат алмавы турында борчылып язулары борчуга сала. Ул да мин көткән кебек өзелеп көтә бит. Госпитальдә бигрәк тә көтәдер инде.

7 март, 1943 ел.»

«Соңгы көннәрдә аз гына күңел ачу кичәләре дә булгалады. 15 март көнне эвакуация юлы белән кайткан артистлар үзебезнең клубта русча концерт үткәрделәр. 19 март көнне филармониядән концерт белән килгәннәр иде. Бусы татарлар. Концертлар бик ошады. Бигрәк тә бу җыр...

Ай югары, ай югары,
Айга менәсем килә.
Айга менеп, түбән карап
Сине күрәсем килә.

Җырны Абдулга да язарга уйладым әле.

20 март, 1943 ел.»

«Сөеклем Рәхилә! ...Менә бүген Мәскәүгә килеп төштем. Билгеле, бирэдә дә артык озак тора алмыйм. Шуңа да адрес та җибәрә алмыйм. Хатларны язмый тор. Хәзергә тәмам.

1944 елның 12 мае.»

«Сөеклем Рәхилә! Минем тормышларга килгәндә, үзгәрешсез, фронтовой тормыш. Үзеңнең тормышлар ничек? Мәктәпләрдә хәлләр ничек? Хат алу белән фотоңны хат белән бергә салсаң, мин шат булыр идем.

Фронтовой кайнар сәлам белән, Абдулла.

1944 елның 20 августы.»

«Сөеклем Рәхилә! Син үзеңнең берничә хатыңда фоторәсememне җибәрүемне сорагансың. Монда фронтовой тормыш, сугыш кыры. Бирэдә бит фотографияләр һәм фотографлар юк. Булса да, алар үзләренең төшергечләрен күтәреп йөри алмаслар иде. Әгәр янымда фоторәсемем булса яки төшәргә мөмкинлек булса, бердәнбер якын кешем булган сиңа җибәрмәс идеммени?

1944 елның 25 ноябре.»

«Яңа ел һәм яңа бәхетләр белән! Менә бүген 1944 елның соңгы сәгате һәм минутлары калды...

1944 елның 31 декабре.»

«...Бәгърем Рәхилә, мин синең 1945 елның 28 гыйнварында язылган хатыңны алып, аңа бер җавап язып салган идем. Менә бүген дә кыскарак кына булса да сиңа шушы хатны язып салырга уйладым. Әлбәттә, вакыт барында нигә файдаланмаска, син теләгәнчә булмаса да, менә бу ак кәгазь барлык мөмкинлекләрдән файдалансын.

Бәгърем Рәхилә, минем тормышларга тукталганда, моннан алда язып үткәнемчә үк, үзгәрешсез. Фронтовой тормыш. Тимер атлар кулда. Атлар белән очып походларны үтәсең, авыр көрәшләрне кичәсең...

1945 елның 19 феврале.»

«Сөеклем Рәхилә! Менә шулай итеп яз айларының беренче ае булган, җиңүләрне якынайткан, мартка аяк бастык...

1945 елның 3 марты.»

«Сәлам ерак Германиядән!
Синең җырың җырлаганда
Өмет белән алга чаптык без.
Өмет алдамады, дошман чыдамады,
Җиңүләр белән кайттык без!

Сөеклем Рәхилә! Үземнең хәлләремне белдереп, синең дә хәлләреңне белеп, яшьлек тормышыңда зур уңышларга ирешүеңне теләп калам.

Менә бүген частька кайттым...

1945 елның 9 июне.»

Медальләрнең бирелү вакыты һәм шәһәрләрне азат итү өчен тапшырылган рәхмәт хатлары буенча (Харьков, Варшава, Дойч-Кроне, Альтдамм, Берлин һ. б.) гына карасаң да, Абдулла Буреев бик зур юл үткән. Сугыш тәмамлангач та ул әле тиз генә кайта алмый, ел ярым Германиядә комендатурада хезмәт итә. 1947 елга кадәр гашыйк җаннарны бер-берсенә хатлар бәйләп тора...

1947 елның маенда ике яшь йөрәк, ниһаять, кавыша. Көтеп алган уллары һәм кызлары дөньяга килә. Минем ирем – бу матур гаиләнең өченче баласы – кайнанам белән кайнатам егерме ел бергә гомер иткәч кенә туа.

Рәхилә һәм Абдулла Буреевлар Буа районының Яңа Чәчкап авылында төпләнәләр, икесе дә мәктәптә укыталар. Кайнатам балаларга биология фәнен укыту белән бергә, яшелчә, җиләк-җимеш, авыл хуҗалыгы культураларын үстерүгә дә алына. Аның турында авылдашлары хәзер дә: «Абдулла абый авылыбыз халкын беренче булып җиләк-җимешле, яшелчәле итте, һәммә кешене аларны үстерергә өйрәтте», – дип, олы хөрмәт белән искә ала. Кемнәрне генә олы юлга чыгармый алар! Үзләренә хәерхаһлы остазлары кебек, алар да ятимнәргә аеруча игътибарлы булалар. Халкыбызның танылган шагыйре, ятимлек ачысын күргән Әхмәт Рәшит тә – кайнанам белән кайнатамның укучысы. Ул гомере буе аларның күрсәткән ярдәмнәрен, биргән җылылыкларын онытмады.

Кайнанам белән кайнанам бик бәхетле пар булып кырык ел бергә гомер итәләр. Сугыш яралары кайнатамны 70 яшендә мәңгелеккә алып китә. Кайнанам үзенең соңгы көннәренә кадәр: «Абдуллам белән яшәгән көннәрем өчен Ходайга рәхмәтлемен. Күргән авырлыклар, сынаулар күп булса да, Ходай безне кавыштырды, саф мәхәббәтебез бәхетле итте», – дип кабатлады.

75
ПОБЕДА!
1945–2020

Илгә ябырылган олы кайгы – миллионнарча корбаннар биргән сугыш афәте без – балалар өчен дә зур сынау, балачагыбызны урлаган, бик күпләребезне ятим иткән кара көннәр булып йөрәккә уелып калган. Безнең чор баласы авыр физик хезмәт белән иза чигүләрдән тыш, сәяси яктан кыерсытылу газапларын да башыннан уздырды шул. Искә төшереп, күз алдына китерсәң, җаннар телгәләнә. Ләкин без барысына түздек...

ТРАКТОРЧЫ КЫЗ



Фото: гаилә архивыннан

«Ул вакытта кайсыбызга җиңел булды соң? Һәркемгә авыр иде», – Миңзифа апа Миңнәхмәтова сугыш чоры истәлекләрен әнә шул җөмлә белән башлый. Әле сугыш башланганчы ук язмыш аларның гаиләсен ятимлек, толлык ачылары белән сыный. 1937 елны һич уйламаганда әтиләре вафат була. Биш кызы белән тол калган әниләре дә тиздән коточкыч бәхетсезлеккә тарый. Япь-яшь ананың аягында гангрена башлана. Ярый әле вакытында табибка күрсәтеп, гомерен саклап калалар, әмма аякны кисәргә туры килә. Авылда ирсез көн итүләре болай да авыр, ә аяксыз да килеш?.. Әнисенең төп таянычы Миңзифага 13 яшь, иң кечкенәләре күкрәк баласы гына. Өстәвенә, бу сугыш тагын...

Сугыш башлану хәбәрен 16 яшьлек Миңзифа кырда – ХТЗ тракторы белән чәчү чәчкәндә ишетә. Әнисен һәм сеңелләрен ач үлемнән алып калу өчен балалыктан чыгып та җитмәгән кызга трактор штурвалына утырырга туры килә. 1940 елны Минзәләдә тракторчылар курсын тәмамлый Усай авылы кызы. Югыйсә Хуҗәмәт авылының җидееллык мәктәбендә бик яхшы укый, киләчәктә укытучы булырга хыяллана ул. Хыялларны чәлпәрәмә китереп, илгә фашист гаскәрләре бәреп керә.

Колхозның җелекләрне суыра торган иң авыр эшләре хатын-кызлар һәм яшүсмерләр җилкәсенә күчә. 16 яшьлек тракторчы кызга да йокының, ялның, туйганчы ашауның ни икәнен онытырга туры килә.

Миңзифа ападан тракторчылыкка укырга ничек гайрәте җитүен сорашам. Яшүсмер кызның берүзе тракторга утыруы уен эшмени?! Белмәгәнен сорардай кешесе дә юк бит авылда. Тракторчы ирләр сугышта. Берничә айлык курсларда гына каян барысына да өйрәнеп бетәсең? Ә эшләргә – җирне сукаларга, тырмаларга, чәчәргә кирәк. Колхозда атларның да бик исәпле чагы. Усай авылы кырларында чәчү төгәлләнгәч, күрше авылларның иксез-чиксез басулары сука көтеп ята.

– 1939 елда тракторда плугарь булып эшләгән идем. Шунда аз-маз өйрәнеп, күреп калганга, Минзәләдә кызларны тракторга укыталар икән дигәч, тәвәккәлләдем инде, – ди ул. – Куркып торырлык идемени хәлебез?! Өйдә ашарга ипи юк. Ә тракторчыларга аз булса да икмәк бирәләр. Ул ипине үзем ашамыйм, җыеп барам да, авылга: әнигә, сеңелләргә кайтарам.

Дүрт ай укып, март аенда авылга трактор белән кайта Миңзифа. Тупач авылы кызы Мәвер (Миңзифа апа аның исемен шулай дип хәтерендә калдырган) белән бергә укып, соңыннан бергә эшлиләр. Иң авыры – ялсыз, ачлы-туклы эшләү дә түгел (анысына яшьлек белән түзелгән!), иң авыры – трактор ватылса, аны рәтләү була яшь кызлар өчен. Трактор астына кереп картер ачу, вал салдыруларның кыенлыкларын әле дә онытмый Миңзифа апа.

– Берсендә Тупач янындагы басуда тракторым ватылды. Җир өстендә калмасын инде дип, юл кырыена чыгарып куйдым да, якындагы авылга кайтып, берәүләрнең ишеген шакыдым. Өс-баш каешланып каткан – чәчү чорында аның кайгысымыни?! Мазуты да чәчри, трактор астына кереп тә рәтләргә туры килә... Ул заманда кешеләр шәфкатьле булган икән дим, шул пычрак киемнәрем белән өйләренә кунарга керттеләр. Идәннәренә генә яттым. Озакламый бригадир килгән: «Ни булды, ник туктадың?» – ди. Һәр сәгать исәптә чак, тракторны туктатырга ярамый. «Клапан төшеп калган», – дим. Икенче көнне тиз генә Минзәләдән запас деталь кайтарттылар.

Алмашка кеше булса, беребез – көндез, икенчебез төнлә эшли. Алыштыручы кеше булмаса, үзеңә генә эшлисе. Басу каравылчысы вагонына төнлә генә кайтып авасың. Тракторның ялгызын калдырырга ярамый – күрше-тирә авыллардан килеп, берәр детален салдырып алулары бар. Күзеңне йомсаң да, колагың сак булырга тиеш. Төнлә түзеп була әле, таң атканда йокы килүгә чыдар әмәл юк. Берсендә зират буендагы басуда җир сукалыйбыз. Таң алдыннан руль артында килеш йокыга кителгән. Уянып китсәм, трактор зират эченә кереп, сунгән. Әле ярый эчкә кермәгән, каберләр өстенә менмәгән дип куануым...

Бераз ХТЗ тракторында эшләгәннән соң, Миңзифаны Чаллыга газогенератор тракторына укырга җибәрәләр. Утын шакмаклары – чүрәкәй ягып эшли торган әлеге тракторда Миңзифа – рульдә, дус кызы Нәҗибә генераторга чүрәкәй салып бара... Әнә шулай, 1940 елдан 1945 елга кадәр тракторда эшли Миңзифа Миңнәхмәт кызы.

Сугыш беткән дигән шатлыклы хәбәрне дә басуда – тракторында ишетә ул. Аның көткән кешесе – 1941 елда армиягә озатып калган Шакирҗаны бер кулын сугышта калдырып, яраланып, 1944 елда кайткан була инде. 1945 елда өйләнешәләр. Әмма бәхетләре генә гомерлек булмый...

Лилия ГӘРӘЕВА

Фотода Миңзифа апа (*уңда*) Тукай районыннан килгән кунагы Гөлчирә Зыятдинова белән.



PRESSA



МӘҢГЕЛЕК КОЯШ ИЛЕ



Алинә ГОБӘЙДУЛЛИНА

Италияне барып күрү теләге күңелемдә күптән йөри иде инде. Бу ил миңа ниндидер романтикага уратылган кебек тоела, аш-суының байлыгы, архитектурасының төрлелеге белән җәлеп итә. Италиядә күрергә, карарга теләгән урыннар шундый күп! Шуңа күрә уйлаштык та, иң яхшысы тур алу дигән нәтиҗәгә килдек. Һәм, минемчә, ялгышмадык.

Италия шәһәрләре арасында Флоренция иң кыйммәтлесе дип санала.

Беренче көн. Сан-Марино

Самолетыбыз Римини аэропортына төшеп утырды. Италия безне колач җәеп каршылый: урамда 26 градус җылы, һавада ник бер болыт әсәре булсын! Атна буена бергә сәяхәт итәсе группабыз белән танышабыз да шундук юлга кузгалабыз. Безне Сан-Марино көтә!

Монте-Титано тавына урнашкан кечкенә генә дәүләт ул Сан-Марино. Италия эчендә урнашса да, бәйсез республика дип игълан ителгән. Мәйданы нибары 60 квадрат километр, халкы да 30 меңнән артмый. Бик кечкенә бу дәүләткә 301 елда ук нигез салынган дип саныйлар. Риваятьләр буенча, әлеге тауга иң элек беренче христиан оешмасы әгъзасы булган Марин дигән егет нәкъ шул елда күтәрелә. Үзен эзәрлекләүче мәҗүсиләрдән шушында качып кына котыла ул. Таш шомартучы була – тауда таш чыгара башлый. Тормыш ыгы-зыгысыннан качар өчен иң югарыда үзенә кечкенә генә хөҗрә төзи. Әмма тирә-юньдә яшәүчеләр аның турында каяндыр белеп алалар, һәм табынучылар тауга агыла башлый. Озакламый монастырь төзеп куялар. Марин вафат булганнан соң, тауда калыккан шәһәрне дә аның исеме белән атыйлар.

Бүгенге шәһәр инде тау итәгендә үк башлана. Аста, үзәнлектә гел заманча йортлар гына булса, өскә күтәрелгән саен узган гасырларда ук төзелгән өйләр күзгә чалына.

Кызганыч, мондагы матурлыкның барысын да туйганчы күреп булмады. Әмма тау түбәсенә күтәрелергә өлгердем! Сан-Маринонын бөтен тарихы ирек һәм бәйсезлек өчен көрәш белән сугарылган. Дәүләтнең эчке һәм тышкы сәясәтенең девизы бер үк – Libertas (ирек). Кошлар очар биеклектә – Монте-Титано тавы түбәсендә басып торганда ирек хисенең мәгънәсен бөтен барлыгың белән тоясың. Анда миңа да юлымда бернинди киртәләр, проблемалар юк кебек тоелды. Күңелеңә энергия мөлдерәмә булып тула: менә-менә очып китәрсең төсле... Юлыгыз Сан-Маринога алып барса, һичшиксез, аның иң биек ноктасына күтәрелергә тырышыгыз.

Адым саен нинди дә булса һәйкәл яки скульптура очрый. Бигрәк тә икесе истә калды. Берсе – тавышсыз кычкырган килеш катып калган бала: Беслан теракты вакытында һәлак булган балаларга куелган һәйкәл. Икенчесе – баласын күтәреп чабучы Ана. Монысы – 1944 елда бомбага тотылганда һәлак булучылар истәлегенә калыккан.

Бу республика НДСның нәрсә икәнен белми, шуңа күрә, Европа белән чагыштырганда, анда шактый әйберләрнең бәясе арзанрак. Шопинг яратучылар өчен оҗмах инде...

Яраттым бу дәүләтне! Гаҗәеп бер ил – азатлыкның кечкенә генә бер утравы. Аның бөтен рухын тояр өчен биредә озаккарак тукталырга кирәк шул... Үз-үземә вәгъдә бирдем – мин монда барыбер тагын бер киләм әле!

Икенче көн. Ассизи

Ассизи шәһәре – Италиянең Умбрия төбәгендә урнашкан. Католикларның табыну үзәге бу, популярлыгы ягыннан Ватиканнан калышмый. Изгеләр дип саналучы Франциск Ассизский һәм Клара Ассизская дини эшчәнлекләрен шушы шәһәрдә башлаган.

Ассизи шәһәрендә сине бөтенләй башка халәт биләп ала: җаныңа тынычлык иңә. Бу каланың энергетикасы үзгә: әйтерсең ул сине балачактагыдай йомшак җылы юрганга төреп әкрен генә тибрәтә... Кайсы якка карасаң да – гыйбадәтханәләр һәм монастырьлар. Алар шундый күп! Беркем дә беркая да ашыкмый: гомумән, монда яшәүчеләргә беркая да барырга кирәкми кебек тоела.

Бер кызык нәрсәгә игътибар иттем: шәһәрнең үзәгенә алып баручы юлга түшәлгән ташларга исемнәр язылган. Ассизиның казнасын баету өчен 40 евро акча күчерүчеләрнең исемнәре икән бу. Аларга рәхмәт йөзеннән исемнәрен шулай мәңгеләштергәннәр.

Икенче, өченче, дүртенче көннәр. Рим. Ватикан

«Дөньяда төп нөсхәләрдән бары тик Рим гына бар, калганы һәммәсе – копия (ягъни күчермә)». Италия башкаласы халкы шулай дип саный. Мин алар белән тулысынча килешәм! Монда һәр урамга, урамнардагы һәр сукмакка, ул сукмакларга җәелгән һәр ташка тарих сеңгән.

Уйласаң да шаккатасың: моннан берничә мең еллар элек үк Римда инде бүгенге заманчаларын хәтерләткән сууткәргечләр булган; бүгенгеләргә бик тә охшаган банклары, сәүдә үзәкләре эшләп торган; медицина алга киткән... Шәһәрдәге тарихи һәйкәлләр турында исә көннәр буе сөйләп торып буладыр. Колизей, Пантеон, Капитолий, Рим форумы, Изге фәрештә замогы (аны импера-


■ Ассизида булган һәркем рухланып, яңа көч туплап китә, диләр. Кабат мин дә барыр идем. Томанга сарган шәһәргә өстән бер күз салырга, кояшның беренче нурларында ялтырап күренгән ташларга сокланырга...



Фото: www.pixabay.com

Диңгез продуктлары белән иң тәмле пастаны Сан-Маринода ашадым.





■ Ватикан – Рим шәһәре эчендә урнашкан кечкенә генә дәүләт. Әмма чып-чын дәүләт! Гомуми мәйданы нибары 44 квадрат километр, ә үзенең армиясе дә бар, акчасы да, жандармериясе дә. Һәм хәтта үз матбугат органнары да!

тор Адриан мавзолее дип тә атыйлар), Испан мәйданы, шул ук исемдәге баскыч, Тибр елгасы яр буе... Римга баргач һичшиксез күрергә, карарга өлгерергә тиешле урыннарның иң кыска исемлеге әле бу.

Мин үзем барысына караганда да күбрәк Треви фонтанына гашыйк булдым. Римдагы иң зур һәм иң билгеле фонтан – шушы. Ул өч урам чатында урнашкан, исеме дә турыдан-туры шуның белән бәйле: «Тре Виа» итальянчадан «өч урам» дип тәрҗемә ителә. Фонтанның үзәк фигурасы – Нептун, аның бер ягында – Муллык алиһәсе сыны (кулындагы савыттан кыз күп итеп су агыза. Безнең эрага кадәр I гасырлар). Рим шәһәре үсә, зурая башлагач, аны су белән тәэмин итү мәсьәләсе килеп туа. Ул чакта идарә итүче император Август үз кешеләрен су чыганаклары эзләргә чыгарып җибәрә. Арып-талып, берни тапмый кире шәһәргә кайтканда, легионерлар юлына шушы кыз очрый, һәм ул аларга чишмә урынын күрсәтә. Озакламый акведук төзиләр: әлеге чишмәдән Рим халкына эчәргә су килә башлый). Нептунның икенче ягында Сәламәтлек алиһәсе сыны: аның кулында еланнар уралган куб. Треви фонтанындагы суга вак акчалар ташласаң, имеш, бөтен теләкләрең дә чынга аша. Берне ташласаң – Римны, һичшиксез, тагын бер килеп күрәсең, икене ташласаң – мәхәббәтеңне очратасың, өчне ташласаң – бәхетле гаилә төзисең. Туксанынчы елларда, фонтанга реставрация ясаганнан соң, шәһәр хакимияте суга акча ташлау гадәтен туктаткан. Әмма үз карарларыннан бик тиз баш та тартканнар: туристлар ел дәвамында фонтан суында 1 400 000 евро акча калдыралар икән! (Римның Милли музее да елына 1,1 миллион евро гына эшли ди). Кызыгып, Треви суыннан берәр евро алыйм дип, ялгыш та үрелә күрмәгез: бу акчалар инде шәһәр хакимияте милке дип санала. Караклыкта гаеплән, 500 евро штраф салырга бик мөмкиннәр!

Ватикан

Мине Ватиканда, беләсезме, нәрсә шаккаттырды? Сикстин капелласы! Аның иң күзгә ташлана торган урыны, әлбәттә, 1115 квадрат метрлы түшәме. Бу түшәмне Микеланджело үзе ясаган! Скульптор әлеге эшкә дүрт ел гомерен багышлый. Бизәү эшләре ахырына якынлашканда, аның буыннары ялкынсына: аркасы авыртканлыктан, ул инде яткан килеш кенә эшли ала. Кемдер моны матур бер әкият кенә ди, икенчеләре, чынлап та, шулай булган дип ышандыра. Ничек кенә булса да, Сикстин капелласы сәнгать шедеври дип санала. Ел саен аны күрергә дип Ватиканга 4 миллион турист килә.

Бишенче көн. Сиена

Шәһәрнең үзенчәлеге шунда, ул районнарга, ягъни контрадаларга бүленгән. Нәкъ урта гасырлардагыча! Сиенада алар барлыгы – унҗиде. Шәһәр эчендә шәһәр! Һәр контраданың үз исеме бар: «Әкәм-төкәм», «Ташбака», «Ана бүре», «Дулкын», «Урман»... Алай гына түгел, һәрберсенең үз резиденциясе, үз чиркәве, фонтаны, девизы, гербы, музее... Дус һәм дошман контрадасы! Сиенада иң яхшы контрада кайсы икәне ел саен ат чабышлары вакытында ачыклана. Ул «Палио» дип атала һәм елга ике тапкыр – 2 июльдә һәм 16 августта уза. Иярләмәгән атка утырган җайдаклар 333 метр озынлыктагы үзәк мәйданны өч тапкыр әйләнергә тиеш. Нибары 90 секунд эчендә барысы да хәл ителә. Текә борылышларда җайдаклар очып төшеп калып, атның берүзе генә финишка барып җиткән чаклары да байтак, диләр. Чынлыкта, Палиода кайсы контраданың аты беренче килә, шул район җиңүче санала. Атланып килеп җитә алган очракта, җайдакны акчалата бүләклиләр, ә ат



■ Сиена – Тоскана төбәгендәге шәһәр. Урта гасырларга караган иң матур калаларның берседер ул. Анда хәтта бүген дә тарихи рух саклана. Риваятьләр буенча, аңа Ремның игезәк уллары Сений белән Аский нигез салган. Әтиләрен үтергән абыйларының үченнән куркып, алар бирегә – Тоскана калкулыгына качалар. Бүген без күргән шәһәр шул урында төзелгән.



өстенә сабыен күтәргән Мадонна сурәте төшерелгән ефәк әләм каплыйлар. Чабышлар тәмамлангач, һәр контрада, тар урамнарга озын-озын өстәлләр куеп, табын кора һәм төне буе бәйрәм итә. Бу бәйрәмнең зурлыгын тою һәм анда җиңүнең әһәмиятен аңлау өчен Сиенада туарга кирәк, диләр... Туу дигәннән. Төрле контрадага караучы яшьләр арасында никахлар, әлбәттә, булып тора. Шунысы кызык: гаиләдә кыз бала туса – ул әнисе, ә ир малай туса, әтисе контрадасыныкы дип санала.

Алтынчы көн. Флоренция

Тоскана башкаласына аяк басуга мәктәп, тарих дәреслеге искә төшә: «Монысын үттек...», «Монысын сөйләделәр...», «Монысын...»... Монда Галилей үзенең ачышларын ясаган, Алигьери, Микеланджело һәм Леонардо да Винчи иҗат иткән. Нәкъ менә Флоренциядә Достоевский «Идиот» романын тәмамлый, ә Чайковский «Пиковая дама» операсына нокта куя. Иң чиста итальян теленең Ватаны да әле ул Флоренция.

Аш-сулары хакында әйтеп үтмәсәм, итальяннар мине кичермәс: Флоренция кухнясы үзенең затлылыгы белән аерылып тора. Анда булганда менә нәрсәләрне авыз итәргә кирәк... Хәер, милли ашсуларның кайсына тукталырга икәнен үзегез хәл итәрсез, ә менә ипиләрен ашап карамыйча кайтырга ярамый. Тоскана ипие бит ул! Шулкадәр тәмле – аны бернәрсәсез, үзен генә ашарга да мөмкин. Төп үзенчәлеге, мөгаен, аңа тозның бөтенләй салынмавыдыр. Риваятьләрне тыңласаң, «тоз сугышы» аркасында шулай тозсыз пешерә башлаганнар бу ипине: Пиза халкы кайчандыр Флоренциягә тоз китерә торган юлларны япкан булган. Ә кемдер: «Башка ризыкларның тәме яхшырак сизелсен өчен тоз кушмыйлар бу ипигә», – ди.

Җиденче көн. Венеция

Бу сәяхәтнең иң әкияти өлеше Венеция булгандыр. Ниндидер могҗизалы төш! Су эчендәге кала. Европаның иң романтик почмагы. Җир шарындагы иң матур шәһәрләрнең берсе... Ничәмә-ничә буын рәссамны, шагыйрьләрне, артистларны рухландырган ул. Бер көн эчендә генә бөтен матурлыгын күрергә, тоярга мөмкинмени аның?! Сан-Марко мәйданын туйганчы карарга да җитми бит ул бер тәүлек! Баскычларга утыр да, көне буе шушы мәйданны күзәт икән ул: кояшның җылы рәхәт нурларын той, күгәрченнәр ашат яки, киресенчә, аларны үз яныңнан ку. Алар монда шундый әрсезләр – үзләрен Сан-Марконың чын хуҗалары итеп тоялар.

Иң беренче чиратта нәрсәләрне карарга? Юк, санап чыга алмам! Туристның вакыты санаулы, димәк, кайсына өлгерәсез – шуны!

Каналлар буенча йөзүне кичке якка калдырсаң әйбәтрәк: кояш баеганда шәфәкъ нурлары астында йортлар тагын да матуррак күренә. Каналлар буйлап йөрүче өч төрле транспорт бар монда. Беренчесе – су трамвайлары, Венециядә аларны «вапоретто» дип атыйлар. Икенчесе – су таксилары: бәясе кыйммәтрәк, әмма туристлар шыплап тулган трамвай түгел инде бу, хәрәкәт итүе дә тизрәк. Өченчесе, әлбәттә, гондола. Аны билгеле бер сәгатькә генә алып була, бәясе дә тәүлекнең кайсы вакытын сайлавыгызга карап үзгәрә. Әмма анда алган тәэсирләр инде бөтенләй башкача. Әкияттәгечә!

Италия турында күп сөйләп булыр иде. Мин күргән бу шәһәрләрнең һәркайсы аерым язмага лаек. Һәм аларны һәркем үзенчә ачадыр... Бу ил күңелемне әле һаман да үзенә тартып тора. Анда – матурлык, мәхәббәт, анда – мәңгелек кояш!



Тулысынча сайтыбызда: www.syuyumbike.ru »

«БАРЫСЫ ДА ИР-АТ КУЛЫНДА...»



Динар ШАКИРОВ,
Дүртөйле шәһәре прокуроры, Башкортстан;
гаилә стажы – 17 ел;
өч бала атасы.

**Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.**

1 Иң элек хатын-кызның сез нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Әгәр миңа бу сорауны 15–20 ел элек бирсәләр, җавап, әлбәттә, башкачарак яңгырар иде. *(Елмая.)* Әмма яшең 40 тан узгач, хатын-кызга инде башкачарак карыйсың. Кайчак иң кыйммәтле бутикта киенгән, бар җире ялт иткән хатын-кыз очрый – бер кашык су белән йотарлык! Тик андагы тәкәбберлек, мин-минлек шунда ук теләсә кайсы ир-атның гайрәтен чигерә: аралаша башлап биш минут узуга, аның ягына инде күз дә саласың килми. Ә икенчесе гади генә киенгән, бизәнүе дә табигый генә, күзләрендә – нур! Ә елмаюы! Күңеленең матурлыгы, тормышка мәхәббәте, җанындагы гармония – һәммәсе күренә. Ни дисәң дә, хатын-кызның тышкы матурлыгына караганда рухи дөньясы, җанының матурлыгы үзенә күбрәк тарта.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Игътибарсызлыгын, сәгатьләр буе кибеттә йөрергә яратуын, көнләшүен, хәтерсезлеген, кайбер нәрсәләрне йөрәгенә артык якын алуын... Дөрес, боларның берсе дә минем җәмәгатемә кагылмый. Аның мине үзгәртергә тырышуы гына ике арада киеренкелек тудыра кайчак. «Ә безнең әти менә шулай эшли иде...» – дигән җөмләне 17 ел эчендә бер генә ишетергә туры килмәде. Бабай шәп кеше минем – сүз дә юк, андыйлар миңа бер генә очрыйдыр. Ә мин... мин башка. Башка гаиләдә, башка тәрбия алып үскәнмен. Мине кем беләндер чагыштыру, алай гына да түгел, үзгәртергә тырышу, әлбәттә, ошап бетми. Ир-атларның күбесенә таныш күренештер бу... Әмма хатынымның бу гадәтенә күз йомарга була дип саныйм. Йомам да! Әтисен ничек мактаса да, артык түгел икәнен белгәнгә – бигрәк тә.

3 Ә нәрсә өчен сез бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Җавап бер генә бу очракта: хыянәтне һәм үземне кимсетүне. Мин табигатем белән горур ир-ат. Өстәвенә, ир-атларның күбесе кебек, үземнекен берәү белән дә бүлешергә дә теләмим. Мондый хәлгә калам икән, никадәр авыр булса да, шунда ук барысын да өзеп, тормышымның бу битен бөтенләйгә ябачакмын гына... Бу исемлеккә тагын хатын-кызның шапшаклыгын, әдәпсезлеген дә өстәр идем. Әлеге сыйфатлар, шунда ук булмаса да, торып-торып теләсә кайсы ир-атны чыгырыннан чыгара аладыр.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– «Һәр бөек ир-ат артында аны яраткан һәм рухландырган хатын-кыз тора», дигән гыйбарә бар. Икенең берсен сайла дисәгез, мин беренчесенә тукталыр идем – анысы күңелемә якынрак. Идеаль очраклар – бу сыйфатларның икесенә дә ия булган хатын-кызлар да бар, билгеле. Гүзәл затларның көчлеләре генә моңа ирешә аладыр. Тик бөтен ир-атка мондый бәхет тәтеми генә...

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Оскар Уайльд: «Ир-ат белән хатын-кыз арасында дуслык булуы мөмкин түгел, алар арасында гыйшык, дәрт, мәхәббәт, нәфрәт кенә була ала», – дисә дә, мин үзем башка фикердә. Ир белән хатын арасында гына түгел, гомумән, ир-ат белән хатын-кыз арасында дуслык, хәтта чын дуслык була ала дип саныйм. Студент чактан ук аралашкан андый якын дусларым бар. Ирләренә әйтергә җөрьәт итмәгән кайбер сораулар белән мөрәҗәгать иткән, киңәш сораган, серләрен уртаклашкан чаклары булгалый.

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

– Хатынымның әнисе Татарстанның Кукмара районында, Өлге авылында туып-үскән. Фәридә дә шунда дөньяга килгән. Без аның белән 2001 елның октябрендә Башкортстанның Чакмагыш районында таныштык. Ул анда әтиәнисе белән яши иде, ә мин район прокуроры ярдәмчесе булып эшкә урнаштым. Кичләрен эштән кайтканда аны юлда бик еш очрата идем. Фәридә дә улы белән эштән кайта, баласына ул чакта 6 яшь иде. Чибәр, зифа буйлы бу кыз миңа бер күрүдә ошады, әмма аның белән танышуга бик озак кыюлыгым җитмәде әле. Аралаша башлаганнан

соң – бер елдан никахыбыз булды. Кияүдән кайткан хатын, бераз миннән өлкәнрәк тә, кулында бала... Шуңа күрә әтиәнием башта аңа өйләнергә теләвем белән бигүк риза түгелләр иде, тик соңыннан аңладылар һәм бу карарымны кабул иттеләр. Ул көннән соң инде 17 ел вакыт узды. Тагын ике улыбыз туды – безнең өч улыбыз бар. Олы улыбыз инде Казан федераль университетын тәмамлады, уртанчысы 9 нчы сыйныфта укый, кечкенәсе әле балалар бакчасына гына йөри. Мине шәһәр прокуроры итеп билгеләделәр, соңгы ун елда Дүртөйле шәһәрендә яшибез.

Ничек тәкъдим ясаганымны, әлбәттә, хәтерлим. Никахыбызга кадәр берничә ай алдан булды ул. Фәридә миңа кунакка килгән иде. Алдына тезләндем дә, Америка фильмнарындагы кебек кабатладым: «Миңа кияүгә чык! Бер-беребезне шатлыкта да, кайгыда да, барлыкта да, юклыкта да, авырганда да, сау-сәламәт чакта да яратырбыз. Үлем безне бер-беребездән аерган көнгә кадәр!» – дидем. Ул: «Мин риза!» – дип җавап бирде.

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Әйтүен әйтәләр, әмма соңгы карарны без барыбер йөрәк белән сайлыйбыз дип беләм. Минем үземнең хатыным әнигә бөтенләй охшамаган. Әмма уртак телне алар бик тиз таптылар. Бу очракта күп нәрсә ир-атка бәйле: әниеңне булачак хатыныңны ничек кабул итәргә син әзерлисең. Әйе, барысы да синең кулда...

8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Минемчә, мондый ир-ат алдында ике генә юл бар: йә ул бу хәл белән килешә һәм хуҗалык эшләренең зур өлешен, балалар тәрбияләүне үз өстенә ала; йә ничек итсә итә, әмма югарырак хезмәт хаклы эшкә урнаша. Гаиләне җигелеп тартучы кеше ир-ат булырга тиеш – беренче көннән үземне бары тик шушы рольдә генә күрдем. Бүген дә шул фикердә калам. Улларымны да шулай тәрбияләргә тырышам. Тик бүгенге җәмгыять тәэсиреннән аларны аралап бетерү генә авыррак. Олысы, әнә, ирләр белән хатын-кызлар хәзер бертигез, гаиләнең матди ягын да алар бүлешеп күтәрергә тиеш дип саный. Кыз белән егет кафега кереп утыра икән, һәркем үзе өчен үзе түләсен ди. Мин бу фикер белән риза түгел. Улым да барыбер яши-яши минем кебек уйлый башлар дип өметләнәм.

9 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Без, ир-атлар, читтән бик кыю булып күренсәк тә, гашыйк булган хатын-кызыбыз алдында югалып кала, кыюсызга әйләнә торган гадәтебез бар. Бигрәк тә яшь чакта. Әгәр ул шул вакытта колагыңа: «Миңа сезнең күзләрегез бик ошый. Аларга карагач яшисе килә», – дип пышылдап кына әйтеп китә икән, дөнья күз алдында үзгәрә: аның янәшәсендә булу өчен син инде таулар күчерергә әзерсең!

10 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Өлешчә килешәм. Кызганыч, тик чибәр һәм көчле хатын-кызлар күп вакыт тәкәббер, горур, һавалы була. Ир-атны да беренче чиратта шушы сыйфатлар өркетә. Әмма соңгы вакыт хатын-кызларның көчле булуында, күп нәрсәне үз иңнәренә алуында ирләр үзләре гаепледер: вагайдылар. Әллә хатын-кыз иренең кочагына сыенган килеш, аның: «Барысы да әйбәт булыр, кадерлем. Бөтен нәрсәне дә хәл итәрмен, ә син мине, балаларыбызны гына ярат!» – диюен ишетергә теләмиме?!

11 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатынызгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный...

– Минемчә, ир белән хатын бер-берсенә юл куярга тиеш, юкса гаилә көймәсе бик тиз комга терәләчәк. Бер очрак искә төште әле. Никахтан соң әллә икенче, әллә өченче көн иде. Носкиемны салдым да хатынга суздым: «Юып куй!» Ирлегемне күрсәтүем иде инде бу минем... Ә ул: «Юк, юмыйм!» – диде. Бер-беребезгә ул чакта нинди сүзләр әйтүебез истә калмаган, әмма тавыш шактый зур булды. Мин хәтта ишекне каты ябып чыгып китәргә, әле башланмаган да гаилә тормышыбызга нокта куярга да әзер идем ул чакта. Әмма җаваплылык хисе, әти-әни биргән тәрбия бу адымнан саклады: носкиларны үзем юып куйдым.

12 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән.

– Без һәрвакыт төшке ашны да, кичке ашны да өйдә ашыйбыз. Хатынымның сез әйткәнчә диванда ятып каршы алган чагын хәтерләмим. Теге яки бу сәбәп белән ашарга әзерләргә өлгермәгән очраклар була, билгеле. Әмма мин моны, гадәттә, кичтән үк беләм һәм иртәгәсен, юл өстендә тукталып, йә әзер пилмән, йә пешкән тавык алып чыгам. Кафега кереп тә ашый алам анысы, әмма Фәридә моны аңлап бетермәс, хәтта үпкәләр иде дип уйлыйм. Ә үзем җитдирәк берәр нәрсә пешерергә тәки өйрәнә алмадым. Мультиваркада ботка пешерә беләм дә, йомырка кыздыра алам – шул гына.

13 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

– Әйе, дөрес бу. Мин үземне бүләккә талымсыз дип әйтә алмыйм. Булды инде, эчке кием, оекбаш, чалбар кебек бүләкләр алган чаклар да... Андый бүләкләр истә дә калмый: аласың да, онытасың. Шундый хәл килеп чыкмасын өчен, нәрсә теләгәнемне йә читләтеп булса да алдан әйтеп куярга тырышам, йә икәү бергә чыгып сайлыйбыз.
Иң ошаткан бүләгем исә – алтын чылбыр. Фәридә аны 35 яшем тулган көнгә бүләк итте. Ир-атларның муенга калын алтын чылбыр тагып йөрүен бер дә яратмыйм, шуңа күрә ак алтыннан алырга ризалаттым: күзгә дә артык бәрелеп тормый, матур да, затлы да. Менә җиде ел инде бер салмыйча киям. Хәтта мунчада да салганым юк.

Кайбер гаиләләрдә шундый гадәт бар икән: ир белән хатын ике тартма куялар да, бүләккә нәрсә алырга теләгәннәрен аерым кәгазьгә язып, ел буе шунда салып баралар икән. Ә бәйрәм җиткәч, тартмадан берәр кәгазьне тартып кына чыгаралар: кирәкле әйбер дә була, үзенә күрә бер сюрприз да. Әллә безгә дә өйдә шундый шкатулкалар булдырыргамы икән дип уйлап торам әле.



Балалар бәрелми-сугылмый гына үсми. «Балаң булса – ут булсын, ут булмаса, юк булсын» дигән бит элеккеләр дә. Бәләкәй бөтерчекне күз уңыннан ычкындырмаска тырышсаң да, мизгел эчендә каядыр барып бәрелергә, егылып төшәргә мөмкин ул. Күп очракларда әнисенең бер «өф» итүе белән сызлавы бетеп тә китә. Кайчак исә хәлләр җитдирәк: башы белән бәрелгәннән соң бала агарына, хәлсезләнә... Бу исә аның баш мие селкенү ихтималына ишарә. Республика балалар клиник хастаханәсенең нейрохирургия бүлеге мөдире, табиб-нейрохирург Владимир ИВАНОВ белән шул хакта сөйләшәбез.

БАЛА БАРДА ХӘТӘР БАР

Баш сөягенә һәм баш миенә зыян килмәсә, ми селкенү җиңелчә травмалардан санала. Балаларда шактый еш очрый ул. Сәбәбе билгеле инде: уйнаганда яки спорт белән шөгыльләнгәндә егылу, башны бәрү. Бәләкәй балаларда ул күбрәк биеклектән егылып төшү белән бәйле булса, мәктәп яшендәгеләр травмаларны ешрак спорт белән шөгыльләнгәндә ала (хоккей, футбол, бокс, көрәш...). Соңгы вакытта юл һәлакәте аркасында баш мие белән бәйле травма алучылар да шактый.

Кагыйдә буларак, баш мие селкенгәннән соң барлыкка килгән билгеләр вакытлыча гына, бер-ике көннән алар узарга тиеш. Баш авырту, күңел болгану, баш әйләнүләр озаграк дәвам итсә, баланың организмына тагын да җентекле тикшерү уздыру таләп ителә. Иң мөһиме: травма алган баланың сәламәтлегендәге җитди проблемаларны күрми калдырмау.

Әлеге травма җиңелчә генә булган очракта сәламәтлеккә куркыныч янамаса да, баш мие селкенгән бала берничә ел табиб-невропатолог күзәтүе астында булырга тиеш.

Нәтиҗәсе нинди булырга мөмкин

Җиңелчә генә баш мие селкенү баш миендә ниндидер куркыныч үзгәрешләргә китерә дип әйтеп булмый. Шулай да кайчак түбәндәгеләр күзәтелергә мөмкин:

- ярсучанлык;
- артык хисселек;
- баш авырту;
- һава торышына бәйлелек;
- йокысызлык;
- игътибарсызлык;
- таркаулык;
- уку программасын авыр үзләштерү һәм башкалар.



Беренче ярдәм







- травма алган көнне үк табибка күрсәтергә, ә иң яхшысы: ашыгыч ярдәм чакыртырга. Табиб караганнан соң гына төгәл диагноз куела. Травманың дәрәҗәсен ачыклау өчен рентгенография, НСГ, РКТ билгеләнә;
- урынга яткырырга (йокысы килсә, йоклатырга мөмкин);
- укшытса, башын кырын салырга;
- бәрелгән урынга салкын әйбер куярга;
- пульсын, кан басымын тикшерергә;
- ярасы булса, зарарсызландырырга;
- үзбелдекләнеп авыртуны, укшуны басучы дарулар бирмәскә.

Фото: www.pixabay.com

Баш мие селкенүнең билгеләре

- травмадан соң баланың йөзе агара;
- бик аз гына вакытка һушын югалта (сез аны сизми дә калырга мөмкинсез);
- баш авырта;
- баш әйләнә;
- күңел болгана, укшыта;
- хәлсезлек;
- пульс үзгәрә;
- кан басымы төшә;
- баланың реакциясе акрыная.

Ничек дәваларга

- Травма алган баланы стационар шартларында дәвалау отышлырак;
- беренче көннәрдә баланы урында гына яткырырга;
- урыннан торгач та артык күп хәрәкәтләнергә ирек бирмәскә;
- эмоциональ киеренкелектән сакларга;
- ярты елга кадәр физик нагрузкалардан азат итәргә;
- баш авыртулары күзәтелсә, табиб кушуы белән авыртуны баса торган дарулар бирергә.



Материал ДРКБның матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.



Ростов медицина институтының топографик анатомия һәм оператив хирургия мөдире А. Голубев әлеге әгъза турында болай дип яза: «Иркәләнүче пантера кебек, башын уникеилле эчәккә салган, нәзек гәүдәсе аортада ята, ә чак кына бөгелгән койрыгы талакка таба сузылган. Берәр чир килеп чыкса, кинәт кенә һөҗүмгә ташланып, төзәтеп булмаслык зыян салачак». Аңлавыгызча, бүген сүзебез ашказаны асты бизенең ялкынсынуы турында булыр. Әлеге чир хакында безгә Россиянең һәм Татарстанның атказанган табибы, медицина фәннәре докторы, КДМАның ашыгыч медицина ярдәме кафедрасы мөдире, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш хирургы һәм трансплантологы, профессор Андрей АНИСИМОВ сөйли.

«ЙОКЛАГАН ПАНТЕРА»НЫ УЯТМАГЫЗ!

Панкреатит – ашказаны асты бизенең ялкынсынуы. Бу биз – ферментлар һәм гормоннар җитештерүче уникаль «фабрика» – кешенең гомере өчен иң мөһим органнарның берсе. Ул ике «фронт»ка эшли. Тышкы «фронт» – ашкайнату. Эчке фронт – махсус күзәнәкләрнең инсулин һәм башка төр специфик гормоннар җитештерүе. Әлеге орган эшчәнлегендәге теләсә нинди чатаклык организмның тулаем сафтан чыгуына китерә ала, чөнки бу биз – билгеле бер шартларда үз-үзен эшкәртергә сәләтле. Монысы исә кеше гомеренә куркыныч янаучы халәт.

Ашказаны асты бизе ялкынсыну кискен һәм дәвамлы була. Ялкынсыну процессы бер-ике көн эчендә кинәт башланса, бу – панкреатитның кискен төре. Узган гасыр башында кискен панкреатит сирәк очраса, хәзер ул кайбер илләрдә, кискен аппендицит кебек үк, бик еш очрый. Авыручыларның уртача яше элек 50 булса, хәзер – 40 яшь.

Панкреатитның сәбәпләре:

- исерткеч эчемлекләр белән мавыгу;
- майлы һәм ачы ризыкларга өстенлек бирү;
- үт куыгында ташлар булу (аеруча хатын-кызларда еш очрый);
- инфекцияләр;
- эчәклектә тумыштан булган җитешсезлек;
- агулану;
- артык авырлык;
- нәселдәнлек;
- стресс (стресс тамырларның һәм биз юллары мускулларының спазмын барлыкка китерә);
- аскаридалар (алар ашказаны асты бизенең каналларына бөялергә мөмкин);
- көчле травмалар да кискен панкреатит башлануга сәбәпче була ала;
- күптән түгел тагын бер сәбәп ачыкланды: үзбелдегең белән гормональ дарулар һәм башка төрле препаратлар куллану.

Ничек сакланырга

- гәүдә авырлыгының индексын 25 тән арттырмаска;
- көненә берөзлексез кимендә 30–40 минут хәрәкәтләнергә;
- иртәнге, көндезге, кичке ашларны калдырмаска, алар арасында тагын җиңелчә генә капкалап алырга;
- майлы ризыклар һәм исерткеч эчемлекләрдән тыелырга.

Кискен панкреатитны ничек белергә

- авырту кинәт башлана һәм бик каты була;
- эчнең өске ягын чолгап авырта;
- авырту гәүдәнең сул ягына «бирергә» мөмкин;
- тыелгысыз укшу һәм косу башлана. Әмма косканнан соң да җиңеллек килми.

Журналыбызның киләсе саннарында исә панкреатитның дәвамлы формасы турында сөйләшербез.



Дәва ысуллары

Кискен панкреатит вакытында кичекмәстән медицина ярдәме күрсәтелергә тиеш. Авырту узар дип көтәргә ярамый. Иң мөһим кагыйдә – тиз арада хастаханәгә бару. Бары тик стационар шартларда гына «уянган пантера»ны авызлыкларга мөмкин. Дәва чаралары – капельница, ач тору, ашказаны асты бизенә бозлы куык кую һәм тынычлык. Дәваламаган очракта ашказаны асты бизенең үз функцияләрен бөтенләй яки өлешчә югалтуы ихтимал. Бу исә кеше исән калса да, сәламәтлегенә бик зур зыян килә дигән сүз. Ашказаны асты бизе ялкынсынуының шикәр диабетына китерү куркынычы да бар.



Материал Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының матбугат хезмәте җитәкчесе Әлфия Хәсәнова ярдәме белән әзерләнде.

Яз ашыктыра

Апрель ае – бакча сезоны ачылу чоры. Җир кардан арыну белән бакчаларда кызу эш башлана.

Җимеш бакчасында эшләр

Агач-куакларның төпләрен йомшартып, азотлы, фосфорлы-калийлы һәм органик ашламалар кертеп өлгерергә кирәк. Бакчада кар сулары җыелып торса, канаулар казып, аларны агызабыз. Агач кәүсәләрен купкан кайрыдан, мүкләрдән чистартып, бакча сумаласы белән яраларын дәвалыйбыз, артык нык үсеп китеп, берберсенә комачаулаучы ботакларын кисәбез, көздән кәүсәләре агартылмаган булса, хәзер известь белән агартабыз.

Бер төптә 10–12 яшь ботак кына калдырып, карлыган куакларын да яңартабыз, картайганнарын төптән үк кисеп алабыз. Артык зур булып бүртеп торган бөреләрен өзеп юк итәбез, ул бөреләрнең эче тулы гөбле була. Апрель аенда карлыганны берьеллык яшь чыбыкчалардан үрчетергә мөмкин. Чыбыкчаны нәкъ бөре өстеннән кисеп алабыз һәм өске яктагы бөредән 1,5 см ара калдырып, 16–18 см итеп кыскартабыз. Йомшак, уңдырышлы җиргә авыш итеп утыртабыз. Туфрак өстеннән 1 бөре генә чыгып калсын. Көзен, тамырлангач, без аны 10 см гына калдырып кыскартырбыз да, тагын бер елдан үз урынына күчереп утыртырбыз.

Кура җиләгенең дә ботак очларын иң нык бөрегә кадәр кыскартып чыгабыз. Болай эшләсәң, уңышы мулрак була. Кура араларын сай гына йомшартабыз, азотлы ашлама белән тукландырабыз, төпләрен черемә белән мульчалибез.

Чия, слива, виноградны исә яз көне кисәргә ярамый, сагызы агудан куак корырга мөмкин.

Апрель – корткычларга каршы көрәш ае да ул. Иң беренче булып алмагачның чәчәген ашаучы бөҗәкләр уяна. Ул әле оча алмый, кәүсә буйлап кына үрмәли. Шуның өчен кәүсә тирәли җилемле путалар куеп чыгарга кирәк. Аны үзең ясарга да мөмкин. Катыргы кәгазьне тасмалап кисеп, «Гусеничный клей» сылагыз да, шуның белән кәүсәне уратып алыгыз. Бөреләр ачылганда агач-куаклар өстенә корткычларга каршы препаратлар сиптерелә.


Фото: www.pixabay.com

Гөлбакчаданиләр бар

Күпьеллык чәчәкләрнең өсләрен ачабыз, төпләрен йомшартабыз. Лаләләр эре булып чәчәк атсын өчен, аларга да азотлы ашлама кертәбез. Ә нәркисләр су ярата: җир өсте кипшерүгә, бер төпкә берәр чиләк җылымса су сибәбез. Розаларның ботак очлары корыган булса, исән урынга кадәр кыскартабыз һәм берникадәр вакытка тукылмаган материал



белән кояш күзеннән каплап торабыз – кышкы йокыдан тәмам уянырга, тамырларга көч алырга ирек бирәбез. Баздагы георгин бүлбеләрен җылыга чыгарып, өйдә туфракка утырта торабыз. Бүлбедәге күзләр күренә башлагач, бер ояда 2-3 тармак калдырып, бүлбеләрне бүләргә мөмкин. Георгин кырауларга нык бирешә, шуңа да утыртырга ашыкмый торыйк. Ай ахырында гладиолус суганчаларын да кабыгыннан чистартып, марганцовкалы суда зарарсызландырабыз һәм кояшлы, ышык урынга утыртабыз. Өйдәге гөлләребез дә туфрагын алмаштырып, зуррак чүлмәккә утыртуны көтә. Ул эшне дә апрель аенда башкару кулай.



Түтәлләр безне көтә

Беренче эш итеп көздән утыртып калдырган сарымсак белән суганны барлыйбыз. Өсләрен каплап калдырган булсагыз, аларны ачабыз – туфрак тизрәк җылынсын. Сак кына төпләрен йомшартып чыгабыз һәм беренче тапкыр азотлы ашлама (мочевина) кертәбез. Узган елгы запаслардан сарымсагыгыз калган булса, иртә язда аларын да утыртырга була. Көзгә алар бер төшле зур сарымсак булып җитешә. Җир кипшерүгә кишер белән суганны да утыртабыз. Орлык суган үстереп алу өчен, апрельдән үк җиргә суган орлыгы да чәчәргә кирәк, ул акрын тишелә, аңа дым күп кирәк. Укроп, петрушка, шпинат, яфраклы салат, кузгалак, борчак, редиска – салкынга чыдам, аларны да хәзер чәчәргә була. Апрельдә әле җитәрлек җылы юк, түтәлләрнең өстен тукылмаган материал белән каплыйбыз. Кояш карый торган ышык урынга башлы кәбестә, чәчәк кәбестә, брюссель кәбестәсе, астра, циния орлыклары чәчәбез. Кәбестә рассадасы өйдә начар үсә, өстен капласаң, түтәлдә аның өчен шартлар кулайрак. Борчалардан саклау чараларын да онытмыйбыз – үсемлекләргә су сипкәннән соң, өстән көл бөркибез.

Соңрак утыртыласы түтәлләргә горчица, тукранбаш (клевер), фацелияише сидератлар чәчә торабыз.

Теплицаны да җәйгә әзерләргә кирәк. Аның эчен-тышын юабыз. Юганда сода яки горчица кебек зыянсыз матдәләр генә кулланабыз. Чыршы яки нарат ылысы төнәтмәләре белән юучылар да бар. Туфракны зарарсызландыру өчен, «Фитоспорин» бөркибез. Ул зыянсыз биологик препарат, әмма андагы микроорганизмнар дымлы һәм җылы туфракта гына эшли. Кәбестә һәм чәчәк рассадаларын, редиска, шпинат, салат, аш тәмләткеч үләннәрне теплицага чәчеп тә үстереп алырга була.

Апрельдә орлык бәрәңгене җылы һәм якты урынга чыгарабыз – яшелләнә торсын, күзләр чыгарып өлгерсен. Моның өчен аңа бер ай вакыт кирәк.

ЙӨЗЕҢ НУРЛЫ БУЛСЫН!

Үзеңне ярату матурлыкка омтылудан башлана. Бигрәк тә яз күңелне әллә нишләтә! Тагын да гүзәлрәк, чибәррәк һәм яшьрәк күренәсе килә! Журналыбызның бу санында бит тиресен тәрбияләү серләре турында «Суфле» матурлык үзәге җитәкчесе Суфия ГАБДУЛЛИНА сөйли.



Еллар барыбер үзенекен итә дисәләр дә, һәрвакыт формада булганда, вакытында кирәкле процедуралар кулланганда яшь булып калу да авыр түгел. Хәер, хатын-кызның бу ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен бүгенге көндә нинди генә косметологик процедуралар тәкъдим ителми. Әмма иң сыйфатлысы, гасырлар буена сыналганы – тәнне дөрес итеп массажлау. Күз алдыгызга гына китерегез, битне массажлаганда кан йөреше әйбәтләнә, җыерчыклар тигезләнә, тире яшәреп китә. Кайбер хатын-кызлар массажны һәр көнне өйдә үзе дә ясый ала. Әлбәттә, көзге каршына килеп, көн саен үзеңә вакыт бүлеп бирә алу – рәхмәтле гамәл. Әмма шунысын да истә тотарга кирәк, өйдә ясалган массаж кайвакыт биттәге кан тамырларын зарарларга, көтелмәгән күңелсезлекләр китереп чыгарырга да мөмкин. Шуңа күрә матурлык үзәкләрендә ясалган массажның эффекты күбрәк була. Массаж ясаганнан соң битнең овал контуры барлыкка килүен, иякнең юкка чыгуын, күз кабакларының, ирен кырыйларының күтәрелгәнен, күз төбендәге караңгы тапларның югалуын, бит тиресенең ныгып, бит урталарының алсуланып киткәнен үзегез дә сизми калмассыз! Нәтиҗәсе тәүге тапкыр ясатканнан соң ук күренә башлый. Мондый ысул белән дә бит тиресен яшәртеп булганда ботокс, төрле инъекцияләр ясатырга, бәлки, ашыкмаскадыр?! Профилактика өчен биткә массажны 25–30 яшьләрдә ясата башларга киңәш итәр идем. Иртәрәк башлаган саен, киләчәктә нәтиҗәсе зуррак була.

Йөзегездәге арыганлыкны бетерәсегез килсә, язны биткә массаж ясатудан башлагыз! Үзегезгә матурлык бүләк итәргә уңайсызланмагыз, кызлар!

БИТКӘ МАССАЖ ЯСАУНЫҢ УҢАЙ ЯКЛАРЫ:

- тирәндә яткан мускулларны җанландырып җибәрә;
- лимфалар хәрәкәтен активлаштыра;
- күзәнәкләрдә матдәләр алмашын җайлый;
- токсиннарны һәм организмга җыелган артык суны чыгара;
- тирене кислородка баета;
- биттәге тонусны бетерә, спазмнар юкка чыга;
- тиренең сыгылмалылыгын арттыра; организмдагы стресс чыганакларыннан арынырга булыша.

МАССАЖ ЯСАТЫРГА ЯРАМАГАН ОЧРАКЛАР:

- инфекцияле авырулар;
- онкология авыруы булган очракта табиб киңәше белән;
- биттә үлекле бетчәләр;
- биттә травмалар;
- нык беленеп тора торган купероз;
- акне;
- калкансыман биз авырулары.

Суфле
девчачье пространство

Казань,
пр. Победы, 100
ул. Ибрагимова, 61
@prostrsnstvo_sufle

РЕКЛАМА

Камырсыз чизкейк

Чизкейк – бүгенге көндә иң популяр десертларның берсе. Аны чәй яки каһвә янына куялар. Чизкейк әзерләү фуд блогерларның яраткан шөгыле. Ниндиен генә уйлап тапмыйлар! Ә безгә аның камырсыз гына, тиз арада печеньедан әзерләнә торганын декрет ялында да мең төрле шөгыль табып яшәүче яшь әни Айгөл ТАҖИЕВА өлгертте. Айгөл – Башкортстан кызы. Һөнәре буенча – педиатр. Сөләйман һәм Кәрим исемле уллары – нәни ярдәмчеләре үсеп килә. Аш бүлмәсендә бергәләп тәм-томнар пешерергә яраталар. «Кич йокларга ятар алдыннан төрле рецептлар укыйм, өйдәгеләргә һәрвакыт яңа ризык әзерләргә тырышам», – ди Айгөл. Туган көннәрдә, төрле бәйрәмнәрдә табын яме булырлык татлы ризыкны, әйдәгез, бергәләп әзерләп карыйк.



Кирәк

- 400 г эремчекле сыр;
- 10 г желатин;
- 200 г печенье;
- 150 г куертылган сөт (майлылыгы югарырак булган саен, тәмлерәк);
- 150 г шикәр комы;
- 70 мл су (желатинны эретер өчен);
- 80 г атланмай.





Фото: Анна Арахамия

Эш барышы

■ Желатинны суга салып җебетергә, бүрттерергә куябыз.
■ Печеньены блендер яки уклау белән әйбәтләп ваклыйбыз.
■ Атланмайны микроволновка мичендә яки май салынган савытны кайнар суга куеп эретәбез.
■ Эрегән майны вакланган печенье өстенә салабыз да чәнечке белән изеп, әйбәтләп болгатабыз.
■ Чизкейк пешерү өчен боҗра рәвешендәге махсус форма кулланыла. Кайберәүләр аны фольгадан үзләре дә ясый ала. Тигез өслеккә (тәлинкә, түгәрәк поднос кулланырга була) шул форманы куябыз һәм печенье белән май кушылмасын салып, тигезләп җәябез. Тыгызлансын өчен төйгеч белән бастырып чыгабыз.
■ Барысы да әзер булгач, 10–15 минутка суыткычка куябыз. Ул арада чизкейкның өске өлешен әзерлик.
■ Эремчекле (сливочный) сырга куертылган сөт, шикәр комын кушып, тиешенчә болгатабыз.
■ Желатин эретмәсен утка куеп, болгаткалап торабыз. Әмма ул кайнап чыгарга тиеш түгел. Желатин эреп беткәч, төерләр калмаслык итеп туглап, сырлы кушылмага салабыз. Тигез масса килеп чыгарга тиеш.
■ Суыткычтан печеньелы форманы алып, шуның өстенә сырлы массаны тигезләп агызабыз һәм 3-4 сәгатькә кабат суыткычка урнаштырабыз. Процессны тизләтер өчен 40–50 минутка суыткычның катыра торган бүлегенә куеп торырга да була. Иң яхшысы – төнгә салкын урында калдыру.
■ Чизкейкның өске ягына бармак белән басып карап та аның әзер булу-булмавын белеп була. Бармак ябышмаса һәм сыгылмалы булса – әзер дигән сүз! Чизкейкны формадан бозмыйча гына матурлап алыр өчен юка озын пычак кулланабыз. Аны кайнар суга манып алабыз да тиз генә сөлге белән корытып, формадан чизкейкны аралыйбыз.
■ Чизкейкны табынга чыгарганчы киви, җиләк, вакланган шоколад, чикләвек белән матурлап бизәргә дә була. Шуны исегездә тотыгыз: чизкейкны чәй янына чыгарыр алдыннан гына суыткычтан алалар. Бүлмә температурасында озак торса, ул җебергә мөмкин!

Чәйләрегез – чизкейклы, көннәрегез ямьле булсын, дуслар!

Авокадо – мәхәббәт җимеше



Беркөнне кибеттә авокадо сайлаганда яныма бер ханым килеп, моның нинди җимеш булуын, ничек кулланууларын сорашты. Моңа кадәр авыз итеп караганы булмаган икән. Менә шуның өчен бүгенге сәхифәдә әлеге продуктның файдалы үзлекләрен ачыкларга, аны дөрес сайлау һәм әзерләү турында сөйләшергә булдым.

Авокадо кибет киштәләрендә чагыштырмача яңарак күренсә дә, бик тиз популярлык казанып өлгерде. Әлегә кадәр кулланмаган булсагыз, рационыгызга кертми калмагыз. Ул тәмле һәм файдалы ризык.

Бу җимеш A, E, F, K, B төркеме витаминнарына, калий, кальций, цинк, тимер һәм фосфор кебек минералларга бай. Авокадо – майлы җимеш, әмма туендырылмаган майны организм җиңел үзләштерә. Ул тән тиресенә, чәч, тырнакларга яхшы тәэсир итә, организмның картаю процессын тоткарлый. Моннан тыш, тән тиресен менә дигән итеп дымландыра. Изелгән авокадога бераз гына зәйтүн мае кушсаң, бит тиресе өчен бик шәп маска була.

Ул кандагы холестеринны киметә, иммунитетны арттыра, организмдагы су-тоз балансын тигезли. Ашкайнату, нерв һәм йөрәк-кан тамырлары системасы эшчәнлеген яхшырта.

Аны даими куллану күзләр өчен дә шифа: A витамины һәм каротиноидлар күзләрне картаюдан саклый.

Авокадоны сайлаганда иң элек кабыгына игътибар итегез. Анда каралҗым таплар, тырналган эзләр булмаска тиеш. Бармак бите белән басканда, йомшак тоелсын. Катырагы эләксә дә борчылмагыз, банан кебек үк, авокадо да өзеп алганнан соң өлгерә. Аны фольгага төреп, целлофан капка салырга һәм караңгы урында өлгертергә мөмкин. Янына банан да салсагыз, өлгерүе тагын да тизләнә. Көтәргә теләмәсәгез, фольгага төреп, 15 минут духовкада пешерергә була. Әзер җимешне урталай бүлеп, төшен алып ташларга кирәк. Анысын ашарга ярамый, агулы.

Авокадоны ничек әзерләргә



■ Иң гади ысул – телемләп туралган җимешне хлебец өстенә тезеп, тоз-борыч сибәбез дә, ашыбыз әзер!

■ Икенче вариант иртәнге аш өчен әйбәт. Авокадоны урталай бүлеп төшен алабыз, чокырларны кашык белән чак кына тирәнәйтәбез. Һәркайсына берәр йомырка сытып, 200 градус кызулыктагы мичтә 30 минут пешерәбез.

■ Өченче ысул – гуакамоле соусы. Аны майонез урынына да кулланырга була. Авокадоны изеп, боламык хәленә китерәбез, тоз, борыч, бер аш кашыгы зәйтүн мае, бер тырнак издерелгән сарымсак кушып туглыйбыз. Бу пастаны ипигә яки хлебецка ягып, өстенә тозлы балык яисә кыздырылган йомырка куеп ашарга була – бик тәмле.

■ Дүртенче вариант – салат. Бер авокадоны шакмаклап турап, 300 г кыздырылган тавык түше, бер уч черри помидоры, бер тотам салат яфрагы турап кушабыз. Зәйтүн мае, тоз-борыч өстибез, берничә тамчы лимон суты тамызабыз.

■ Бишенчегә – туңдырма. Телемләп туралган бер авокадо белән ике бананны капка салып, дүрт сәгатькә туңдыргычка куеп торабыз. Туңдырылган телемнәрне блендер белән издерәбез. Куерак булса, бер кашык сөт яки су кушарга була. Масса бертөслегә әверелгәч, туңдырманы креманкаларга бүлеп салабыз.

Бу кызык

- Авокадо төше безнең эрага кадәр 750 ел элек җирләнгән каберлекләрдә табылган. Әмма Европада ул бары XVI гасырда гына күренә башлый.
- Дөньядагы иң туклыклы җимеш буларак, авокадо Гиннессның рекордлар китабына кертелгән.
- Аборигеннар авокадоны «мәхәббәт җимеше» дип атый. Юкка түгел, авокадо – бик көчле афродизиак.

Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА

Фото: www.pixabay.com

Кучкар. Туганнарыгыз, дусларыгыз белән мөнәсәбәтләр шактый катлауланыр. Сезне беркем ишетми һәм аңламый кебек тоелыр. Әмма гаеп аларда түгел, ә сездә. Үзегезне үзгәртергә көч тапсагыз – араларыгыз җайланыр.

Үгезбозау. Үткәннәргә борылып карап, берникадәр нәтиҗә чыгару зыян итмәс. Югыйсә һаман шул ук тырмага басасыз. Ялгышларны төзәтергә беркайчан да соң түгел. Бүгенге көн белән генә яшәмәгез, киләчәккә максатлар куегыз.

Игезәк. Сезне алдап калдырулары бар. Шуңа күрә һәр адымыгызны уйлап эшләү хәерле. Бар нәрсәгә игътибарлы булыгыз, бернәрсәне дә күз уңыннан җибәрмәскә тырышыгыз. Таныш булмаган кешеләр белән аралашмагыз.

Кысла. Кылган игелекләрегезнең әҗерен күрер вакыт җиткәндер. Тормыш сезне яхшы кешеләр белән таныштырып торыр. Алдагы айларда биргән вәгъдәләрегезне үтәргә онытмагыз.

Арыслан. Үткәннәр белән бәйле җепләрне өзеп, яңа тормышка аяк басарсыз. Ләкин ялгыш адымнардан сак булырга кирәк! «Сабыр төбе – сары алтын» дигән девиз белән яшәсәгез бар да әйбәт булыр.

Кыз. Эш эзләүчеләр, ниһаять, күңелләренә хуш килгән эш табар. Әмма үзеңне гел эшкә генә дә багышларга ярамый. Сәламәтлек турында да онытмаска кирәк. Финанс өлкәсендә төрле үзгәрешләр булыр.

Үлчәү. Яз җитүгә үзегездә ышаныч сизәрсез һәм әлегә кадәр җитди булып тоелган проблемаларга җиңел карарга өйрәнерсез. Шәхси тормышыгызга гармония килер. Белемеңне арттыру белән шөгыльләнә башлар өчен уңай чор.

Чаян. Йолдызлар ашыкмаска, сабыр булырга, уйлап эш итәргә киңәш итә. Башкалар ашыктырсалар да, һәрнәрсәнең үз җае бар. Эштә вак-төяккә игътибар итмәгез, кирәкмәгән уйлар белән йөрмәгез.

Укчы. Сөйгәннәрегезгә карата игътибарлы булырга тырышыгыз. Бәлки, романтик кичә оештырып, хисләргә ялкын өстәргәдер? Гаилә учагын саклау – хатын-кыз эше. Ай ахыры мәшәкатьле булыр.

Кәҗәмөгез. Тормыштан канәгать булып, аның матур якларын күреп яшәргә өйрәнергә кирәк. Шул вакытта барысы да сез дигәнчә килеп чыгар. Ялгызларны ай дәвамында очрашу-танышулар көтә.

Сукояр. Ялгыз Сукоярларга йолдызлар апрель аенда мәхәббәткә кагылышлы сорауларга җитди карамаска, аларны арткы планга күчереп торырга киңәш итә. Яңа танышлар белән сак булыгыз. Бу ай – төрле сынаулар чоры.

Балык. Апрель аенда йолдызлар күбрәк ял итәргә һәм сәламәтлекне сакларга киңәш итә. Иң яхшысы – өегездә берәр тыныч почмак булдырып, үзегезнең яраткан эшләрегез белән шөгыльләнергә тырышыгыз.

КАЯН КӨЧ АЛЫРГА?

1. *Ирегезнең туган көненә туганнар җыелышып киләсен беләсез. Зур табын корырга әллә ни көчегез юк. Дустыгыз кибеттән пешергән ризык алырга яки үзләре китереп бирүче хезмәттән файдаланырга киңәш итә. Сезнең реакция:*

А. Бу бик кыйммәт!

Б. Кешенекенә ышаныч юк, үзем әзерләү хәерлерәк булачак.

В. Башкалар пешергән ризык белән сыйларга? Иремнең туганнары моны ярты ел сөйләячәк!

2. *Үзегезгә генә ял итеп кайту мөмкинлеге туды, ди. Сез:*

А. Күптән шулай ял иткәнем юк!

Б. Начар түгел. Ирем балалар белән үзе генә нишләп бетәр?

В. Гаиләдән башка гына ялга китү дөрес түгелдер сыман...

3. *Яшүсмер улыгыз үзен начар хис итә. Үзегезнең сумка да, аның рюкзагы да сезнең кулда. Бу вакытта сезнең:*

А. Өйгә кайтып, авыр рюкзакны салып ташлыйсы килә.

Б. Балагызны табибка алып бару турында план корасыз.

В. Гаҗәпләнеп караучыларга, улыгыз авыргангa гына аның рюкзагын күтәреп баруыгыз турында аңлатырга тырышасыз.

4. *Иртәнге аштан соң тәлинкәдә бер тәмле коймак калды. Аны кем ашар?*

А. Коймакны кем пешергән – шул ашый.

Б. Бала, әлбәттә. Иң әйбәте – балаларга.

В. Бөтен кешегә җитәрлек итеп бүлешәбез.

5. *Мәктәптә юк кына сәбәп буенча чираттан тыш әти-әниләр җыелышы уздырырга җыендылар, ди. Барасызмы?*

А. Юк! Хәбәрләрне телефон чатыннан беләчәкмен.

Б. Әйе! Бәлки минем әйберләр турында дә сүз булыр.

В. Чакырганнар икән, димәк, барырга кирәк...

6. *Ничек уйлыйсыз, дәү әниләр оныклар тәрбияләгәндә булышырга тиешме?*

А. Әйе, тик бөтен кешенең дә онык карарга вакыты юк.

Б. Вакыты җиткәч, мин оныклар карарга булышачакмын.

В. Әлбәттә! Гаиләдә һәркем туган җанлы булырга тиеш!

7. *Үсеп җитеп өйдән чыгып киткән балалар турында әти-әни ни уйлый икән?*

А. Җиңеллек һәм тынычлык! Тик аларсыз бераз күңелсез.

Б. Борчылу. Алар безнең өчен һәрвакыт кечкенә бала сыман.

В. Аларга барысын да бирә алдыкмы икән, дип дулкынлану.

8. *Сезгә берничә көнгә китәргә кирәклеге билгеле булгач, балагыз авырый башлый. Баланы кем белән калдырасыз?*

А. Миңа ярдәм итәргә әзер кеше белән.

Б. Миннән башка кем карасын? Беркая да бармыйм.

В. Ничек кенә хәл итсәм дә, үземне гаепле санаячакмын.

А җаваплары күбрәк: сезгә *ресурслар* җитми. Көч, акча, бәлки, вакыт җитмәгәнлектән бәргәләнәсездер. Тормыш йөген үзегезгә алгансыз. Чыгу юлы – азрак көчсез булып карагыз. Өйдәгеләрдән ярдәм сорагыз, кунакка барыгыз, үзегез генә иркенләп йөреп кайтыгыз, ял оештырыгыз.

Б җаваплары күбрәк булганда: сезгә *тынычлык* җитми. Тәнегезгә ял бирә торган ысуллар турында уйланыгыз әле: бөтнекле чәй, тозлы ванна, массаж, сериаллар... Өйдәгеләр йоклап киткәч ял итә алам дип яшәү – хатын-кызга килешми...

В җаваплары күбрәк булганда: сезгә *үз-үзегезгә ышаныч* җитми. Тирә-юньдәгеләр фикерен тыңлаудан туктагыз инде. Идеаль әни булмаудан да курыкмагыз. Һәркемнең үз тормышы, үз юлы.

тест

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен
Раилә ХӘЯЛИЕВА,
Лилия ГӘРӘЕВА
әзерләде.







ОСТАЗЫНА ЛАЕК ШӘКЕРТ

Дарина Ильясованың сынлы сәнгать белән кызыксына башлавы, әлбәттә, балачакка карый. Аның бүгенге иҗат мохите – графика һәм катнаш стильләр. Ул кечкенәдән үк Модильяни, Ван Гог, Хоппер, Франсуа Легран кебек бөек осталарның картиналарында, шулай ук рәссамнарның төрле авангардлык, импрессионизм, графика юнәлешен өйрәнеп илһамланып үсә. Яраткан рәссамнары Дейнека, Петров-Водкин, Иконников. «Мин совет чорының эре монументалистларын яратам. Колачлы эшләр илһамландыра, күбрәк графикага тартылам», – ди Дарина.

Мадияр Хаҗиевны исә иҗатындагы иң беренче укытучысы һәм илһамчысы дип саный. «Мадияр Шәрипович булмаса, сәнгать мәктәбен әллә кайчан ташлап киткән булыр идем... Ул тулы бер буын укучылар үстерде. Мин графика белән шөгыльләнергә теләгән идем, Мадияр Шәрипович сынлы сәнгатькә барырга күндерде, беренче чиратта классик белем алырга кирәклекне сеңдерде ул», – дип сөйли Дарина. Кыз Суриков исемендәге художество академиясенең Казан филиалын тәмамлый.

Сәнгатьнең дәвалау көчен ачарга хыяллана ул. Һәм шуның белән шөгыльләнә дә: сынлы сәнгать мәктәбендә укыта. Укытуны Дарина иң зур казанышы дип саный. «Балалар бернинди шартлылык та, каршылык та күрми, шуңа күрә яңа төсләр һәм палитра әйбәт килеп чыга аларның, кайчагында алар сынлы сәнгатьтә яңалык ача кебек тоела», – дип, яшь рәссамнарын мактый.

Дарина иҗатында совет чорының «кырыс стиле» дә, Европа сынлы сәнгать мәктәбе йогынтысы да сизелә. Яшь автор Ренессанс һәм классицизм мирасын өйрәнүгә күп вакытын багышлый. Шул ук вакытта эшләрендә традицион татар рухын сакларга кирәген дә аңлый. Абстракт сәнгать һәм импрессионизм кабул итү предмет формалары буенча экспериментлар башларга этәрә. Рәссам үз эшләрендә барлык классик алымнарны һәм кануннарны шик астына куя. Хәзерге заман авторлары да яңа чынбарлык тудырып, аңның мөмкинлекләрен киңәйтә.


Соңгы вакытта Дарина сюжетларны, нигездә, чынбарлыктан алып ясый. Эмоцияләргә игътибарны көчәйтә, гади генә чаралар ярдәмендә күбрәк эффект тудырырга омтыла. Төрле төсләрне ярата, әмма тәэсир көчен арттыру өчен еш кына кара һәм сорының төрле төсмерләреннән файдалана. Яңа техника кулланып, экспериментлар ясаудан да курыкмый. Җанлы һәм җансыз объектлар бертигез дәрәҗәдә күренә, ләкин шул ук вакытта пәрдә артына да качмыйлар, үз күңел дөньясын ачарга булышалар. Дарина картиналарындагы сюжет композицияләре тамашачыга мөстәкыйль интерпретацияләү өчен билгеләнгән. «Скульптор» картинасын караганда нәкъ менә шул чагыла. Автор безне картина белән ләззәтләндереп кенә калмый, картина героинясының күңел халәтен тоярга да булыша.

Болардан тыш, Дарина этләр ясарга ярата. Этләр – кешенең күңел халәтен тоярга сәләтле, һәм алар соңгы көннәренәчә хуҗаларына тугры кала.

Замана авторының эшләре күпкатламлы композицияләре һәм төсләр муллыгы белән таң калдыра. Төсле өстәлмәләр ярдәмендә туры һәм кәкре сызыклар үзара бәйләнә. Эшнең нигезендә караңгы тоннар ятса да, Дарина рәсемгә яңача карарга булышучы яктылык өсти.


Киңкырлылык, нәфислек, хисләр тирәнлеге, ялгызлык, уйчанлык, тырышлык... Яшь авторның рухын менә шул сыйфатлар билгели, ул гаҗәеп сәнгать һәм музыка гармониясе белән бергә үрелеп бара. Ә Мадияр Хаҗиев үз укучыларының уңышы белән чиксез горурлана. Шәкертем остазын да уздыра дип тә әйтә әле...

Рәмзия КАШАПОВА











ДАРИНА ИЛЬЯСОВА

ТАССР

Празднование 100-летия Татарской АССР

Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү

1920-2020



Җиһанша ТУКТАРОВ,
Җиденче чакырылыш Пенза шәһәр думасы депутаты, Пенза өлкәсенең Татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе

Пенза татарлары һәм шәхсән үз исемемнән Татарстан халкын ТАССРның йөзьеллыгы белән чын күңелдән тәбрик итәм.
Бүген Татарстан Республикасы – күпмилләтле Россия дәүләтендә үзен иң ышанычлы һәм ныклы таяныч итеп күрсәтә алган төбәк. Шунысы куандыра: Татарстан Россиядә генә түгел, бөтен дөнья күләмендә танылa бара.
Ирешкән уңышларыгызга сөенәбез, иҗтимагый-сәяси, икътисадый һәм фәнни-мәдәни тормыштагы казанышларыгызга сокланабыз. Безгә – Татарстаннан читтә яшәүче татарларга Татарстан, Казан һәрвакыт кыйбла булып тора. Ул – тарихи-мәдәни мирасны саклау үрнәге, рухи дөньябыз үзәге. Без сезгә таянабыз, сезнең ярдәмне тоеп яшибез. «Сез кайсы халыктан?» – дисәләр, «Без – татарлар, Татарстан – безнең республика!» – дип горурланабыз.

